КҮҢЕЛЛЕ
КИТАП

ББК 84(2Р-Тат)-4
К99

ЭЧТӘЛЕК

Тагын күңелле табын. Кереш сүз 3
Туплар гүләгән чакта . . 5
Бервакыт шулай була... . 32
Гераклның унөченче батырлыгы 45
Уйнап түгел, уйлап... . . 47
Ике йөрәкле кеше . . . 59
Аракыдан акыл кими . . 65
Абуталиб әйтә 69
Бик озак егылу 72
Көзгегә карап 81
Егет түгел... кыз, әти түгел, әни... 83
Бераз көтәм әле 87
Поездлар йөри, сәгать туктаган 90
Киндзюлис килә дә әйтә... 96
Шәкидә көлке бәйрәме. . 100
Таныш булыйк: Пыхы Таган 102
Башкорт көләмсәләре . . 104
Бер җепкә тезеп 107
Үзләре турында үзләре . 116
Мәсәлләр букеты . . . 129
Шинельле юмор 139
Мәктәптә һәм өйдә . . . 144
Кыска ыштанлы юмор . 164
Чәнечкеләрдән муенса . 172
Бу уклар кемгә тияр? . . 183
Озын сүзнең кыскасы . . 187
Көлдереп дәвалау . . . 215
Көндез — номерсыз, төнлә — уты юк 220
Фән күзлегеннән карап . 225
Шул да булдымы әхлак . 228
Чиле-пешлеләр сырлаган чыш-пыш 238

К99 Күңелле китап: Мәзәкләр / Төзүчесе һәм тәрҗемәчесе Зәки Нури.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.— 240 бит.

К $\frac{4803010200-004}{М132(03)-89}$ 160—89 ББК 84(2Р-Тат)-4

ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ УКУЧЫЛАРГА

ВЕСЕЛАЯ КНИГА

Анекдоты и юморины разных народов

(на татарском языке)

ИБ № 5277

Рецензенты *А. Яхин.* Редакторы *Л. Хәмидуллин.* Рәссамы *В. Бибишев.* Художество редакторы *Ф. Хәсьянова.* Техник редакторы *М. Абитова.* Корректорлары *Р. Хәмидуллина, Х. Фәйзрахманова.* Җыярга тапшырылды 20.07.88. Басарга кул куелды 18.11.88. Форматы 84×108 1/32. Китап-журнал кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 12,6. Шартлы буяу-оттиск 13,02. Нәшер-хисап табагы 10,82. Тиражы 15 000 экз. Заказ Е-405. Бәясе 60 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

ISBN 5 — 298—00139—4
© Төзү һәм тәрҗемә. Татарстан китап нәшрияты, 1989.

ТАГЫН КҮҢЕЛЛЕ ТАБЫН

Бу китап түренә без, дөнья әдәбиятының бетмәс-төкәнмәс хәзинәләреннән бик җентекле сайлап, шаян сүзле, үткен телле елмаю-көлү осталарын утырттык. Аларны берсеннән-берсе бик ачык аерылып торган чуар киемле, һәркайсы үзенә, үз милләтенә генә хас холыклы акыл ияләре дип белик.

Социаль хисләрне, яшәеш хакыйкатен, намуслылык, дөреслек төшенчәләренең тәмен дә, ямен дә бик ачык белгән һәм тирән аңлаган затлар да алар. Әйтәсе сүзләрен сине елмайдырып-көлдереп, үткен тел белән, кыска итеп, кашыңа түгел, күзеңә бәреп дигәндәй әйтү сәләте зур аларның.

Әйтергә кирәк, дөньяда яшәгән һәр халыкның әнә шундый «көлке капчыклары» — безнең илдәгедәй Щукарь бабайлар, Василий Теркиннар кебек әдәби персонажлары бар: кайбер төрки телләрдә Хуҗа Насретдин, әрмәннәрдә Пыл-Пуги, казакъларда Алдар-Күсе, кыргызларның Куйручогы, чувашларның Пудәш Потяны, молдованнарның Тындалә белән Пекалосы, каракалпакларның Омирбәге, бурятларның

Будамша дигән фольклор персонажлары бар. Әйе, алар күпләр!

Бары тик шундый көлкеле-елмаюлы иҗаттан гына торган «Күңелле китап» исемле ике басма безнең нәшриятта 1969 һәм 1979 елларда чыкканы хөрмәтле укучыларга билгеле инде. Бу басмага исә төрле илләр әдәбиятларыннан һәм халык иҗатларыннан сайлап алып туган телебезгә тәрҗемә ителгән яңа әсәрләр генә кертелде. Биредә зурлар өчен хәрби тема материаллары («Шинельле юмор») хәтта мәктәпкәчә яшьтәгеләргә адресланган «Кыска ыштанлы юмор» сезнең күңелләргә шулай ук хуш килер дип ышанабыз.

Буржуаз мораль һәм мещанлык күренешләренә төбәп яудырылган уклар исә шулай ук күпләрне уйландырыр әлбәттә.

ТУПЛАР ГҮЛӘГӘН ЧАКТА*

(Ватан сугышы елларының көлке капчыгыннан)

Кайнар сәлам

— Мин бүген гитлерчыларның бөтен бер ротасына аларның үз телләрендә кайнар сәлам юлладым.

— Ничек аңларга моны?

— Гап-гади бер нәрсә бу: үзем кулга төшергән трофей минометтан — димәк, немецларныкыннан — ут яудырып, рота дигәннәрен берьюлы кырып салдым.

Уртак тел

Ике командир сөйләшә:

— Минем рота унбиш милләт егетләреннән тора. Әмма алар бөтенесе бер уртак телдә аңлашалар.

— Ә ничек?

— Украиннар — кыю пулеметчы, казакълар — минометтан утны бик оста яудыра, грузиннар белән үзбәкләр — менә дигән тупчы, себернекеләр — ут күзле мәргән... Сугышчан телдә бөтенесе бергә сөйли башласалар, үз хәлләре мөшкел икәнен немецлар бер минутта аңлап ала.

---

* «Туплар гүләгән чакта музалар тынып тора» диелгән кайчандыр. Үткәннән килгән бу гыйбарә совет гаскәрләре туган илне яклап батырларча сугышкан барча яуларда, шул җөмләдән Бөек Ватан сугышы елларында да, кире кагылды. Җыр һәм шигырь, үткен һәм тапкыр сүз үзләренең төп мәгънәсендә һәр адымда һәм һәркайда өзлексез яңгырады, безнең сугышчылар кулында корал һәм байрак булып Җиңү яулашты. Фронт матбугаты битләреннән сайлап алынган юмор һәм сатира үрнәкләре биредә дә өлешчә тәкъдим ителә.

Телəгенə ирештe

— Партизаннар белəн йөзгə-йөз очрашмый торып җаным тынычланачак түгел,— дип шапырына СС командасы командиры, үзенең җəзалау отрядын урман ягына алып барганда. Һəм чыннан да хаклы булып чыга ул: партизаннарның беренче пулясы ук аны аяктан ега. Җаны мəңгегə тынычлана бушбугаз фашистның.

Фронтка хат

Бер малай əтисенə язган хатында түбəндəге яңалыкларны да белдерə:

«Мин этемə яңа кушамат бирдем — хəзер инде Фриц ул. Чөнки соңгы вакытларда нəкъ дошман кебек кыланганлый башлады: узган айда əнинең бер чүлмəк сөтен чөмергəн иде, əле күптəн түгел бер тавык белəн ике чебешнең башына җиткəн булып чыкты. Ə күршебез Фəрит исə үз бурзаен Геббельс дип йөртə: никтер ул, һичкем игътибар итмəсə дə, көннəр буе бертуктаусыз өрə».

Кем эше?

Басып алынган Парижда торганда вермахт офицерлары атаклы рəссам Пикассоның остаханəсенə дə кергəлилəр. Чакырылмаган бу «кунакларны» хуҗа бер сүз дə дəшми генə каршылый һəм мастерскоен күрсəтə. Шулардан берəү инде кире чыгып китəр алдыннан бер рəсем репродукциясен кулына ук алып караштыра башлый. Анда фашистлар бомбага тотып җимергəн Испания шəһəре Герник хəрабəлəре сурəтлəнгəн була. Шулчакны аңа оккупация власте башлыгы да кырын гына булса да күз төшереп ала һəм рəссамга сорау бирə:

— Сезнең эшме бу?

— Юк,— дип җавап бирə Пикассо, ике генə сүз белəн,— сезнең эшегез!

Бу кай төш була?

Майор фон Гольц Днепр ярында басып тора.

— Гей, син! Кем əле?..— дип сорый ул бер авыл кешесеннəн.— Кай төш була бу? Нинди шəһəр тирəсе?

— Биредə,— ди мужик,— нəкъ менə син торган урында, кайчандыр князь Владимир Киев кешелəрен чукындырган...

Аннары әлеге абзый, як-ягына каранып, якында беркем дә юклыгын белгәч, өсти икән:

— Ә әнә теге уйсулык тирәсендәрәк 1918 елда Киев кешеләре немецларны чукындыра... Менә шулай! — һәм, бергә укмаштырылган өч бармагы белән майорны чукындырган сыман итә дә, аны биек ярдан түбәнгә мәтәлдерә *.

Гафу үтенү

Немец генералы бик каты чабып барган полковникка кычкыра:

— Дәрәҗәсе үзеңнекеннән олырак кешегә честь бирмичә узарга нинди хакың бар синең?

— Гафу итүегезне үтенәм, пан генерал,— ди полковник, туктап та тормыйча,— әнә, күрәсез ич, минем полк пленга бирелә, ә мин, аның командиры буларак, үз солдатларым белән бергә булырга тиешмен *.

Белдерү

«Исән калган яки яралы немецлар әсирлеккә кабул ителә. Эш сәгатьләре — тәүлек буе!» дигән язулы такта кадаклап олы юл чатына дәү багана утырта һөҗүм итеп алга баручы гаскәриләрдән «Василий Теркин» кушаматлы берәү *.

Ишетеп түгел, күреп...

— Ишеттеңме, Фриц, бүгенге көннән башлап безнең баш командующий Гитлер үзе булачак.

— Әйтәм, без бүген чигенеп кичәгегә караганда озаграк һәм ераграк чаптык.

Үч алынды

Фашист әйтте көндез бер «абзыйга»:
— Сал бүрегеңне һәм бир честь!..— диләр.
Ә фашистның бүрек кигән башын
Шул абзыйлар төнлә кистеләр.

---

* Украина сатиригы Остап Вишня язмаларыннан.

Киресенчә уйла

— Инде дә куркыта да бу белорус урманнары мине, Ганс дустым. Адым саен бер генә нәрсә көтәм кебек: шуннан менә-менә чыгарлар да өстебезгә партизаннар ташланыр төсле...

— Әгәр көтәсең икән, кордаш, андый һөҗүм булмаячак: партизан бит ул һич көтмәгән төштән килеп чыга! *

Һөҗүмнән соң

— Тешләрегезне тоташтырган күперчек зарарланган, яңаны ясарга кирәк булыр, капитан әфәнде.

— Белмим, кирәкме икән: аны барыбер партизаннар шартлатыр төсле...

Кемгә нәрсә...

— Безнең обер-лейтенант тизрәк дөмексен иде.
— Ник алай дисең?
— Чөнки итеге бик әйбәт.

Гадидән дә гадирәк исәп

Офицер. Минем ротаның ничә кешесе исән калды?
Солдат. Менә сез, офицер әфәнде.
Офицер. Ә син үзең?
Солдат. Мин бүтән ротадан берьялгызым...

Ялган сүз

— Курт Пепке, сез фронтта безнең полк бик күп сугышчыларын югалтты дигән гайбәт таратасыз икән.

— Моны миңа бүген икенче батальон солдатлары әйтте, гер обер-лейтенант!

— Менә болай дип икеләтә ялганлыйсыз инде! Икенче батальон солдатларыннан сез бернәрсә дә ишетә алмадыгыз һәм ишетә алмыйсыз, чөнки ул батальонны кичә руслар тулысынча юк иттеләр бит!

---

* «Уч алынды» һәм «Киресенчә уйла» мәзәкләре заслоновчы-партизан Зәки Нуриның 1942—43 еллар блокнотында сакланган.

Дөресме?

— Сталинград кышы чамасыз салкын булган диләр. Дөресме, Фриц?

— Андый тәмуг утларында тирләп-пешәргә, янып-көяргә яңадан язмасын иде...

Барлы-юклы сөяк

«...Командирыбыз полковникның тиресе дә коры сөяге генә калды инде. Ә полкның яртысыннан... сөяк тә калмады».

Киресенчә

— Сез инде советларның шул хәтле җирен басып алгансыз, хәтта аны нишләтергә дә белмәссең?!

— Киресенчә, иркәм, бу җирләрдә үзеңне нишләтергә белмисең, инде бары җир астында гына урын калып бара кебек...

Турысын әйтү

Бөкресе гәүдәсеннән дә зуррак булган бер бабайны карый врач.

— Минемише гарип-горабаны да фронтка җибәрергә ниятлисезме әллә? — дип сорый бичара карт.

— И җанкисәккәй, рус җирендәге кабер мондый гына бөкреләрне бик тиз турайта ул! Әллә шуны да белмисеңме әле? — ди аңа врач.

Хәрбигә озату пунктында

...Отто Шмюцке, солдат. Бәкәле каймыккан. Кызу атлап яки чабып руслардан качалмый. Сафта калдырырга.

...Ганс Трипке, ефрейтер. Кулларым сызлый ди. Тикшереп карасаң — авыртма...

...Ганс Трипке, ефрейтер. Кулларым сызлый ди. Тәннәрен йоклый алмый икән. Утта пешкән булып чыкты: куллар, чыннан да, күтәрелә ала торган түгелләр. Димәк, теләсә дә пленга бирелә алмый. Күзәтү постына гына куярга яраклы.

Ком сипкән эздән

1944 елда Өченче империядә бөтен ирләрне армиягә рәттән алалар. Яше җитмештән узган Карл Сукенцукс

та фронтка китерелә һәм ул Карпат тауларында оборонага урнаштырылган бер ротага эләгә.

Менә алар текә биеклектә: менеп-төшеп йөрүләре чамасыз кыен — түбәнгә я шуасың, я бөтенләй тәгәрәвең мөмкин...

Шул биеклектән төшеп качар минутлар да килеп җитә. Рота командиры Карлга карап тора-тора да кинәт учы белән маңгаена сугып ала:

— Эврика!

Аннары янына ике солдат чакыра да әлеге Сукенцуксны биеклекнең шомарак җиреннән түбәнгә юнәлтергә куша. Әйе, тау башыннан башта шул «Грос-фатер» бабай озатыла. Бүтән солдатлар үзләре исән-имин төшә алалар. Ничек дисезме? Карл Сукенцукстан коелган... ком бәладән коткара һәм рота командиры аны Тимер тәре ордены белән бүләкләргә тәкъдим итә. Ләкин соңыннан командирлар бер нәрсәне уйлап аптырарга тиеш булалар: бу орденны кая тагып йөртергә соң? Фюрерны күкрәк белән яклаган орден урыны — әлбәттә күкрәктә... Бу очракта бит күкрәк белән яклау булмады?!

Ни бары белән

— Сезгә ничә яшь?

— Ни бары белән, офицер әфәнде, инде артыгы булмастыр...

Йөгерә алу — зур бәхет

— Карале, Отто, син уң кулсыз бит. Ничек армиягә алсыннар ди?

— Аның каравы, аякларым таза-сау минем. Ә Көнчыгыш фронттагы хәзерге шартларда тиз йөгерә алу — зур бәхет ул.

Уйлый белү — кирәкмәячәк

— Тагын буталчык җавап бирдем бит, Швейдер. Кайчан төпле уйларга өйрәнерсең икән син? — ди немец мәктәбе укытучысы бер балага.

— Уйлый белүнең миңа кирәге булмаячак инде, кадерле укытучы әфәндем.

— Ник алай дисең?

— Бер атнадан мине сугышка алалар. Минем өчен фюрер уйларга тиеш була.

Беләсе килә

— Әйтегез әле, кадерле укытучы: Сталинград урамнары бик озыннар мәллә?

— Ник сорыйсың әле моны син?

— Фронттагы абыем Курттан кичә хат алдык: «Дивизиябез бер урам буйлап инде ай буе уза, ә аның очы-кырые һаман күренми әле...» — дип яза.

Нәрсә яза?

— Иреңне госпитальгә салганнар дигән идең. Яңа хәбәре бармы? Нәрсә яза?

— Язды, тыныч ята.

— Кем язды?

— Штаб начальнигы.

Дөресме бу, әни?

— «Әтиеңне руслар әсир иткән икән...» диде миңа бер дус малай. Дөресме бу, әни?

— Беләсеңме ничек ул: русларны әтиең үзе пленга алган, ләкин алар бик күбәү булганнар икән дә, әтиеңне дә үзләренә ияртеп киткәннәр.

Тагын күңелсезлек

— Тагын күңелсезлек: минем Карл операциядән соң үлгән...

— Операцияне хлороформ биреп эшләделәрме икән?

— Юктыр, ахрысы, кәгазендә «Смоленск операциясе» һәм «Кургашын» дигән ят сүзләр генә бар.

Партизаннар ниндиләр?

— Ганс, синең партизаннар белән очрашканың булдымы?

— Әлбәттә!

— Ниндиләр соң алар?

— Моны өзеп әйтү кыен: чөнки нигәдер аларга гел артым белән торырга, алардан алда атларга туры килде миңа.

Төшкә кергән өн

— Капитан әфәнде, ник болай иртә тордыгыз?

— Коточкыч хәтәр төш күрдем... Ярый әле өн түгел.

— Әллә партизаннар кердеме төшегезгә?
— Ә ничек белдең моны?
— Йөзегездән күренә. Шабыр тиргә баткансыз...

Охшашлык

— Фриц, минем сәгатем, нигәдер Геббельска охшап булып китте.
— Ник шулай уйлыйсың?
— Вакытны гел алдап күрсәтә.

Бинокль кирәкми

— Полковник әфәнде, бинокльдән карагыз әле: безнең «тигрлар» яна түгелме?
— Бинокльдән? Үзебезнең югалтуларны нигә зурайтырга ди безгә?

Тынычландырды

— Ишеттеңме? Безнең чигенү юлын руслар тагын кискәннәр. Әгәр шулай дәвам итсә, алар безнең туган якларыбызга да юлыбызны киртәләячәк бит.
— Борчылма, якташ. Берлинга һәм өйләребезгә, белмим, җитә алабызмы-юкмы бит әле...

Куркак куркыта

— Фриц, ник син һавага гына атасың?
— Партизаннарны куркытам.
— Ә ник үзең дер-дер калтырыйсың?
— Партизаннардан куркам.

Ничек булдырган?

— Ә Карл тәки үзенә партизан пулясы тидерми калган бит. Ничек шулай булдыра алды икән?
— Димәк, минага эләгеп дөмеккән.

Матур исемле авыл *

Аулак тыкрык башындагы бүрәнәләр өстендә колакка катырак, күзләре ярымсукыр бабай утыра. Авылга

* «Партизан әлмаюлары» дәфтәреннән.

дәү машинага төялеп килеп кергән немецлар нәкъ шунда килеп тукталалар да сорыйлар икән:

— Бу авыл ничек атала?

— Нәрсә кирәк дисезме?

— Авылыгызның исеме ничек? — дип кычкыра немецларның бераз русча сукалый белгәне.

— Ә, авылыбыз исеме?! Партизан дип аталабыз. Күптәннән инде. Буденный сугышкан елларда ук шулай дигәннәр.

«Партисан... Партисан?» дип пышылдаша килмешәкләр. Һәм мотор кинәт гүли башлый да, куе тузан куптарып, машина тиз-тиз китеп бара.

Матур исемле авылның шундый хикмәтле яңгырашы да бар икән бит!

Днепр тирән елгамы?

— Ничек уйлыйсың, Ганс, Днепр бик тирән елгамы икән?

— Минемчә, шулай булырга тиеш. Чөнки моннан өч көн элек безнең батальон шунда чумдырылган иде һәм... әле һаман калкып чыкканы юк.

Ник кул күтәрдең?

— Ник кулыңны күтәрдең, Вшивке? Соңгы солдаткача каршы торырга кушылган иде бит?!

— Соңгы дигәне менә шул мин булам инде, пан фельдфебель. Ә батальон моннан бер сәгать элек әсир ителде бит. Партизаннар, каяндыр арттан килеп кереп, аны урманда камап алды.

Сөйләшә алмый

— Полк командирын телефонга чакырыгыз әле.

— Ул бит сөйләшә алмый.

— Нинди дә булса эше бармы әллә?

— Юк, телдән язды.

— Ничек?

— Бүген засадага баргач партизан гранатасыннан шулай миңгерәп кайтты.

Ник чишенмәдең?

Полковник фон Гоп-Скок бер обер-лейтенантның итекләрен дә салмыйча йокыга ятканын күрә.

— Ник чишенмәдең? Гигиенаны оныттыңмы әллә?

— Эш анда түгел. Болай кулайрак: чөнки батальоныма караганда үз аякларыма ышана төшәм мин. Партизаннар алдан сигнал биреп һөҗүм итми бит алар...

Нинди телдә сөйләшәләр?

— Партизаннарның нинди телдә сөйләшкәнен белмисеңме син, Шмутке? Белорус җирләрендә икенче ел торасың бугай инде.

— Туры китереп сөйләшкәнем булмады. Һәркайсы өч телдә сөйләшә дигәнне ишеткәнем генә бар: я атып, я граната яки мина шартлатып, я штык кадап...

Ә урман еракмы?

— Бу якларда партизаннар кай тирәдәрәк тора икән? — дип сорый немец автоколоннасы башлыгы бер авыл кешесеннән.

— Кем белгән аны, пан. Каядыр урманда инде...

— Ә урман еракмы моннан?

— Ничек әйтим инде? Менә шул юл белән туп-туры барасыз, әнә теге күрше авылны чыккач елга һәм күпер булыр. Әйеме. Әгәр шуның аша чыгалсагыз, аллага шөкер итегез, әгәр чыктым юк икән — партизаннар белән очрашу шул үзе була инде.

«Мин күпме яшәрмен?»

Партизаннар оясын туздырырга дип, бер урман читенә килеп керүгә, җәза отряды фашистлары күке кычкырганны ишетә. «Күке, күке, мин күпме яшәрмен?» дип санатмакчы була бер фриц.

— Минем пулям барып тигәнче,— дип әйткәнче имән башында утырган «Күке-партизаннар» пуляларының һәр кайсы берәр немецны җиргә егып та сала.

Сәбәбе ачык

— Руслар турында уйладым исә, куркудан тешем тешкә тими башлый.

— Бүтәнчә булмый да. Чөнки тешләреңне руслар күптән төшереп бетерде ич инде.

Врач белән офицер

Врач. Ни булды сезгә?

Офицер. Рус туплары атканын ишетүгә телдән яза башладым...

Озак түгел икән инде *

Хуҗа Насретдин, фриц кыяфәтенә кереп немецлар тылында йөргән вакытта, бер лейтенантка очраган да сорау биргән:

— Я, обер-лейтенант Шан-Раппе, бу позициядә без озак торачакбызмы?

— Фюрер приказында «актык солдат калганга хәтле» диелгән.

— Алайса, озак түгел икән,— дигән Хуҗа.

Соңгы тәре

Хуҗадан:

— Тимер тәре алган фашистка тагын нинди тәре бирәләр? — дип сораганнар.

— Агач тәре,— дигән Хуҗа.

Киресенчә дә була

Бер фрицның:

— Беләсезме, самолет һавада оча, су асты көймәсе су астында йөзә,— дип акыл сатып утырганын ишеткәч, Хуҗа:

— Киресенчә дә була. Мәсәлән, соңгы вакытта фашистларның «Фокке» дигән самолетлары күбрәк су астында йөзә, ә су асты көймәләре һавага оча,— дигән.

Беркатлылык

— Әти, синең берәр партизанны якыннан күргәнең булдымы?

— Партизанны якыннан күргән кеше, улым, бу дөньяда инде бүтән бернәрсәне дә күрә алмый...

---

* Хуҗа Насретдин мәзәкләре. Беренче Балтик буе фронтында татар телендә дә чыккан «Алга, дошман өстенә!» газетасында басылган. 1944 ел.

Эзгә төшү

— Полковник әфәнде, минем рота партизаннар эзенә төште!

— Бик яхшы хәбәр бу! Искиткеч уңыш! Котлыйм!

— Әйе, без партизаннар эзенә төштек, ә алар безгә һөҗүм иттеләр... Хәзер минем ротаның эзе дә юк...

Чыныгып җитә алмау

— Фридрих, сезнең ротага генерал фон Шлагбаум адъютанты нигә дип килде?

— Рус җирендә беренче кышны кичерә алырлык чыныккан биш солдатка орденнар тапшырырга.

— Тапшырдымы соң?

— Юк. Туры килмәде. Чыныкканнар икенче кыш башында ук бөтенесе туңып үлгәннәр иде...

Украин җиренең рельефы

— Маңгаеңа бу шешне кайда кундырдың, Макс?

— Руслардан качып чигенгәндә, Кременец дигән тау сыртыннан тәгәрәп төшкәндә. Ә синең күз төпләрең ничек күгәрде?

— Ровнодан ашыгып чапканда тип-тигез бер урында абынып...

Киресенчә

— Сезнең улыгыз Украинадан нәрсә яза, фрау Мюллер?

— Руслар аларны Днестр һәм Буг буйларында тукмаклый икән. Ә сезнеке каян һәм нәрсә хәбәр иткәне бар соңгы арада?

— Нигәдер аның киресенчә: Буг һәм Днестрда ди.

Үзенә һөҗүмнән соң

Гитлер (Гимлерга). Минем белән канәгать булмаган барча кешене Берлиннан җыеп алыгыз.

Гимлер: Әгәр моны эшләсәк, буш шәһәрдә япаялгыз калырбыз дип уйламыйсызмы, фюрерым?

Чәчләрнең үрә торуы

— Мескенкәй Максны парикмахерскийда чагында килеп кулга алганнар. Күңел төшенкелегенә бирелгәне, паникер булганы өчен ди.

— Кит әле?!
— Әйе, әйе. Чәче, ничек тарасаң да ятмыйча, гел үрә тора башлаган икән.

Һуштан язып аву

— Коточкыч бер хәл булды бит әле бездә, ахирәтем Минна, фронттан командировкага кайткан ирем Руди кухняга кергә кинәт һуштан язып ауды.
— Нидән икән?
— Казан күрде.

Кирәге беткән баш

— Мин Гюнтерның башын снаряд өзгәнне күрдем.
— Ул баш бит аңа кирәкми дә иде. Чөнки безнең барыбыз өчен дә фюрер уйлый бит хәзер.

«Кайта алмаячаксың!»

— Фриц, кәләшең Эльза өеңнән ниләр яза?
— Үлеп сагындым, әзгә генә булса да ялга кайтуыңны күрер көнем килерме икән? — ди.
— Дөрес яза ул: чөнки кайта алмаячаксың. Безнең барыбызның да монда ятып калачагыбыз көн кебек ачык хәзер.

Уртак язмышлар

— Бөтен гаиләбезнең язмышы уртак булып чыкты безнең. Үткән сугышта әтиемнең уң аягы өзелгән булган, менә хәзер минем дә нәкъ уң аякны өзделәр.
— Димәк, хәзер син әтиең улы түгел, дип беркем дә әйтә алмый инде.

Түбән дәрәҗә

— Безнең якташыбыз Штэкерның взвод командиры булганын ишеттеңме әле син?
— Ә элеккеге командир кем булган хәзер? Күрәсең, дәрәҗәсен күтәргәннәрдер?
— Киресенчә, бик түбән төшерелгән: тирән гүрдә ята инде ул хәзер.

Тимерме? Әллә агачмы?

— Руслар траншеясына беренче булып керүчеләргә тимер тәре ордены биреләчәк,— дип белдерә офицер үз солдатларына бер һөҗүм алдыннан.

Казан ашамы, Берлин ашамы?..

Рота командиры Иванов солдат Насыйбуллин белән окопта сөйләшә:

— Кайсы яктан әле син?

— Татарстаннан. Буа дигән кечкенә бер каланыкы.

— Димәк, өеңә Казан аша кайтачаксың?

— Юк, иптәш капитан, только через Берлин!

— Молодец! Географияне яхшы беләсең икән. Җиңү фәне буенча «бишле» сиңа.

«Өметеңне өзмә»

Салкын окопта тешләре тешкә тими калтыранган ике солдат сөйләшә:

— Хатыныңниләр яза?

— Арабызда үзенең туган энесе юкмы икәнен белергә тели, эзләп кара әле шуны!..— ди.

— Юк белән баш катыра. Без чигенгәндә дөньяның асты-өскә килде бит инде.

— Өметеңне ул хәтле үк өзмә, кордаш,— дип өченче солдат сүзгә кушыла.— Тиздән син аны теге дөньяда очратачаксың.

Төгәллек

— Хәрби эштә, лейтенант Вошке, иң мөһиме — төгәллек.

— Так точно, полковник әфәнде. Бүген менә руслар безне тагын төп-төгәл ун пункттан алып ыргыттылар.

Теге дөньяда

— Ишеттеңме, Мориц? Геббельс соңгы речендә безнең дивизия солдатларына тиздән шоколад, балык уылдыгы һәм рус аракысы бирәчәкләр дигән бит.

— Теге дөньяда нәрсә ашатканны каян белә иден?

Генераллар сөйләшә

— Бухарест янында дивизия командиры булып күпме сугыштыгыз?

— Белмим. Сәгатькә карап торырга вакыт булмады анда.

Французча бәяләү

Гитлерчы: — Безнең югалтулар зур дигәнгә ышанмагыз сез.

Француз: — Мин шулай итәм дә! Бөтенегезне кырып бетерсәләр дә, барыбер: «Югалту зурдан түгел!» — диячәкмен.

Минск гарнизонында

— Нишләп син болай үзеңә кабер казып куйдың әле, Ганс?

— Бүген булдыра алган эшеңне иртәгегә калдырма дигән кагыйдә белән яшәдем һәм яшим мин.

Мәкальгә төзәтмә

— Син, Гюнтер: «Тел Киевка кадәр җиткерә», дигән мәкальнең нәрсә аңлатканын беләсеңме?

— Ул, мөгаен, Геббельс теле турындадыр. Ләкин аның теле безне Киевка түгел, ә Берлинга хәтле үк җиткерер дип куркам мин.

Табып бирерләр

Чигенгәндә Фриц бер фельдфебельдән сорый икән:

— Әйтегезче, зинһар, миңа үз полкымны ничек табарга икән?

— Борчылма, әсир төшкәч сиңа аны руслар табып бирерләр.

Элемтә өзелүдән куркалар

— Капитан Шульц, синең солдатларың бүген ник чигенде?

— Алар, генерал әфәнде, сездән аерылып калып, штаб белән элемтә өзелүдән куркалар.

Иске танышлар

— Курт Блицграбе, сез Гете, Гейне, Шиллерларны яхшы беләсезме?

— Ничек белмәскә ди: аларның китапларын мин сугышка чаклы ук Берлинда яндырган кеше.

— Тарас Шевченконы дамы?

— Аны да беләм: музееннан бик яхшы биш гобелен әләктергән идем...

Әзерлек

— Полковник, сез иртәгә башланасы һөҗүмгә әзерме?

— Әйе, генерал. Иң кирәге әзер: офицер әфәнделәрнең шәхси әйберләрен җыеп тылга озаттык инде.

Йөри алмабыз, ахрысы

— Син ничек уйлыйсың, Вилли, без кайчан да булса Мәскәүдә ду килеп йөри алырбыз микән?

— Белмим, Отто. Минемчә, без инде гомумән, беркайчан да йөри алмабыз, ахрысы.

Берлин мәктәбендә

— Хәзер, балалар, үзегезне Көнчыгыш фронтта дип хис итегез. Бөек Германияне яклап сугышасыз. Һәм барыгыз да шул турыда инша яза башлыйсыз.

Биш минут вакыт уза.

— Минем әзер, укытучы әфәнде!

— Шулай бик тизме? Нәрсә яздың соң, Гансик?

— Васыять, укытучы әфәнде.

Тотальниклар * сөйләшә

Бабасы. Кайларда югалып йөрисең, эт койрыгы? Монда бабаңны фронтка куалар, ә син җил куасың... Вакытында өйгә кайтырга исеңдә дә юк. Колагыңны бормый булмас, юеш борын!

Оныгы. Беренчедән, мин югалып йөрмәдем, ә хәрби хезмәткә алу комиссиясендә булдым. Икенчедән,

---

* Тоталь мобилизация — тоташтан, барысын да хәрби хезмәткә алу.

юеш борын түгел, ә ефрейтор мин. Өченчедән, рядовой Шульц, сезгә үрә катып сөйләшергә боерам, өлкән чин алдында басып торуыгызны онытмагыз!

Төртеп төшерүләр дә саналгач...

— Парашют белән ничә тапкыр сикердегез?
— Бер.
— Ә кәгазьдә унбер дип язылган?
— Ун тапкыр безне самолеттан төртеп төшергәннәр иде, бәлки шуларны да санаганнардыр...

Соңгы куану

Кәефе тәмам кырылган Гитлер хәрби хәрәкәтләр картасына иелгән килеш тирән сагышланып үзалдына мыгырдый икән:

— Таллинны калдырдык... Риганы бирдек... Чехословакиянең Раховын алдылар...

Шулчакны ашыгып адъютант аңа телеграмма кертә:

— Сезнең бертуганыгызның хәрби училищеда укучы улы бер экзаменын да бирә алмаган...

Гаять куанган Гитлер урыныннан кинәт сикереп тора:

— Менә рәхмәт ичмасам... Менә рәхмәт... Бернәрсәне дә бирмәгән... *

Авиация һәм пехота

— Украинада безгә дә һавага күтәрелергә туры килде.
— Әллә син, Ганс, авиациягә күчтеңме инде?
— Юк, партизаннар минасы чәлпәрәмә китергән эшелоныбыздан минем дә ничек күкләргә күтәрелүем искә төшкәннән генә әйтәм...

Танымады

Баласын иярткән бер фрау зоопаркта йөри. Бер читлектә маймыл күргәч, шул малай сорый икән:

— Әллә сугыш беттеме инде, әни?

---

* «Бу сатираны «Крокодил» журналы 1944 елның октябрь ае санында бастырганда менә нинди искәрмә өсти: «Бүгенге көн немец-фашистлары телендә поражение (җиңелү, тар-мар ителү сүзе) «бирү... бирелү... калдыру...» кебек төшенчәләр белән йомшартып аңлатыла башлады...»

— Юк әле, балам, әмма тиздән бетәчәк. Ник сорыйсың әле син моны?
— Ә, алайса, Геббельс ник бу төрмәдә утыра?

Барысы да тәртиптә

— Алло!.. Штабмы бу? Совет самолетлары бомбага тотканнан соң чигенүче Шнельс гаскәрләре нинди хәлдә?
— Барысы да тәртиптә шикелле, пан майор? Полковник гәүдәсенең бөтен өлешләре табылды... Ә башын эзләү әле дәвам итә.

Юл уңаена каратып...

Немец офицеры үзенең деньщигын битәрли:
— Күпме әйттем инде син дуракка «Минем итекләрне көнбатыш якка алды белән каратып куй» диеп. Инде чолганышта калуыбызны белмисеңдәме әллә, аңгыра?!

Кирәкле күнегү

— Бу Карл кулларын ник алай бер күтәреп, бер төшереп маташа. Сигналчы булырга өйрәнәме икән әллә?
— Әйе. Әсирлеккә бирелү күнекмәләре ясый...

Бердәмлек

— Сез капитан Мюллер солдатлары турында ишеттегезме әле? Соңгы сугышта берәве дә чигенмәгән ди.
— Һөҗүмгә чынлап шулай бердәм керделәр микәнни?
— Юк, бөтенесе бергә кул күтәреп әсир булганнар.

Кемне ничек сәламләргә

— Рядовой Попер, лейтенантны ничек сәламләргә тиешсең син?
— Үзебезнекен бер кулны, ә русныкын ике кулны күтәреп.

Күзгә төртсәң күренмәс төн

— Күзеңне нигә бәйләдең, Ганс?
— Рус штыгы кадалды.
— Менә ни аңлата икән ул русның «күзгә төртсәң күренмәс» төн дигән әйтеме.

Бездән җиткән

Гитлер, Геринг һәм Геббельс герман халкы үз идарәчеләренә нинди караштa икәнен белмәкче булалар. Урамда алар беренче немецны күрүгә:

— Әйт әле, безнең хакта халык нәрсә сөйли? — дип сорыйлар.

Җавап урынына эшләпәсен салып тегеләргә суза әлеге абзый. Ил башлыклары шул эшләпәгә берәр марка акча салалар. Немец, эшләпәсен тагын бер сузып, тагын өч марка ала. Моны ул бер авыз сүз дә әйтмичә берничә кат кабатлый. Ниһаять, түземе беткән Гитлер кычкыра аңа:

— Бездән җитте сиңа!

— Нәкъ менә шуны әйтә дә инде немец халкы сезнең хакта,— ди дә узгынчы, якындагы бер йортка кереп кача.

Иске яңалык

— Фриц, сиңа бер кызык нәрсә әйтимме?
— Тыңлыйм.
— Без җиңәчәкбез бит!
— Кем әйтте?
— Фюрер.
— Мин тагы җитди сүздер дип уйладым...

Тубыктан, муеннан һәм баштүбән

Суга батучы ике ата фашист сөйләшә:

Муссолини. Ярдәм итүеңне үтенәм, Гитлер... Урта диңгезгә батам бит. Су инде муенга җитте.

Гитлер. Тыныңны чыгарма, тиле!.. Үзем дә Рурда тубыктан су эчендә торам бит инде.

Муссолини. Тубыктан? Ә мин муеннан дим ич...

Гитлер. Ә мин баштүбән бит...

Телгә бөсер чыгу

— Геббельс ник радиодан чыгышлар ясамый башлады?

— Чирләгән ди, теленә бөсер чыккан икән...

— И мескен, шул хәтле яман нинди сүз лыгырдады икән?

Гүр дигән нәрсә бар!

— Ничек уйлыйсың, Вилли, Кызыл Армия килеп Берлинны алгач, Гитлер кереп качарга нинди урын табар икән?

— Гүр дигән нәрсә бар бит!

Әтисе һәм улы

— Фриц, бик кызыклы нәрсә белдем әле мин бүген: мине әсир иткән рус офицерының әтисе 1918 елда минем әтине пленга алган булып чыкты.

Яшен тизлеге белән

Үз гаскәрләрен һөҗүмгә юнәлткәндә Гитлер аларның Советлар Союзын яшен тизлеге белән басып алачагын белдерә. Әмма сугыш озакка сузыла һәм «яшен тизлеге» дигән сүз Германиядә бөтенләй икенче мәгънәдә кулланыла башлый.

Берлинның бер кешесе, мәсәлән, чалбары ертылгач, мастерскойга керә дә:

— Шуны тиз генә ямап бирә алмассызмы? — дип сорый.

— Яшен тизлеге белән эшлибез аны! — ди оста.

— Рәхмәт, алайса,— ди клиент һәм остаханәдән тиз генә чыгып китә.

Бармагын дәваларга...

Фронт корреспондентларыннан берәү Геббельска гариза җибәрә: «Синявино янындагы бер бәрелешкә эләккәч, рус снаряды кулымны өзде. Миңа, министр әфәнде, дәваланырга биш меңарка акча бирүегезне үтенәм».

Геббельс шуңа: «Бармагын дәваларга илле марка бирергә», дигән резолюция сала. Ә секретаре исә аңа: «Бирелә бит өзелгән кул турында сүз бара», ди икән.

— Сез бигрәк тә беркатлысыз. Минем корреспондентым «кул» диеп яза икән, димәк, аның бармагы гына өзелгән булырга тиеш. Ул бит минем шәкерт!

«Нәрсә ул үлек баш?..»

— Фриц, сезнең дивизия ни өчен «Үлек баш» диеп атала?

— Чөнки аның исән башлы сугышчылары бик санаулы гына калды.

«Иң ышанычлы сугышчылар»

— Полковник әфәнде,— ди обер-лейтенант.— Нәрсә була инде бу? Мин бит ротаны яхшы солдатлар белән тулыландыруны көткән идем. Сез миңа җыен аксак-туксаклар белән сукырларны гына бирәсез.

— Соң алар бит иң ышанычлы сугышчылар да инде хәзер, чигенеп чабар хәлләре булмаячак.

Артык бияләй

— Безнең, Ганс, бөтен ротабызга нибары өч пар бияләй бирделәр.

— Ничек, җиттеме соң?

— Җитте. Хәтта бер пары артып та калды әле.

Кара тартмада ак ситсы *

1944 ел азагында фронтта Гитлер солдатларына кара тартмалар өләшелә... Аның өстенә «Катгый сер итеп сакларга! Кирәкле иң соңгы очракта гына ачарга!» дип язылган була.

Шундый ахыр чик җиткәч солдат Ганс үз тартмасын беренче булып ача һәм анда ак ситсы кисәге ятканын күрә. Аның белән нишләргә кирәген бик тиз аңлап ала ул, һәм шуны күтәреп, беренче булып әсирлеккә бирелә.

«Русларның снарядлары беткәч...»

Гитлерга Мәскәүдә немецлардан азат ителгән һәр шәһәр уңае белән 224 туптан егермешәр салют бирелә дигән хәбәр җиткерелгәч, ул:

— Һәр пункт өчен 4480 снаряд! — ди дә үз гаскәрләренә чигенергә әмер бирә.— Шулай итеп,— дип аңлата ул моны — руслар үзләренең бөтен снарядларын атып бетерәләр һәм аннары без аларны коры кул белән кырып бетерә алачакбыз.

Үтә ятим булырга теләү

— Рядовой Фриц, син Гитлер партиясен үзең өчен кем итеп саныйсың?

— Туган анам дип, обер-лейтенант!

---

* Болгария хәрби нәшрияты чыгарган «Сатира Сопротивления» исемле китаптан берничә язма.

— Ә фюрерны?
— Туган атам.
— Ә шулар өчен нишләргә әзерсең син?
— Үтә ятим булып калырга теләр идем.

Белгечлеге — табут ясау

Гитлерчыларга болгар халкының карашы нинди икәнен белергә теләп, бер обер-шарфюрер, урамда очраган кешегә сорау бирә:

— Партизаннарга булышлык итәргә әзерме син?
— Мин моны гомердә эшләячәк түгелмен.
— Ә безнең армиягә?
— Аның өчен көне-төне эшләргә әзер.
— Молодец! Шуннан да яхшырак җавап көтмәгән идем. Белгечлегең нинди соң синең?
— Кабер казучы һәм табутлар ясаучы идем...

Маймыллар кертмәячәк

Геббельс турында сүз чыга:

— Әгәр Германия җиңелсә, нишләр икән ул?
— Югалып калмас! Зоопаркка барыр да тиз генә анадан тума чишенеп маймыллар читлегенә керер. Анда аны руслар таный алмаячак.
— Ә син аны маймыллар үз читлекләренә кертер дип уйлыйсыңмы?

Бәясен түләячәксең

— Өемә ризык һәм бүләкләр белән тагын бер посылка җибәрдем. Бер тиен түләүсез кулга төшергән нәрсәләрдән генә.
— Юкка шапырынма, Ганс, аның өчен гомерең белән түләячәксең әле син.

Мәҗбүрият корбаны

— Сез үзегез теләп әсир булдыгызмы?
— Юк, руслар мәҗбүр итте.

Ефрейтор язмышы *

— Минем фюререм,— ди генерал башын түбән иеп аптырап утырган әче чырайлы Гитлерга.— Рус фронтында бик күп генераллар һәлак булды!

* Димәк, Гитлерның үзенеке.

— Әйдә, шайтаныма олаксыннар ла! Мине хәзер бер ефрейтор язмышы барыннан да бигрәк кызыксындыра.

Күңелле җавап әйттерер өчен

Фридрихштрасседагы киоскта «Яңа тәртип» дигән журнал саталар. Шунда берәү килә дә, тиешле акчасын сузып:

— «Яңа тәртип» бирегез! — ди.

— Бетте,— ди сатучы.

Бер-ике минуттан шул ук кеше тагын сорый.

— Миңа «Яңа тәртип»!

— Бетте,— ди сатучы тагын.

Минут үтүгә әлеге билгесез агай тагын шул ук сатучыдан «Яңа тәртип»не сорый икән.

— Әйтелде бит инде сезгә ул бетте дип. Ни чурытыма аптыратасыз тагын?

— Менә шуны ишетүе бик күңелле булды! — ди дә юкка чыга журнал сораучы.

Чынын ишетү

Кызыл Армия бик кызып һөҗүм иткән көннәрдә бик җитди сәбәп белән кыска сроклы ялга кайткан бер солдат, кирәк буласы бар дип, «Гитлер капут!» дигән тәгъбирне ятлап йөри икән. Урамда бер офицер очрагач, аны ул «Хайль Гитлер!» диясе урынга, шул «Гитлер капут»ны әйтеп сәламли.

Җене чыгып ачуланган кәяфәтле офицер солдатны юл читенәрәк чакырып ала да сорый:

— Ә син моны чынлап беләсеңме әллә?

Чабышта җиңү

Солдат Фок кыска сроклы ялга кайта. Нәкъ шул вакытта шәһәрдә марафон чабышы буенча ярыш уздырыла икән. Шуңа Фок та катнаша һәм беренче урынны ала.

— Бу хәтле тиз чабарга ничек өйрәндең син? — дип сорыйлар аңардан якташлары.

— Көнбатыш фронтта, әлбәттә,— ди.

Сыңар куллы солдат хаты

— Кадерлем Лотхен, сугышка киткәндә мин сиңа кулымны һәм йөрәгемне вәгъдә иткән идем. Кулымны инде сиңа хәзер үк посылкага салып җибәрә алам.

* * *

Такмак дибез, такмак дибез,
Такмак түгел, тукмак ул —
Көн-төн безнең сафта йөри
Фашистларны тукмап ул.

Суларга кармак салабыз,
Кайтабыз балык белән.
Халык гаскәр белән көчле,
Ә гаскәр — халык белән.

Иген яндырды фашистлар
Һәм ут төртте өйләргә...
Инде суыкта биилэр
Без уйнаган көйләргә.

* * *

Повар юри сорый миннән:
«Кем ул Адольф Гитлер?» — дип.
Мин әйтәм: «Суйсаң итен дә
Эт ашамас эттер!..» — дип.

* * *

«Мәскәүләргә юл аласың»
Дип әйттеләр фрицкә.
— Димәк, потлап сало була,
Балы, мае — бер мичкә.

Миңа да җитәр анда мал
Һәм гаиләм өчен дә.
Барып та җитәрбез бәлки
Ике-өч көн эчендә!..

Зур хыялга чума шулай
Дөньясын онытып бирән:
«Мәскәүне инде үземнең
Җәннәтем итеп күрәм...»

Чү, ни булды? Төсе китеп
Ник калтырый башлады?
Юл буенда аунап ята
Үле фриц башлары.

Мәскәү якынайган саен
Башы иелә бара.
Кара тәреле «Тигр»лар
Тау-тау өелә бара.

Салкын окопларда яту
Аны хәйран калдырды.
Ярый әле бер мужикның
Иске тунын салдырды.

Һәм... Кинәт яшен балкыды
Һәм... Кинәт күк күкрәде...
Күз алларын караңгылап
Аяк асты тетрәде.

* * *

...Эшелон кайта Берлинга
Фрицлар белән тулы:
Кайсының күрер күзе юк,
Кайсының — аяк-кулы...

* * *

Немец разведкага очты
Болыт артына качып.
Батырды очкычны суга
Безнең туплар ут ачып.

Дулкын ярып йөзгән баржа
Фашистлар белән тулы.
Ул да чумды су астына —
Шул булды соңгы юлы *.

* * *

...Урманда кычкырма, күке,
Очып болын-кырга чык.
Кызыл гаскәр килә әнә,
Зур җиңүгә юл ачып.

...Гитлер куркып уянадыр
Төшендә табут күреп —
Чөнки гаскәре чигенә
Йолкынган тавык кебек.

---

* Белорусчадан.

...Күктә йолдызлар атыла
Вак яңгыр яуган кебек.
Фашистлар инде кырыла
Карурман ауган кебек *.

* * *

Сукыр Гитлер сабан сөрә,
Утырып елый межага.
Безгә нужа күрсәтәм дип
Үзе калды нужага.

Килгән чакта немец килде
Ике аягы белән.
Инде кире сыпыра ул
Култык таягы белән **.

Бөтен шартын китереп

...Бер карауга яу кырында безнең сугышчыларның һәммәсе немец-фашистларны бер үк дәрәҗә ачу һәм усаллык белән кырадыр төсле. Сөйләшүләренә колак салсаң, һәркайсы үзенчә сугышка хәтле булган профессиясенә хас рәвештә тукмый икән илбасарларны, әйтик, мәсәлән, теләсә нинди тимерне теләсә ничек бөгә белгән тимерче фрицны аның үз траншеясендә мылтык түтәсе белән дөмектергәндә көйләп әйтә икән: «Дага итеп бөгәм сине, паразит».

* * *

...Парикмахер исә өенә язган хатны менә ничек сырлый: «Кичә разведкада мин дүрт фашистның башын сабынламыйча да шундый чиста итеп кырдым, хәтта кайнар компресс ясап торуның да кирәге калмады».

...Тегүче пулеметтан атып бер «мессершмитт»ны җиргә мәтәлдергән дә үзалдына сөйләнә: «Әһә, бөтен җөйләреңне дә сүттемме!»

...Балыкчы пуляны бер фрицның нәкъ маңгаена тидереп дөмектергәч елмая һәм: «Каптың ич менә!» дип кулларын угалап ала.

---

* Партизаннар иҗаты тупланган «Лясные песни» дигән китаптан. Минск, 1970.

** Татар халык иҗаты үрнәге.

...Укытучы тупчыларга команда бирә: «Тагын шулай кабатлагыз! Кабатлау — гыйлемгә өйрәнүнең төп кагыйдәсе».

...Сугышта хәрби табиб саналган табиб тагын өч «тел» эләктереп кайткан разведчикларны котлап каршылый: «Тел операциясе уңышлы башкарылды!»

...Булмыш бухгалтер эссесчылар землянкасына граната ыргыткач зур канәгатьләнү белән: «Балансның очы очка бик төгәл ялганды...» — дип куя.

Кыскасы, һәр сугышчы элеккеге һөнәрен сугышта да бөтен шартын китереп дәвам итә.

Берничә мәкаль һәм әйтем

— Ватан — ана, Ватан — бер,
шуны яклап утка кер.
— Илең якын икән сиңа —
фашистны катырак кыйна.
— Тапкырлык ул — батырлыктыр,
тапкырлыкка ни җитә.
Дошманны тапкырлар кыра,
тапкырлар әсир итә.
— Дошманнан саклану өчен
иң яхшы чара — һөҗүм.
— Пуля — бал корты кебек ул:
чигенеп чапсаң — чага.
— Ватан бүләге — намус сафлыгы,
Ватан бүләге — йөрәк шатлыгы.
— Дошман поездлары шартлау
партизанның шатлык авазы.
— Эт булып өрмәсен дисәң,
полицайның башын кис.
— Партизанга дан —
фашист койган кан.
— Гитлер тузгый, Гитлер шашына,
димәк, тиздән дарга асыла.
— Патша таҗы киеп Гитлер
Мәскәүгә кермәк иде.
Бетте Гитлер, бетте гаскәр —
гүрләре күмәк инде.
— Илбасарны тар-мар итеп
Берлинга барып кердек.
Гитлерны — фашист сыртланын
шул өндә дөмектердек.

БЕРВАКЫТ ШУЛАЙ БУЛА...

Нәрсә җиңел, нәрсә авыр?

Бик күп шәкертләре булган Сократка бер җилбәзәк һәм җиңел холыклы ханым әйтә икән:

— Зур акылың һәм шәкертләрең белән мактанма. Минем сиңа каш сикертеп бер каравым белән, шәкертләрең минем арттан йөгерәчәк бит.

— Ихтимал,— ди Сократ аңа,— чөнки син бит аларны түбәнгә өстерисең һәм бу эш бик җиңел, ә мин исә аларны биеккә, үргә менәргә өйрәтәм, бу — иң авыр хезмәт.

Кайсы кем?

Атаклы мәсәлче Крыловны җирләгәндә, кемдер сорый:

— Әйтсәгез икән, кемне күмәләр бүген?

— Халык мәгарифе министрын.

— Ничек? Мөмкин түгел. Әллә чыннан да Уваров үлдеме?

— Уваров түгел, Крыловны җирлибез!

— Соң, Крылов бит мәсәлче, ә министр — Уваров...

— Аларны шулай бутыйлар. Чын министр — Крылов. Ә Уваров үз отчетларында Россиянең халык мәгарифе турында мәсәлләр язган.

Трагик дебют

Үзен инде хәтта «бөек» дип санаучы мактанчык бер артист атаклы трагик Рыбаковтан үзе уйнаган «Отелло»-ны карауны үтенә һәм спектакльдән соң сорый икән:

— Мин Дездемонаны яхшы үтердемме?

— Әйе,— ди Рыбаков.— Ә Шекспирны аңардан да яхшырак үтердегез.

Башмак түгел, чүәк

...Бурычка акча биреп торучылар Оноре де Бальзакның теңкәсенә тия икән. Берчак иртән, ишек шакыгач, ул:

— Мин өйдә юк! — дип кычкырган.

— Дөресен әйтмисез! Сез өйдә! — дигән тавыш ишетелгән тышкы яктан.— Башмакларыгыз ишек төбендә бит!

— Булса соң! — дип каршы килгән Бальзак.— Мин башмак түгел, чүәк киеп киттем, бик беләсегез килсә!

Сыйфатына карап

— Шуны кисәтеп куйыйм,— ди язучыга нәшир,— без әсәрләргә аларның сыйфатына карап түлибез.

— Шәп ич бу! — дип елмая Марк Твен.— Шул хәтле күп акча алырмын дип һич уйламаган идем!

Кыен сорауга җавап

Атаклы инглиз шагыйре Мильтонга сорау бирелә:

— Ни өчен ундүрт яшьлек малай тәхеткә утыра ала, ә унсигезе тулмыйча өйләнә алмый?

— Чөнки ил белән идарә итүгә караганда хатынга баш булуы кыенрак,— ди Мильтон.

Хатын һәм сөяркә

1888 елның 11 февралендә Антон Павлович Чехов Суворинга хат яза:

«...Сез мине берьюлы ике куян артыннан кумаска, медицина белән шөгыльләнү турында уйламаска да өндисез. Ни сәбәпле ике куян кумаска икәнен белмим мин. Шулай эшләү минем күңелне күтәренке итә, дәрт кертә. Чөнки эшем бер генә түгел, ә ике икәнен беләм. Медицина — минем законлы хатыным, ә әдәбият — сөяркә. Берсе туйдырса, икенчесендә кунам. Бу, гәрчә әдәпсезлек булса да, әллә ни куркыныч нәрсә түгел, чөнки бит минем хыянәтчеллегемнән аларның икесе дә берни югалтмый».

Дөрес сайланылган

Академиягә сайланылган берәү турында үз фикерен әйтә икән аның икенче коллегасы:

— Минемчә, дөресе эшләнгән. Барыннан да элек ул мәһабәт кыяфәтле. Ул әдәпле. Ул бүләкләнгән. Аның бернинди үз фикере юк. Нәрсәдер язганын беләм, әлбәттә, ләкин нишләмәк кирәк? Безнең беребез дә тулы ук камил түгел бит!

Үзгәреш турында

Атаклы бер актриса картлык килә дип борчылганда, берәү коры сүз белән юата-тынычландыра икән: имештер, үзгәрешсез булып беребез дә калалмый.

— Куйсана,— ди икән ачуы кабарган актриса,— әнә диваналарны алыйк, мәсәлән! Күптән дивана үзе һәм һаман шулай булып кала бирә ич!

Аталы-уллы әдипләр гәбе

Улы Александр Дюма белән атасы Александр сөйләшә:

— Бу дөньяда, улым, вөҗданлы кешеләр шактый күп... Әйтик, мәсәлән, менә без икәүбез, һәм һәрхәлдә икебездән берәү — шундый яхшыларның берсе.

Икенең берсе

Кече Александр Дюма хатын-кызларны бик ярата һәм аларга мөнәсәбәте бер үк вакытта тыйнак та була: «Хатын кыз,— ди ул,— я бер нәрсә турында да уйламый, я бүтән нәрсә турында гына уйлый...

Ике фикер

Атаклы драматург Саша Гитри бервакыт ничектер театр директоры белән ачуланышып әрләшә.

— Сез мине рәнҗтеттегез, шуңа күрә сезне күмәргә дә бармаячакмын!

Шикләнеп куркучан директор төн йокламый бичара, иртәгесен дә эле аптырап, Гитриның театрда актер булып эшләгән улы Люсьеннан сорый:

— Мине шулай куркытудан ничек оялмады икән этиең?.. Шундый сүзне әйтергә ярыймы соң? Сез ничек уйлыйсыз?

— Әйе, сез хаклы,— ди Люсьен.— Әтиемә аны әйтергә кирәк булмаган... Ләкин, сезне тынычландыру өчен, мин сезнең җеназагызга һичшиксез киләчәкмен.

Биргәнне алмау

— Сезгә илле яшь бирәләр,— ди икән берәү танылган актрисага. Ә ул әйтә:

— Әйе, бирәләр, ләкин бит мин аны алмыйм!

Интервью

Ул чакта шахмат буенча дөнья чемпионы булган Роберт Фишердан Болгариянең бер журналисты интервью алырга тели.

— Башта миңа илле лев акча бирегез, аннары сөйләшербез,— ди чемпион.

— Рәхмәт,— ди аңа журналист һәм «Сездән интервью алдым инде» дип китеп бара.

Бер тәүлек срок

Шерлок Холмс турында атаклы хикәяләр авторы Артур Конан-Дойль бервакыт «Югары катлам кешеләре» дәрәҗәсенә күтәрелгән танышларыннан ун кешегә берүк эчтәлекле телеграмма җибәрә һәм... шуларның бөтенесе бер тәүлек эчендә чит илгә чыгып кача.

Телеграммада: «Бөтенесе дә ачыкланды, тиз генә шылыгыз», дип язылган була.

Ничек язарга?

— Шөһрәт казаныр өчен ничек язарга кирәк? — дип сорыйлар бервакыт Марк Твеннан.

— Бу бит бик гади нәрсә! Каләм һәм кәгазь алырга да башыңа килгән уйларны берниндиi көчәнүсез сырларга да сырларга кәгазь битенә...

Көтеп картаю

Автобуска кереп утыргач Бернард Шоу контролерга үзенең даими билетын күрсәтә икән.

Контролер гаҗәпкә кала:

— Соң, бу бит укучы бала билеты?!

— Әйе. Менә шуннан чыгып сезнең каргалган бу автобусны күпме көткәнемне аңларсыз дип беләм.

Бәла түгел

— Шәкертләрегездән берәү иҗат иткән музыка сезнекенә бик охшаш диләр? Сез моңа ничек карыйсыз?

Шундый сорауга композитор Римский-Корсаковның җавабы менә нинди була:

— Әгәр музыка турысында ул нәрсәгәдер охшаш дисәләр — бу бәла түгел! Ә менә әсәр берничгә дә охшаш булмаган очракта — эш бөтенләй начар инде.

Китаплар исеменнән җавап

Гогольдән сорыйлар икән:

— Сез үзегез җен-пәриләр, шайтаннар һәм җәһәннәм уйдырмаларына ышанасызмы?

— Һичкайчан һәм берничек тә ышанмас идем, әгәр менә бу әсәрләр тумаган булса,— дип аңлата әдип әле яңа гына чыккан «Вий», «Диканька янындагы хутор кичләре» дигән әсәрләрен күрсәтеп.

Берничә көн үтүгә

Билгеле булганча, Жюль Верн гадәттән тыш эшчән, ә аның нәширләре исә чамасыз өлгер-җитез булалар.

Көннәрнең берендә аңа бер яшь кеше ашыгып килеп керә һәм каты кычкырып:

— Әфәндем, бетте баш, харап булдым мин! — дип белдерә.— Бүген бер мәҗлестә, әдәбият өлкәсендәге белдеклелегемне танытырга теләп, мин сезнең бер романыгыз сюжетын мактадым. Ә тыңлаучылар миннән көлделәр генә. Мин буташтырган булып чыктым, сезнең андый романыгыз юк икән бит әле!..

— Кәефең кырылмасын,— ди әдип һәм әкрен генә сорый: — Нинди сюжет турында сөйләдегез?..

Берничә көннән шундый сюжетлы роман шул эше пешмәс егетнең өстәлендә була.

Бүтәннәрне кысрыклау

Бер урта куллыдан да сәләтсезрәк шагыйрь Маяковскийга сорау бирә икән:

— Сез гәзитләргә бик күп нәрсә язып бер максатны күздә тотасыз — бүтән авторларны кысрыкларга телисез икән дип сөйлиләр. Дөресме?

— Әлбәттә! — ди Маяковский, уйлап та тормастан.—

Чөнки әгәр мин язмасам, гәзиттә сезнеке ише әсәрләр басылачак бит. Шуңа күрә дә гәзиткә язудан тыела алмыйм.

Санаулы минутлар тизлеге

Михаил Зощенко кирәк очракта чираттагы номерга дигән хикәяне санаулы минутлар эчендә язып бирә алган.

Көннәрнең берендә аны бер редактор редакциягә чакыра икән: «Номерыбыз яна! Хәзер үк килегез!»

Берничә минуттан соң әдип чакырткан янгын сүндерү машинасы редакция тарафларына юл ала икән.

Урындыклар җитмәс шул...

Бервакыт Ильф белән Петров янына сәләте бик чамалы, әмма үз-үзен бик яратып йөргән бер автор килеп керә.

— Ишеткәнемчә, сез биредә нindидер көлке нәрсә язып ятасыз икән. Урындыклар турында, имеш! Бәлки, миңа да сезгә кушылырга мөмкин булыр?

— Урындыклар җитмәс шул...— дип әйтәләр икән пардашлар иркен сулап.

Соңгы чара

Бразилиянең күп миллион халыклы Сан-Паулу шәһәрендә машина таптаган кешеләр саны бермәлне чамасыз күбәя. Чөнки «Автомобильдән сакланыгыз!» дигән бик күп язуларга җәяүлеләр күз дә салмый башлаганнар икән. Полиция бердәнбер чара итеп: «Җәяүлеләр, сак булыгыз, автомобильне таптавыгыз бар!» дигән плакатлар язып элгәч, урамдагы искәртү язуларына халык чыннан да игътибар итә башлаган диләр.

Газетка төрелгән пьеса

Александр Дюмага (улы) «Ярымяктылык» дигән пьесасына берничә төзәтмә кертергә тәкъдим итәләр.

— Кулъязманы бер генә көнгә өйгә алыйм, алайса,— ди автор театр директорына.— Ләкин аны берәр нәрсәгә төрәсе иде бит...— Шулай ди дә өстәлдә яткан газетаны ала.

— Газета бүгенге, мин әле аны укымадым. Тимәгез.

— Зинһар дип әйтәм, бирегез... Чөнки гаять кызыклы итеп һәм зур осталык белән язылган пьеса беренче булып төреләә бит аңа!

«Бергә яздык...»

Мәктәптә укыганда бертуган Гриммнар язган иншалары өчен бик еш икеле билгесе алалар.

— Ни өчен шулай бәялисез, укытучы әфәнде? — дип аптырый малайлар.

— Бер-берегездән күчереп язган өчен. Чөнки язганнарыгыз ике тамчы су шикелле охшаш була.

— Без күчереп язмыйбыз, ә бергә язабыз.

— Бергә? Әкият сөйләмәгез миңа!

Географиядән икеле билгесе

Бервакыт Магеллан географиядән икеле билгесе ала: чөнки картадан укытучы әйткән утрау белән култыкны табалмый. Укытучы аны дәрестән чыгарып җибәреп «җәзалый».

— Бар, эзлә, теләсәң ничек тап һәм аннары кереп әйтерсең миңа! — ди ачу белән.

Шулай тынычрак

Атаклы дирижер Артуро Тосканинидан:

— Оркестрыңда ни өчен хатын-кызлар юк? — дип сорыйлар.

— Беләсезме,— ди ул,— әгәр хатын-кыз чибәр булса, ул музыкантлар игътибарын үзенә җәлеп итәчәк, әгәр ямьсез кыяфәтле булса — минем кабынгалап китүем бар.

Җырлар патшасы

Италиянең атаклы җырчысы Катерина Габриелла әби патша Екатеринадан Петербургта ике чыгышы өчен биш мең дукат акча түләүне сорый.

— Мин үз маршалларыма да моңардан азрак түлим,— дип, каршы килә патша.

— Бик яхшы алайса, галиҗәнап, генералларыгыз җырласын да инде,— диелгәч кенә биш меңгә ризалаша Екатерина II.

Бер төрле үк шарт белән

Паганини, концертка соңгармас өчен, извозчик ялларга тиеш була һәм аның тизрәк баруын үтенә. Аннары күпме түләргә туры киләчәген дә ачыклый.

— Ун франк,— ди извозчик.

— Шаяртасыздыр?!

— Уйлаганым да юк. Сез бит менә бүген бер кылда уйнаган концертыбыз өчен һәр тыңлаучыдан унар франк алачаксыз.

— Ярый, яхшы алайса, унны түлим, ләкин театрга чаклы фаэтуныгызның бер генә көпчәге әйләнеп барсын.

Беркемнән сорамыйча

Бер яшь егет Моцарттан симфонияне ничек язарга кирәклеген сорый.

— Сез бит әле үсмерсез генә. Ни өчен баллададан башламаска ди?

— Ә сез бит ун яшегез тулганчы ук симфония язгансыз! — дип каршы килә егет дигәнебез.

— Әйе, яздым, ләкин бит аны ничек эшләргә кирәген беркемнән сорамадым!

Матбугат иреге

Россия буйлап җәяү йөргән елларының берсендә Максим Горькийны кулга алалар. Полиция начальнигы сорый икән:

— Сез чынлап та язучы Горький булсагыз, безгә нинди дә булса мәгънәлерәк бер вакыйга тарихын язып күрсәтегез. Аннары мин сезне иреккә чыгарам.

Горький яза, казематтан чыгарыла.

Берничә көннән үзенең шул хикәясе губерна газетасында басылып чыкканын күрә. Аның астына исә полиция начальнигы фамилиясе куелган була.

Ишекне үзегез ябарсыз

Испаниянең бер киноактеры Парижда кинога төшкәндә бер көнне кунакханәгә бик соң кайта. Йокымсырап яткан дежурный:

— Кем ул анда? — дип сорый аңардан.

— Хуан Родригес Веладо Перио-и-Тонсалес.

— Ярый, узыгыз, әмма иң арттан керүчегез ишекне яхшылап япсын.

Лондондагы чыгыштан соң

Гендельнең Лондонда беренче чыгышы уңышсыз уза. Әмма бу аны нигәдер бер дә борчымый сыман, тып-тыныч кыяфәттә әйтә икән ул таныш-белешләренә:

— Буш залда музыка матуррак яңгырый бит!

Әйтер сүзе булмагач

Яшь композитор оперетта музыкасы язгач, аны Дунаевский тыңлавын үтенә. Опереттаны тыңлый башлыйлар. Бер акт бетә, аннары икенчесе. Дунаевский исә ләм-мим сүз әйтми. Ниһаять, партитура уйналып бетә. Бүлмәдә киеренке минутлар башлана. Яшь егет композиторга, ниһаять, үзе сорау бирүне тиеш таба:

— Нишләп сез миңа берни дә әйтмисез әле болай?

— Чөнки бит сез үзегез миңа бернәрсә дә әйтмәдегез әле,— дигән җавап кына бирә аңа остаз.

Россини сәламнәре

Икенче бер яшь автор язган музыканы бөек Россини тыңларга риза була. Эшкә керешкәч исә ул нигәдер эшләпәсен тиз генә салып, шул ук минутта кия дә икән. Егет кызыксына, әлбәттә:

— Әллә сезгә бик эссеме, маэстро?

— Юк,— ди композитор,— шундый гадәт бар миндә, иске дусларым белән очрашканда һәрвакыт эшләпәмне салып исәнләшәм. Сезнең иҗатта алар күпләп очрады, шуңа эшләпәне бик еш салырга туры килде.

Ун булышчылы Одарка

Атаклы украин әдипләреннән берәү бервакыт бер хатын торган өйгә керә. Одарка исемле була ул. Өйдәге чисталык-пөхтәлекне күреп соклана язучы: балалары чиста юындырылган һәм киендерелгән, аш-сулары әзер.

— Шуларның бөтенесен эшләргә ничек өлгерәсез?

— Ничек өлгермәскә ди! Минем бит менә дигән ун булышчым бар. Ни кушсам шуны эшләргә, бер берсенә булышырга гына торалар.

— Нинди булышчылар соң алар?

— Менә күрегез! — дип елмая Одарка һәм өстәлгә кулының ун бармагын җәеп куеп күрсәтә кунакка.

«Тагын кулга алыгыз мине»

Көчәнеп булса да җырларга маташкан графоман корольнең тавышын яманлап сөйләгәне өчен атаклы бер музыка белгечен төрмәгә ябалар. Срогын тутырып чыккач «дәрәҗәле» автор аны тагын үзенә чакырта.

— Я, акыллы баш, минем иҗатым турында бу юлы нәрсә әйтерсең икән?

Белгеч авыр сулап куя һәм әйтә корольгә:

— Мине тагын төрмәгә япсагыз иде!..

Яхшысы яңа түгел, яңасы начар

Бер уртакул гына сәләтле яшь композиторның музыкасы белән танышкач, Ференц Лист әйтә икән аңа:

— Сезнең иҗатта яңалык та юк түгел, шактый бай да ул. Әмма, кызганычка, яхшысы яңа түгел, ә яңасы начар.

Ярату

Әдәби кичәсендә утырганнан соң Бернард Шоу, бик күп китап чыгарып та таныла алмаган бер язучының кулын кысып:

— Хуш, сау булыгыз! — ди икән.

— Бәй, сез минем белән бер хушлаштыгыз бит инде.

— Мин сезнең белән хушлашуны бик яратам шул! — дигән җавап бирә Шоу.

Таныш герой

Чарльз Диккенс бал-маскарадка чакырыла. Анда һәркем Вальтер Скотт әсәрләренең бер герое кыяфәтендә килергә тиеш икән. Ә Диккенс көндәлек, гадәти киемдә килә.

— Гафу итегез, сэр,— дип сорыйлар аңардан,— сез Скоттның кайсы герое булып киендегез?

— Бу геройны сез Вальтерның барлык романнарында очрата аласыз,— дип елмая әдип.— Ул — хөрмәтле укучы.

Әгәр теләсәгез...

Инглиз әдибе Клара Шеридан интервью алырга Америка журналисты килә. Әңгәмә вакытында шул зат,

онытылып китептерме, аягын өстәлгә куя һәм, гаебен тиз генә аңлап, гафу үтенә икән.

— Борчылмагыз,— ди аңа хуҗа,— теләсәгез өстәлгә дүрт аягыгызны да куя аласыз.

Казаннан еракта сөйләшү

Атаклы җырчы Шаляпин композитор Антон Эйхенвальд белән чит ил кафесында сөйләшеп утыралар.

— Казанда мин гаҗәеп бер кеше очраткам идем...— ди Шаляпин һәм карандаш алып шул яшь татар егетенең рәсемен ясап күрсәтә.— Ул бик шәп шигырь яза иде. Безнең Лермонтов кебек. Малай чагында ук диярлек үлеп китте. Нигәдер ул минем хәтергә читлектәге акчарлак булып кереп калган... Кызганыч, хәзер инде исемен дә онытканмын...

— Тукай ул! — ди Эйхенвальд.

— Дөрес! Тукай! Тукай!

Шунда Эйхенвальд Шаляпинга Тукайның «Су анасы» шигырен укып күрсәтә һәм Федор Иванович аңа:

— Син шуңа нигезләп опера язсаң иде! — ди.

Антон Эйхенвальд шул операны яза башлый. Үзе вафат булганнан соң, ул язмалар Глинка исемендәге музейга тапшырыла.

* * *

Атаклы украин әдибе Иван Котляровскийның тууына ике йөз ел тулу юбилее алдыннан була бу. Башлап язучы бер шагыйрь редакциягә шул бәйрәмгә багышлап язган шигырь китерә. Шуны укып чыккач газета хезмәткәре әйтә аңа:

— Шигырь бик йомшак һәм грамматик хаталары чиксез күп. Аны әйбәтләп төзәтегез. Һәм безгә әдипнең 300 еллыгы бәйрәменә китерерсез.

Шигырь авторы «Һичшиксез китерәчәкмен!» дип чын күңелдән ышандыра.

Марста кура җиләге

Үзенең соңгы лекциясен Циалковский Калуга аэроклубында үләренә ике ай калгач укый.

— Врачлардан качып килдем! — ди ул аудиториягә килеп кергәндә. Аннары кесәсеннән кульязма чыгара һәм курсантларның берсенә бирә:

— Шуны, зинһар, сез укыгыз, мин утырып тыңлап

торыйм, әгәр кирәк булса, аңлатмалар гына бирермен. Сезнең белән бергә булу миңа больница түшәгендә ятудан күңеллерәк.

Лекциядән соң очучылардан берәү аңа кычкырып әйтә:

— Бик күпне беләсез сез! Көнләшеп һәм сокланып туярлык түгел!..

Галим исә тыйнак кына сүзләр белән җавап бирә:

— Сез миңа түгел, киресенчә, мин сезгә сокланырга тиеш, чөнки сез мәктәптә һәм вузларда укып бик күп белем алдыгыз. Әгәр мин һәм Мичурин, мәсәлән, сезнең шартларда укыган булсак, һәр якшәмбе көнне Марска барып ял итәр һәм анда хәтта кура җиләге дә, карбыз да үстерер идек.

«Начар солых та... яхшы» *

Бервакыт Суворов барында сугыш хәрәкәтләре турында сүз чыга. Полководецны мактап аның алдында яхшатлы булып күренергә теләгән берәү шунда генералга сорау бирә икән:

— Сез галиҗәнапләрнең сугышны бик яратуы сөендерә мине!

— Аллам сакласын! — ди Суворов.— Шулай ук минем бөтен илдәшләремне дә сугышны яратудан алла сакласын! Минем бар теләгәнем һәм максатым — җирдә тынычлык булсын өчен сугышу, ә сугышта дан алу хакына тынычлыкны бозарга беркайчан да теләмәдем. Чөнки хәтта начар солых та яхшы талаштан яхшырак бит.

«Минем итекләр гаепле...»

Крепость салганда Суворов бер полковникка яңа ныгытмалар эшләтүне күзәтергә куша. Әллә ялкауланып,

* Сүз исеме бөтен дөньяга билгеле һәм атаклы полководец, заманында Россия армиясенең генералиссимусы Александр Васильевич Суворов турында бара. Чыннан да, әле үзе яшәгән заманда ук (1730—1800) халык аңа, чын күңелдән яратып һәм олылап, генерал Алга дигән исем таккан. Чөнки ул җитәкләгән яуларның берсендә дә (Очаков һәм Фокшан, Рымник һәм Измаил сугышлары, атаклы Альп походы) рус гаскәрләрен бер генә дошман да җиңә алмаган.

Суворов традицияләре, аның «Җиңү фәне» дигән китабында язганнары, хәрби стратегия һәм тактика принциплары, гаскәриләрне өйрәтү һәм тәрбияләү үрнәге — бүгенге Совет Армиясе өчен дә кирәкле көчле корал. Аның шулай ук халык үзе иҗат иткән «биографиясендә» дә бик күп легендалар, җырлар, күңеле хикәятләр, мәзәкләр һ. б. бар.

әллә инде вакытын кызганып, полковник моны үзеннән түбәнрәк дәрәҗәле бүтән берәүгә тапшыра.

Эш барышын карарга килеп, ныгытмалар тиешенчә төзек түгеллеген күргәч, Суворов полковникны бик каты шелтәли, ә полковник исә гаепне теге түбән чинлы өстенә аудармакчы икән.

— Ул да, син дә гаепле түгел,— ди Суворов һәм бер чыбык китертә дә шуның белән үз итекләрен кыйный башлый.

— Бүтән беркайчан да ялкауланмагыз! Үшән булмагыз! Барсына да сез гаепле! Әгәр эш урыннарында үзегез йөргән булсагыз, бернинди дә төзексезлек калмас иде!

«Биредән күккә чаклы ара күпме булыр?»

Суворов үзе сораганга «белмим» дигәнне яратмаган — «белмәмеш»лекне күралмаган ул, һәркемнең аңа төгәл һәм тиз җавап бирүен таләп иткән.

Берчакны гренадерларының берсеннән сорый икән:

— Менә биредән күккә хәтле ара күпме булыр?

— Аны узар өчен ике Суворов походы кирәк! — дип бик тиз җавап бирә тапкыр солдат һәм Суворов моңа бик канәгать була.

«Безнең полкка бу сүз билгесез»

Яшь кенә кавалерист офицерны туктата да кинәт сорый Суворов:

— Ретирада * нәрсә ул?

— Белмим бит,— ди офицер бер дә исе китмичә.

Суворовның күзләре уттай кабына, саксызрак бу кавалеристны усал сүзләр белән күмәргә әзер ул. Ә офицер һаман салкын канлы була биреп ашыкмыйча гына дәвам итә:

— Чыннан да белмим, Галиҗәнап, безнең полкка бу сүз билгеле түгел. Минем аны беркайчан да ишеткәнем юк!

— Шәп полк! Искиткеч әйбәт! — дип тантана белән һәм мөмкин хәтле кычкырып әйтә Суворов. Аннары шулай ук кычкырып көлә дә тирә-юньдәге барча сугышчыларга әйтә: — Рәхмәт яугыры белмәмеш мине бу хәтле куандырыр дип һич көтмәгән һәм уйламаган идем.

---

* Ретирада — чигенү.

ГЕРАКЛНЫҢ УНӨЧЕНЧЕ БАТЫРЛЫГЫ

(Бүгенге көннәр мифологиясеннән берничә гыйбрәт)

* * *

Атаклы батыр Геракл * тинтәк һәм дуамал патша Авгийның утыз ел буена чистартылмаган ат абзарларын бер көн эчендә чистартып бирә. Моның өчен ул Алфей һәм Паней елгаларын буа да шул сулар агымын эшкә җигеп пычракны юдырта.

Эше тәмамлангач, Гераклны патша үз кабинетына чакыра.

— Синең командировкаңа, әлбәттә, печать басам, Геракл, задание үтәлде, батырлыгың растыр. Даның үзең белән йөрсен — төрле легендаларга кер, гәзит-журналларда макталырсың, радио-телевидениеләр интервью алыр. Рационализаторлык тәкъдимең өчен сиңа тәңреләрнең бүләге бирелергә тиеш, бүтән абзарларны да шул ысул белән чистарта башларлар, инде танышым да буларак, алла колы, бу авторлыкка мине дә пардашың ит. Чөнки чистарту заказын мин бирдем бит сиңа. Нәрсә? Тыгылма һәм тагылма дисеңме? Акыллы бул, Геракл, дусларча хәл итик мәсьәләне!

Юк, Геракл соавторлыкка беркемне дә яздырмый. Шуңа күрә ул герой да. Аннары бит, Авгий хезмәтчесе дә түгел. Геракл аңа вакытлыча ялланып (субподрядчик булып) кына бер көн эшләде.

Ә әгәр хезмәтчесе булган булса?

Тантал газаплары

Тупас һәм дорфа Тантал * аллалардан көлә һәм шуның өчен Тартарга сөрелә һәм эле дә газап кичереп яши,

* Геракл һәм Тантал — мифология геройлары.

имеш. Берәр йотым су эчәргә дип ул иелсә — елгалар, инешләр чигенә, җимешләре кызарып пешкән куакларга үрелсә — алар кинәт үзләреннән-үзләре өскә-биеккә күтәреләләр, ди.

Кыскасы, менә күпме мең еллар инде Тантал шундый җәфа кичереп яши, ләкин үз маркасын барыбер тота белә икән. Тартарга килгән корреспондентларга, мәсәлән, үз язмышын болай аңлата:

— Әйтәсе дә юк, һәрвакыт ашыйсым да, эчәсем дә килә. Ләкин бит һәртөрле яманлыкның да ниндидер яхшы ягы була. Әгәр шундый кырыс диета белән тормасам, шул яшемә җитәр идемме мин?

Чарасын тапты

Зевс борынгы грекларның баш алласы була, шуңа күрә дә, күп башлыкларга хас булганча, кәефе кырылган чакларда үз ярдәмчеләренең кайберләрен пешекләштергәли дә икән.

Бервакыт, мәсәлән, шулардан берәве каршы сүз дә әйтеп ташлый аңа:

— Күкрәмә-яшьнәмә әле син болай. Синең ярдәмчең мин дә Олимп алласы бит, ник болай кызган табага бастырасың...

— Әйе шул, бераз кызып кителде бугай,— ди Зевс. Ярый, синең фикерне дә искә алырмын, нинди дә булса чара табылмый калмас.

Һәм табыла чара: әлеге ярдәмчене ул, штат кыскарту тәртибендә, алимпия аллалыгыннан азат итә.

УЙНАП ТҮГЕЛ, УЙЛАП...

*(Рус анекдотлары *)*

* * *

Үзенә бик күп акча түләгән шаһка алхимик яшәү элексиры бирә. Юкка шул хәтле акча әрәм итмәскә күндереп караса да, шаһны тыңлата алмагач, әлеге вәзир элексирны тота да үзе эчеп җибәрә.

— Мин сине җәзалап үтерергә боерам! — дип кычкыра шах ачудан ярсып.

— Галиҗәнабем,— ди аңа вәзир, — әгәр алхимик хаклы икән, бу мөмкин түгел, әгәр ул алдаган булса — җәзалауга мин лаек түгелмен **.

Уйнап түгел, уйлап

Иске заманда утарга алпавытның идарәчесе килә һәм ни сәбәпле керемнең азлыгын крестьяннардан сораштыра башлый.

— Ник быел акчалата керем бик аз?

— Уңыш начар булды.

— Ә сыерлар сөте кая китте?

— Май яздык.

— Майны нишләттегез?

---

* Әдәбият тарихында анекдот дип башта иске кулъязмалар яки тарихи затлар тормышыннан кызыклы вакыйгалар турында кыска хикәятләрнең беренче басмалары аталган (VI гасырда, мәсәлән, Прокопийның «Яшерен тарих»ы). Хәзер исә телдән сөйләнгән кыска һәм шаян хикәяләрне бик күп телләрдә анекдот дип йөртәләр. «Анекдот,— дип яза Валерий Брюсов,— бер укуда ук кыска һәм ачык эчтәлекле булып истә калырга тиеш...»

** Тоташ уйдырмалы, ялган җеп йомгагы төсле бу тезмә турында В. Брюсов, имештер, аны Михаил Лермонтов бик оста сөйләгән анекдот, дип яза.

— Саттык.
— Ә акчасы кая?
— Тоз сатып алдык.
— Ә тоз ник бетте?
— Майны тозладык.

Мул файда

Бер бабай базарда дару үләннәре сата. Алырга теләүчеләрдән берәү сорый икән аңардан:

— Файдасы бармы соң бу тамырлар белән бу кыякларыңның синең?

— Нинди генә файда әле, туганкай! Улыма «Жигули» машинасы алып бирдем инде, ә хәзер кызыма дача салып ятам.

Катгый куелган таләпләр

— Хәзер теләсә нинди гаиләнең дачасы бар. Ә ник без шуны булдыра алмыйбыз. Әйтик, әнә Семеннарныкы кебек кенәне булса да... Тәбәнәк кенә, бер катлы гына үзе, ә ике каты җир астында икән, гаражлары, сауналары, балыклар йөзеп йөргән бассейннары, чын шарлавык агып торган мәгарәсе дә бар, ди, шунда.

Хатыны катгый куйган бу таләптән ир, әлбәттә, аптырап кала: «Мин шарлавыкны яратмыйм»,— дип карый.

— Ярый, алайса, ә машина?! Ансыз бер генә танышыбыз да юк бит инде. Алыйк әнә Гергериләрне, «Запорожец»ка тягач моторы куйдырган, ди, шуңа тагып йөртә торган көпчәкле өе эчендә рәхәтләнеп йокларлык икән.

Сүз тәлпәктән башлана да...

— Беләсеңме, картым, кибеттә академиклар тәлпәге саталар. Барып үлчәп карамыйсыңмы? Минемчә, сиңа таман булыр кебек.

— Ә нигә кирәк ул?

— Ә ни өчен киләчәк турында уйламаска икән.

— Минем бит докторлык диссертациям дә язылмаган.

— Яз!

— Хәтта кандидат та түгелмен.

— Бул!

— Аның өчен минимум тапшырырга кирәк.

— Тап та тапшыр!!!

...Мин дәшмим. Ул да тына. Шулай да баш киемнәре кибетенә барып кайтырга дип өйдән чыгып тормыйча ярамас.

Көннәрнең берендә

Көннәрнең берендә:

— Күгәрчен сөте эчәсем килә! — дип тел тибрәтмәсенме хатыным.

— Каян алыйм мин аны? — дим аптырап.

— Әгәр чынлап яратса, кеше «каян алыйм?» түгел, ә «күпме кирәк?» дияр иде.

— Күпме кирәк? — дим мин дә салкын канлы булмавымны исбатларга теләп.

— Күпме табалганың хәтле. Ләкин баллоныбызның өч литрлысын алып чык. Кара аны, эчегән сөт бирә күрмәсеннәр.

Алай уңайсыз...

Бер ялкаудан сорыйлар:

— Нишләп син утынны утырып ярасың?

— Яткан килеп ярып караган идем дә — алай бик уңайсыз икән.

Алар бүлмә бит

— Миңа,— ди яңа йортны кабул итү комиссиясе председателе,— стенага уеп ясалган гардероблар бик ошый.

— Нинди гардероб булсын? — дип гаҗәпләнә архитектор.— Алар бит бүлмәләр.

Ау сезоны инде ябык бит

Берәү бөтен ау кирәк-яракларын күтәреп сунарга чыгып бара. Иптәше очрый да аңа сорау бирә:

— Ау сезоны инде ябылды бит. Кая китешең болай?

— Әкрен... Бу турыда минем хатын ишетмәскә дә, белмәскә дә тиеш.

Сәер сигнал

— Безнең искиткеч яхшы этебез бар. Өебезгә кем дә булса якын килә икән — шул минутта ук сигнал бирә.

— Өрә башлыймы?

— Юк, диван астына кереп кача.

Тавышланмый торган балалар

— Син ишеттеңме, кәбәм, балалар өчен бөтенләй тавышсез яңа коляска эшләп чыгарганнар, ди?

— И ходаем! Тавышланмый торган балаларны да тизрәк уйлап чыгара башласалар икән!..

Күршеләрегездән дә тәкъдим кирәк

— Мине хорда җырларга алсагыз иде, әни әйтә, син бик яхшы җырлыйсың, ди.

— Ләкин ул гына җитми,— ди хормейстер.— Күршеләрегездән дә рекомендация алып кил.

Будильник түгелме?

— Безнең местком кабинеты өчен бер сәгать алырга кирәк иде.

— Стена сәгатеме, әллә будильник кирәкме?

Тирәнәйткән...

Режиссер киносценарий авторыннан сорый:

— Хәзер инде сценарийны тирәнрәк итеп яңадан эшләгәнсез дип уйлыйм?

— Әйе, мин вакыйгада катнашучыларны шахтага төшердем.

Үтенеч

Ашханәдә бик озак көтеп тә бер савыт сыра эчә алмагач, берәү официантка хат язып өстәлдә калдыра: «Пенсиягә чыккан чагыгызда сезне алыштырасы кешегә әйтеп калдыра күрегез — ул миңа бер савыт сыра китерергә тиеш!»

Батырлык турында

Улының көндәлек дәфтәрен карый да аны үгетли икән атасы:

— Кызганычка каршы, мәктәптә сезгә батырлык очен билге куймыйлар, әгәр шундый билге булса син гел бишле алыр идең. Чөнки шундый көндәлекне атаңа күрсәтергә синең генә батырчылык итә алуың мөмкин.

Берүземме?

— Күреп торганымча, иптәш Сидоров,— ди мөдир,— сез эшкә иң соңгы кеше булып киләсез, ә эштән беренче булып китәсез.

— Мин бит берүзем иртән дә, кичен дә соңга кала алмыйм инде.

Киләчәкне кайгыртып

Бер ир ике пылесос алып кайта.

— Нишләп һәр нәрсәне ике данә аласың әле син болай? — дип сорый хатыны аптырап.

— Аерылырга туры килсә дип шулай тырышам.

Чөнки... өйләндем

— Синең машинисткаң бар иде бит, нишләп хәзер машинкада үзең сугасың?

— Чөнки шул машинисткага өйләндем.

Шелтә сүзе

Хатыны кибеттән уклау алып кайткач, ире аны шелтәли башлый:

— Акылдан яздыңмы әллә? Өйдә эчәргә бер тамчы нәрсә юк, ә син мебель ташыйсың!

Дөрес сукмау

— Чүкеч белән бик тә оста эш итәсең икән бит син! Хәтта чын яшен бу дип әйтергә була үзеңне.

— Шул хәтле тиз суккалыйммыни?

— Юк. Бер үк урынга икенче тапкыр суга алмыйсың.

Алтынчысы да бар

— Котлыйм сезне,— дип әйтә бала тудыру йортының медсестрасы, бик тиз йөгереп чыгып: — Җиденче малаегыз бар!

— Сез, бәлки алтынчы малаегыз туды дип әйтергә телисездер?
— Әйе, әлбәттә... алтынчысы да бар...

Талымсызлык

Утильгә дип җыйган тимер-томыр өеме янында йоклап яткан сәрхушне күргәч берәү:
— Булса да булыр икән шундый талымсыз хатыннар — әзмәвердәй ирен утильгә тапшырган бит,— дип әйтә икән.

Телефон... һич бушамагач

Командировкадагы бер ир өенә шалтыратып көн буе азаплана — ләкин телефоннары һич буш булмый. Түземе калмагач, хатынына ул телеграмма суга: «Телефон трубкасын урынына куй әле!»

Ярый, үзем ыңгырашырмын

Башы бик каты авыртканга бер ханым йоклый алмый һәм ирен уятырга мәҗбүр була.
— Мин шул хәтле ыңгырашканда ничек йоклый аласың?
— Ярый, яхшы, хәзер син йокла, ә мин ыңгырашырмын.

«Мин өйдә түгел»

Бер күрше керә дә:
— Иван, син өйдәме? — дип сорый.
— Юк, мин өйдә түгел,— ди йокымсырап яткан хуҗа.
— Әнә бит галошларың бусага төбендә тора, ничек инде син өйдә юк?
— Ә мин яңа галошларымны киеп киттем.

Бишек җыры тыңла...

Танылган врачка төнлә нииндидер бер кыз шалтырата:
— Нишләргә дә белмим, доктор, йокы алмый. Берәр киңәш әйтмәссезме?
— Моны эшләп була, балакай: трубканы колагыңнан алма, хәзер мин бишек җыры көйли башлыйм.

Иртэ чыгарга соң иде...

— Ник соңгардың?
— Өйдән соң чыктым.
— Ә ник иртәрәк чыкмадың?
— Чөнки иртә чыгарга соң иде инде.

Белмәмешкә салыну

Әзмәвердәй дүрт ирне бер хулиган куып бара.

— Ник качасыз, сез дүртәү бит? — ди шуны күргән бер әби.

— Шулаен шулай да бит, ә без аның кайсыбызны куганын белмибез.

Тагын... тагын

Ишек шакыйлар. Хуҗа хатыны аны ача һәм теле бәйләнгәнрәк бер абзыйны күрә.

— Тәрәзә ю-ю-у-у-чы чакырдыгызмы?
— Әйе, рәхим итегез.

Берничә минуттан тагын ишек шаку һәм тагын:

— Тәрәзә ю-ю-у-у-чы чакырдыгызмы?
— Әйе, рәхим итегез. Анда сезнең бер иптәшегез эшли дә инде.
— Ю-ю-к, тәрәзәдән егылып төшүче ми-и-н ул.

Ватылмый торган уенчык

— Малайга «ватылмый торган» уенчык алырга син киңәш бирдеңме? Син!
— Нәрсә, әллә ваткан дамы уенчыкны?
— Ул аның белән бәрдереп уникe кешелек сервизны ваткан.

Кит балыгын белмисезме әллә?..

— Ник син суда йөзү кешене ябыктырмый дип уйлыйсың?
— Гомер буе суда йөзгән кит балыгын белмисеңме әллә?!

Йоклаганда... эчә алмау

— Юк, рәхмәт, коньяк эчкәч мин йоклый алмыйм.
— Ә мин йоклаганда эчә алмыйм.

Тапсагыз — бирерсез

— Мин сезнең кибеттә акчалы янчыгымны калдырганмын.
— Күрмәдек. Белмибез.
— Әйбәтләбрәк карагыз әле. Тапсагыз — миңа бирерсез.
— Әгәр табылмаса?
— Миңа бер янчык акча бурычлы булырсыз.

Шуңа күрә әйтә дә атаң

— Бүген синең иң бәхетле көнең, улым!
— Нишләп, әти, бүген? Мин иртәгә генә өйләнәм бит әле.
— Шуңа күрә әйтәм дә.

Ярәшүнең сере

— Хатыным белән мин бик пар килеп ярәштем.
— Ничек?
— Төннәрен мин бик каты гырлыйм, ә ул — чукрак.

Күрше үтенече

Күрше бүлмәдә торучы ишек шакып керә дә үтенечен белдерә:
— Гафу итегез, радиогызны ярты минутка гына булса да туктатып торалмассызмы икән? Хатыным колагына бер-ике авыз гына сүз пышылдыйсым бар иде.

Повар түгел... итекче

— Безнең бифштекс сезгә ошадымы?
— Һөнәр иясе буларак шуны әйтә алам: искиткеч яхшы материал.
— Әллә сез повармы?
— Юк, итекче...

Әле взносы түләнмәгән...

— Бер утыруда әллә күпме нәрсә эчтең. Ә үзең эчмәүчеләр җәмгыятендә член икәнсең бит.
— Әйе, членмын шул. Ләкин бу айда әле минем членлык взносларым түләнмәгән.

Ни өчен уң аягым гына?

— Доктор, бер аягым сызлап интектерә мине.
— Картлык галәмәте ул...
— Алай булуы мөмкин түгел. Чөнки минем ике аягым да бер яшьтә бит, ә ни өчен уңы гына сызлый, алайса?

Кирәкле китап югалгач

— Ник елыйсың, бәләкәчем?
— Әнием «Балалар психологиясе» дигән китабын югалткан да хәзер мине үзе белгәнчә тәрбияли.

Кыюлык җитмәү

— Әти-әниләргә хатыннан аерылуым турында әйтергә кыюлыгым җитми.
— Нигә?
— Чөнки алар минем өйләнгәнемне белмиләр иде...

Дәшми торырга өйрәтү

— Сезнең балагыз сөйләшәме әле?
— Әйе. Хәзер без аны дәшми торырга өйрәтәбез инде.

Йөзсә соң...

— Официант, минем сырамда бер чебен йөзә!
— Йөзсә соң! Әллә аңа суда батырмый торган резин капчык бирүне теләр идегезме?

Докторга сорау

— Зинһар дип әйтәм, дөресен аңлатыгыз әле миңа, доктор. Кулы шулай бик каты сынгач, минем ирем кайчан да булса савыт-саба юа алырмы инде?

Сәбәбен әйтте

— Нишләп син болай бик күңеллесең әле?
— Чөнки теш докторына бардым, ә аның исә бүген ял көне икән.

Эшкә кергәндә

— Хезмәт кенәгәгездән күренгәнчә, сез эш урынын бик еш алмаштырасыз икән. Менә соңгы урыныгызда, мәсәлән, күпме булдыгыз?

— Әйтә алмыйм, чөнки янымда сәгатем юк иде.

Ялгыш уй

Хуҗабикә үзендә фатирда торучы кызның ишеген шакый.

— Нишлисез сез?

— Скрипка уйныйм ич.

— Ә мин караватыбыз аякларын кисәме әллә дип уйладым. Гафу итегез.

Шаһитлар кирәк

— Лида, син мине яратасыңмы?

— Әйе, бик яратам...

— Шулай булгач иртәгә загска килүеңне үтенәм. Без Маша белән язылышабыз — шаһитлар кирәк.

Нәрсә булды?

— Син ник эшкә килмисең?

— Чирлим.

— Нәрсә булды?

— Бюллетень алдым!..

Пешекчеләр мәктәбендә

Укытучы укучыга сорау бирә:

— Шеф-повар кем була?

— Бер котлетка егермедән артык исем уйлап таба белүче кеше.

Ялгышасыз

— Алло, бу Ивановлар фатирымы?

— Сез ялгышасыз. Безнең өйдә телефон юк бит...

Үкчәсеннән... төньяктарак

— Кай җиреӊ авырта? — дип сорый врач география укытучысыннан.

— Аягым.
— Ә кай төше?
— Үкчәмнән төньяктарак җире.

Әллә кызыңа да утыз тулдымы?

Инде утыздан узган егеткә очраган саен берүк сорау бирә икән күршесе:
— Кайчан өйләнәсең соң инде син?
Шул бәйләнчектән котылыр өчен әйтә икән егет дигәнебез:
— Әллә синең кызыңа да утыз яшь тулдымы?

Ашыгыч сөйләшү

Вокзал ресторанында бик ашыгыч шундый сөйләшү булып ала:
— Кәтлитегез ник болай бик кечкенә?
— Зурысын бирсәк, поездга утырырга соңгарырсыз дип курыктык.

Биш балам юк ич әле...

— Улым, ник болай бик кыйммәтле сигаретлар гына тартасың әле син? Менә мин гел арзанлыны гына суыргалыйм бит!
— Синеке кебек биш балам булса, мин бөтенләй тартмас идем, эти!

Ник башта ук әйтмәдең?

— Иптәш милиционер, әнә тегендә күптән инде берничә кеше кыйнаша.
— Ә ник син моны башта ук әйтмәдең?
— Чөнки моңарчы минем эти өстә иде...

Чәнечкеле сорау

Бер композитор бик якын таныш драматургны яңа операсын тыңларга чакыра. Ә драматург исә, премьера тыңлаганда, берөзлексез елмаеп утыра икән.
Ачуыннан җеннәре чыга язган композитор бик оста чәнечтереп аңа сорау бирә:
— Нәрсәдән көлеп утырасың әле син болай? Синең комедияләрне караганда мин елмайганны кайчан да булса күргәнең булдымы әллә?

Хикмәте бар икән

— Шундый гап-гади эт өчен җитмеш сум алырга телисезме? Аның бит әнә күзендә дә зыян бар — һаман йомгалап тора!

— Хикмәтен белсәгез иде сез моның: бик арзанга сатма дип, миңа күз кыса, мине искәртә ич ул.

Кем нәрсәгә карый

— Өйгә соңга калып кайтсам, минем хатын сәгатькә карый.

— Ә минеке — календарьга.

...Юләрме әллә мин

Бер бабай, калкавычына карап, яр буенда утыра. Шул тирәдән узып барган бер ханым:

— Ничек соң, бабакаем, берне булса да эләктердеңме инде?

— Бер балык кына эләксен өчен көннәр буе калгып утырырга юләрме әллә мин...

Әҗәт сорау

— Сез Кызыл Хач курсларында укыгансыз һәм кешегә беренче ярдәм күрсәтә беләсез икән. Хакмы бу?

— Әйе.

— Алайса, миңа бурычка ун сум акча биреп торыгыз әле.

Эсседән курку

— Эссене ничек кичерәсез, кояшта озак йөрүдән курыкмыйсызмы? — ди башлык үзенең кытыршырак холыклы бер хезмәткәренә.

— Куркам һәм ярамый миңа эсселек...

— Аңлашылды: отпуск сорап декабрьдә генә гариза язарсыз.

ИКЕ ЙӨРӘКЛЕ КЕШЕ*

Винтның сыры төшеп калган

Берәүнең хатыны газ баллонына кибеттән яңа редуктор алып кайта. Ире шуны баллон башына борып куялмыйча азаплана икән.

— Нәрсә алдың син?.. Винтының сыры юк бит.

— Бора белмисең икән — азапланма. Әнә күрше кереп борыр әле.

Бәхәснең зурга китәсен сизенгән каенана йомгаклый сүзне:

— Күрәсеңме инде, бичәң нинди ачык авыз икәнен. Резьбаны кайтканда төшереп җуйгандыр, ахрысы...

Ялгыш җыелган номер

Телефон будкасына кергән бер ханым чамасыз озак чыкмый тора. Автоматка чират зурайганнан-зурая икән. «Чама белергә кирәк!» — дип, будканы шакый ук башлыйлар. Ә тегенең исендә дә юк. Киресенчә, кулындагы трубканы кабинадан сузып тыныч кына белдерә:

— Тиешле номерны җыймаганмын... Менә бу 2—79—49 кемгә дә булса кирәкмиме?

Ике йөрәкле кеше

— Ишеттеңме искиткеч яңалык? Явтушның йөрәге ике икәнен белгәннәр бит!..

— Кит әле!.. Аны, алайса, фәнни-тикшерену институтына алырлардыр инде!

---

* Украинчадан.

— Нинди институт ди шуңа?.. Милициягә алганнар инде, икенче йөрәге — үзенеке булмаган. Комбинат проходноеннан чыкканда сумкасыннан тапкач белгәннәр...

Гади арифметика

— Бу бозауга ничә яшь инде? — дип сорый каладан килгән кунак ханым авылда.

— Өченче ел туган иде. Димәк, ике яшьтә була,— ди көтүче.

— Ә терлек-туарның яшен ничек беләсез соң?

— Мөгезеннән.

— Ә-ә-ә! Әйе шул, әйе... Мин аның ике мөгезле икәнен күрми дә торам тагын.

Кайсы яхшырак?

«Бүген клубта лекция, аннары танцы» дигән белдерүне укыганда ике кыз аңлаша:

— Әллә чынлап та лекция тыңлыйсың киләме?

— Әйе шул, чөнки бу лектор бик оста биюче диләр.

Сәгать нульләрне сукмый...

Чәукә шулпасын шактый авыз иткән бер абзый өенә кайткач, хатыны сорый икән йокы аралаш:

— Вакыт күпме инде хәзер?

— Йокла, йокла, карчык, сәгать ун.

— Нигә ялганлыйсың, берне сукты ич инде?!

— Әллә син аңардан нульләрне дә суктырыр идеңме?..

Буш өстәл

— Сезнең диета өстәлегез ник гел буш тора?

— Ашка йөрүче юк. Берәү бар иде — аны да бездән үк больницага алып киттеләр.

Серен ачты

Өенә күрше агай килеп керүгә бер сәрхуш әрәмтамак ашавыннан кинәт туктый да алдындагы табагын куллары белән каплый.

— Ник капладың савытыңны, матурым?

— Ашап туйганымны белсеннәр өчен.

— Күр син аны, шундый галәмәт тә бармыни. Ә мин чучкабызның буш тагаракны ник әйләндереп каплаганын белми идем бит әле...

Бик яхшы...

— Әтисе, бүлмәләрне җыештырышырга булыш әле миңа.

— Булдыралмам, карчык. Башым бик каты чатнап авырта һәм нигәдер кулларым калтырый.

— Алайса, бик яхшы: әнә идән җәймәләрен урамга алып чыгып как.

Поп белән гәп

Тегүче белән сөйләшә бер поп:

— Мин шундый бер тинтәк затны беләм — башта ул бер бөтен тирене кискәләп ташлый, аннары шуларны берсенә-берсен тегә.

Тегүче исә уйлап тора-тора да үзенекен әйтә:

— Ә мин шундый бер акылсыз адәмне беләм: кем дә булса үлсә, бөтен кешеләр елыйлар, ә бу адәм нәрсәдер көйли башлый.

Чылатылмаган аш

— Саулыгыгыз ничек хәзер, бабай?

— Рәхмәт, яхшы хис итәм үземне.

— Аш үтәме?

— Бүген ярты кило ит һәм чирек кило чамасы сало ашадым.

— Аппетит беләнме?

— Юк, аш алды дигән нәрсә булмады шул.

Бергәлек

— Шайтан белсен, нишләп ятасыңдыр өйдә! Тагын әбәт әзерләмәгәнсең бит. Ресторанга китмичә нишләргә кала миңа! — дип ярсулы ачу белән кычкыра ир.

— Бер генә минут көт, алтыным,— дип тасма телләнә хатыны.

— Нәрсә, әбәт буламы?

— Юк, хәзер тиз генә киенәм дә ресторанга бергә китәбез.

Булышу

Таң алдыннан берәү тәрәзә шакуга йортка чыга хуҗа.

— Саумысыз! Зинһар, миңа булышыгыз әле: базарга алып бара торган чучкам олаудан сикереп төште, шуны күтәреп салышсагыз иде.

Ике ир моны бик тиз эшлиләр һәм олаучы, рәхмәт әйтеп, тиз-тиз китеп тә бара.

Иртә белән хуҗаның хатыны үз чучкаларын ашатырга абзарга керсә, анда иң дәү чучкадан җилләр искән була.

Кунак кына булмасын...

Бер өйдә кемнеңдер туган көне бәйрәм ителә. Табынга бөтен авыл кешеләре диярлек җыела икән. Һәм бәйрәм атна буе диярлек дәвам итә. Ниһаять, кунаклар таралышып беткән көнне хуҗабикә төнлә ирен уята икән:

— Әтисе, ишетәсеңме, кемдер өйгә керергә маташа түгелме? Карак була күрмәсен...

Хуҗа икенче ягына әйләнеп ята да әйтә шунда:

— Йоклый бир, әйдә! Карак — куркыныч түгел ул. Кунак кына булмасын.

Банкыдагы помидорлар

— Бу иптәшнең битенә помидорлар аттыгызмы? — дип сорый судья гаепләнүчедән.

— Аттым.

— Ә ни өчен аның башы күгәргән?

— Чөнки помидорлар банкыда иде.

Таныш өй

Иван дәдәй салам төягән олауга утырып кырдан кайтып килә. Аты урамга кереп бераз баруга, бер йорт алдында кинәт бик текә борылыш ясаганда, ул олау башыннан ничектер мәтәлми калуына хәтта үзе дә аптырый.

— Әй, каһәр суккан җан, нишләвең бу? — дип, атны бик каты чыбыркылап та ала хәтта.— Хима түтәң самогон сатып яшәүче спекулянт булганы өчен колониягә озатылды бит инде, ә син һаман әле шуның өе каршына барып туктамый узалмыйсың, үләт төшкере!

Бәлки галәм белгече булыр

— Безнең улыбыз көннәр буе караватта аунап тәрәзәгә карап ята,— дип зарлана Гапуля түти.— Белмим, кайчан кем була алыр икән ул бәндә?

— Бәлки метеоролог булырга җыенадыр.

Өч бәягә сатачак

— Шул хәтле азынып оятсызланды спекулянтлар соңгы елларда. Кешенең өч кат тиресен тунарга әзерләр,— дип, базардан алып кайткан йон күлмәген караштыра бер агай.

— Соң ник алардан алдың соң?

— Ничек ник? Күршеләргә моны мин өч бәягә сатачакмын.

Ялган акча

— Дөньяның хәзерге үзгәрешләренә исләрем китә минем, кәбәм. Кешеләр берсен-берсе ничек тә булса алдарга гына торалар... Кичә калада ниндидер бер шалапай миңа егерме биш сумлык ялган акча тоттырган.

— Я, күрсәт әле миңа шуны, күгәрченем, белим әле мин дә, нинди була икән ул ялган акча дигәнең...

— Юк инде ул миндә хәзер — кибеттә ситсы өчен түләп кайттым бүген.

Ике фокусчы

Авылга фокус күрсәтергә килгән берәү белән сөйләшә колхоз председателе.

— Безнең хуҗалык — хозрасчетлы, быел менә кәрәкә балыгына дип комбикорм алабыз да шуның белән чучкалар симертәбез.

— Чучкалар? Башыма сыймый минем бу нәрсә.

— Чучкаларны иткә тапшырып акча алабыз.

— Ә балык нишли?

— Ит акчасына уылдыклы кызыл балык алабыз. Менә сиңа балык. Уылдыклы балыкны планга тапшырабыз, ә уылдыгын кыслага алыштырабыз...

— Аңладым,— ди артист.— Минем фокуслар сезнекенә караганда пустяк икән әле.

Кем кайда эшли

Берәүнең бөтен йорт-җир тирәсе асфальтланган. Капка баганалары — тимер-бетоннан. Нәүрәбе — цемент плитәләрдән эшләнгән икән.

Көннәрнең берендә аңа иске танышы килеп керә һәм туп-туры сорый хуҗадан:

— Әллә син һаман юллар салу бригадасында эшлисеңме?

— Каян беләсең?

— Йорт-җиреңә әйтеп тора.

— Ә син үзең, күрәм, табигатьне саклау эшендәсең?

— Ничек белдең?

— Башыңдагы бүрегең бурсык тиресеннән ич.

Ашханәдә сөйләшү

Ике ир ашханәдә сөт эчкәндә сөйләшә:

— Исләрем китә, валлаһи. Бүген сөт гомердә булмаганча куе һәм тәмлерәк.

— Моның өчен мине мактарга кирәк.

— Әллә сез биредә эшлисезме?

— Юк, мин сантехник-слесарь.

— Ә сөткә нинди катнашыгыз бар соң?

— Турыдан-туры. Пешекчеләр сөт кайнатыр алдыннан су краннарын томалап куйдым.

АРАКЫДАН АКЫЛ КИМИ

*(Белорус мәзәкләре *)*

Белгәннең башы авыртмый

— Белгәннең башы авыртмый икән бит.
— Әйтәм, безнең Микола институтка өченче тапкыр керә инде...

Ник саталар?

— Аракыдан акыл кими, агай-эне. Фән шулай аңлата.
— Алайса, ник аны саталар?
— Нәрсәдән куркырга кирәклеген барча кешеләр дә белсен өчен.

Үпкәләтмәс өчен...

— Син урыныңны ник ханым кешегә бирмәдең?
— Мине әбигә санады дип үпкәләтмәс өчен.

Үзе тапкан чир

— Кая барышың? — дип сорыйлар бер йокы чүлмәгеннән.
— Поликлиникага.
— Чирләдеңме әллә?
— Әйе! Нигәдер ян-якларым авырта.

---

* Белорус халык иҗатында алар күпчелек очракта сатира-юмор персонажлары Мирутка бабай белән Патап Чамярыца исеменнән сөйләнелә.

Логикалы җавап

Кухняда ир белән хатын аңлаша:

— Әйт әле син миңа, каян килә бирегә бу хәтле шешә?

— Ә мин каян белим? Өйгә буш савыт алып кайтмавымны бит үзең бик яхшы беләсең.

Килешмә

— Әнием, туебыз шаулап узгач та ирем мине кулына гына күтәреп йөртергә вәгъдә бирә.

— Килешмә, риза булма, кызыкаем. Сразы автомашина алуын даула.

Хатын гаепле

— Үткән җыелышта сиңа хатының аркасында йөз кызартырга туры килгән дип сөйлиләр, дөресме бу?

— Булды шул... Узара ярышта ул миннән уздырды.

Вак-төяк төзәтүләр

— Рыгор, сез сөт заводын салып бетердегезме?

— Беткәненә бер ел инде.

— Ә хәзер син кайда эшлисең?

— Сөт заводында.

— Әллә төзелештән киттеңме?

— Юк, китмәдем, әнә шул үзебез салган сөт заводында вак-төяк төзәтүләрне эшләтәләр әлегә.

Кайда үсәсең?

— Әти, син өйдә генә үсәсең икән. Бу дөресме?

— Каян алып әйтәсең әле моны син?

— Әнием бер апайга шулай диде: «Ул эштә бер дә үсә алмады шул...»

Ремонт өчен

— Күпмегә алдың бу яңа ботинканы?

— Унсигез сумга.

— Ә мин нәкъ шундый өчен унбишне генә түләдем.

— Минем өч тәңкәне ремонт өчен алдылар.

Киңәш итә

— Кара син аны, әле берничек тә белми торып, инде миңа өйләнмәкче...
— Үзеңне ул яхшылап белеп өлгергәнче, ашыгырга кирәк сиңа.

Оялма, имеш

Берәү трамвайда күзен тәрәзәдән алмыйча урамга карап бара. Шуны очраклы күргән танышы аңардан сорый икән:
— Нишләп әле син болай баш та бормыйча гел читкә карап барасың?
— Кешеләр өчен шулай оялам: энә янымда бер карчык басып тора, шуңа һичберсе урын бирми генә бит...

Үзе гаепле

— Пилип!
— Пилип түгел, ә Пилип Петрович!
— Пилип Петрович, беләсеңме...
— Беләсеңме түгел, беләсезме!
— Беләсезме, Пилип Петрович! Синең...
— Синең түгел, сезнең!
— Пилип Петрович, беләсезме, сезнең сыерыгыз үлеп ята бит.
— Нәрсә? Ах син, шайтан алгыры, ник шуны башта ук әйтмәдең!..

Үз икмәкләре

— Синең улларың укыйлармы әле, әллә инде үз икмәкләрен ашый башладылармы?
— Ничек әйтим инде. Икмәк үзләренеке, ә акча... һаман әле минем кесәдән.

Медицина тыя

— Әллә тәмәке тартмыйсыңмы инде?
— Медицина тыйды шул.
— Чирләдең, димәк?
— Юк, сау-таза мин. Беренче хатыннан соң шәфкать туташына өйләнергә туры килде.

Атларга да иренә

— Минеке шикелле ирне кулга гына күтәреп йөртергә кирәк.
— Шул хәтле яхшымы?
— Кая инде ул! Аяк атларга да иренә торган булып чыкты.

Нигә болай уфтанасың?

— Син нәрсә болай уфтанасың әле, Трифон!
— Ничек уфтанмыйсың ди, утыз биш баш чучка баласы юкка чыкты бит.
— Кайчан? Ничек?
— Синең малайны өйләндергән туйда.
— Нәрсә әйтергә теләвең бу?
— Әйтерлек ул хәтле зур сүзем юк, иртәгә минем кызым кияүгә чыгасын гына белдермәкче идем...

Саклык кассасында очрашу

— Эшләрең харап бит, иптәшкәй, синең. Кешеләрдән ришвәт алып, шуны саклык кассасына саласың икән дип сөйлиләр. Бу бит бик зур әшәкелек!
— Кызма әле юкка, кызма, ахири, ул акчаны минем хатын үз кенәгәсенә сала.

Утыз тиенгә машина!

— Лоторея билеты сатып алыгыз. Утыз тиенгә автомашина ота аласыз.
— Юк инде, гафу итәсез. Теге юлы да шулай дигән идегез, ә миңа бары тик мотоцикл гына чыкты.

Кыенлыклардан курыкмау

Бер төркем ялкаулар, үз җыелышларында түбәндәгечә карар кабул итәләр: «Эшсез яшәве кыен әлбәттә, ләкин без кыенлыклардан курыкмыйбыз!»

Элек сигез булган...

— Сезнең авылга чаклы ничә чакрым?
— Элек сигез иде. Хәзер багана утыртып, шуңа «ун» дип яздылар. Менә хәзер ике чакрым артыграк атла инде.

Ягылмаган мунча

— Безгә берәр кызык нәрсә сөйлә әле, Микола дәдәй! — дип бәйләнә ике малай авылда чиксез җор мәзәкче саналган абзыйны очратып.

— Вакытым юк. Мунчам узган, шунда ашыгам. Килегез, бергә юынырбыз да.

Малайлар җыенып киләләр. Ә мунча бөтенләй ягылмаган булып чыга. Микола дәдәйнең анда эзе дә күренми.

АБУТАЛИБ ӘЙТӘ*

Әшеннән алынгач

Берәүне башлык булып эшләгән урыныннан алалар. Бераздан Абуталиб аның белән туйда очраша. Эшеннән азат ителгәнче үзен бик әре тоткан шул кеше туй бәйрәмендә көн буе диярлек җырлый, бии, шаяртып сөйли икән. Абуталиб әйтә:

— Күр аны, менә нинди яхшы кеше ничәмә еллар урын биләп кенә түгел, әрәм булып та яткан бит.

Шигырь язган актер

Бер уртакул актер шигырьләр яза башлый һәм хәтта җыентык та чыгарып өлгерә. Абуталиб әйтә:

— Ул шагыйрь булып уйный. Ләкин, сәхнәдә бөтен рольләрен дә шулай башкарганча, бик начар уйный.

---

* Дагстанның лак шагыйре Гафуров Абуталиб (1882—1975) сөйләгәннәрне Расул Гамзатов язып алган китаптан.

Аңлашылмау

Абуталиб бервакыт аның канына бик күп тоз салган нәшир белән очраша һәм әйтә:

— Карале, син шактый картайгансың бит. Чаларгансың.

— Соң, Абуталиб, үзең дә чал бит инде.

— Мин синең аркада шулай картайдым, ә сиңа чал керүе ничектер аңлашылмый.

Ник киресенчә икән?

Әсәрләрен бик чамалы сыйфат белән генә язган шагыйрь урамнан бик матур кыз белән уза. Шунда әйтә Абуталиб:

— Мәхәббәттә уңмаганнар бик яхшы шигырь яза. Ә шигырь яза белмәүчеләр әнә мәхәббәттә уңа күрәсең.

Кем белән ничек сөйләшергә?

Осталык турында сүз бара. Абуталиб әйтә шунда:

— Билгесез, кечкенә, танылмаган кеше турында җентекләп һәм матур итеп сөйләргә кирәк. Ә ялтырап күренгән берәр атаклыга карата бер-ике сүз әйтү дә җитә.

Осталык искерми

Яшь язучылар киңәшмәсендәге бер чыгышында әйтә Абуталиб:

— Мин, әлбәттә, күптән тудым. Сезнең әбиләрегез ул чакта сабый кызлар гына иде әле. Шуңа күрә минем хакта сез үзе дә картайды һәм фикерләре дә искерде инде дип әйтергә хаклы. Әмма кешенең нәрсәгәдер сәләте, осталыгы искерә алмый. Ишәкне тыңлата белү автомашина йөртүдән кыенрак. Ватылган тәлинкәне төзәтү электр чыбыгын ялгаудан күп авыр. Дүртьюллык шигырь яза белү су буе сузылган тәнкыйть мәкаләсе язудан кыенрак.

Яңа спектакль карагач

Яңа спектакль куелганнан соң аңа ошаганлыгын белергә телиләр. Абуталиб әйтә:

— Дүртенче акт бик әйбәт иде.

— Ә бит спектакльдә өч кенә акт уйналды.

— Ничек? Ә банкет!

Язмас өчен шартлар

Бер әдип дәрәҗә һәм орден ала, аны берничә урында эш башына куялар. Шунда Абуталиб әйтә:

— Хәзер сиңа инде бернәрсә дә язмас өчен бөтен шартлар да тудырылды.

Тәнкыйтьчеләр турында

Тәнкыйтьчеләр турында фикерен дә бик җыйнак итеп әйтә Абуталиб:

— Бөтен яктан яхшы халык, ләкин шаяруны аңлый белмиләр.

Күзгә бәреп әйтү

Бер яшь авторга карата Абуталиб әйтә икән:

— Аңардан шагыйрь чыкмастыр кебек. Чөнки беренче шигырьләрен редакциягә машина белән китергән.

Сәер җавапка җавап

Сакал үстергән бер шагыйрь егетне күргәч әйткәне менә нәрсә була Абуталибның:

— Карале, бу сакал сиңа ниемә кирәк?

— Лев Толстой да сакал йөрткән ич.

— Лев Толстой булуның шулай бик җиңел икәнен ишеткәнем-белгәнем юк иде әле.

Ишәккә атланганың бармы?

Бер яшь шагыйрьне әдәбият институтына укырга озаталар. Ул инде самолетка утырырга җыенганда уфылдап чапкан Абуталиб килеп җитә:

— Ашыкмагыз әле хушлашырга, аңа соравым бар! — ди.

Бөтенесе аңа юл бирәләр. Яшь шагыйрь янына килгәч, ул:

— Синең бер генә тапкыр булса да ишәккә атланганың бармы? — ди.

— Юк.

Абуталиб әйтә шунда:

— Буш хыял бу. Әле ишәккә дә атланмаган кешедән тау халкының чын шагыйре барыбер чыкмаячак.

Яхшырак булуны теләү

Бер шагыйрә, шигырьләрен тәнкыйтьләгәннән соң, ду кубып җәнҗаллаша икән. Абуталиб әйтә аңа:

— Һәр каенана да үз кызының кияве. Ул инде тиенгән егеттән яхшырак булуын тели шул.

Кесәләрен генә чистарта...

Бер әдипнең бик таушалган һәм чистартылмаган костюмнан йөргәнен күргәч, хатыны бик игътибарсыз булса кирәк дип сөйләнә икән дуслары. Шунда әйтә Абуталиб:

— Ул ханым бик иртүк торып иренең кесәләрен чистарта, диләр. Костюмын да чистарту кирәген уйларга кайчан вакыт тапсын ди.

БИК ОЗАК ЕГЫЛУ

(Болгарчадан)

Колак... фронтта өзелгән

— Сезнең бу парикмахерскийда булганыгыз бар иде бугай? — дип сөйләндермәкче була бер оста, клиентының борын төбен кискәч.

— Юк, әле беренче генә. Ә колагым фронтта өзелгән иде.

Бик озак егылу

Аяк-кулы бинтланган хезмәткәр эшкә бер сәгатьтән артыграк соңгарып килә:

— Зур бәла, иптәш директор: бишенче каттан егылдым.

— Бишенче каттан җиргәчә шул хәтле озак төштегезме?

Пычак-чәнечке кирәкми

— Кызым, кунагыбыз Иорданга ник пычак белән чәнечке куймадың?

— Нигә ул аңа? Син бит, ат кебек ашый ул дип, үзең әйттең.

Кофе түгел, шулпа

Ашханә эшен тикшерергә килгән инспектор кайбер аш-суларның тәмен дә татып карый.

— Кофены аеруча әйбәт әзерли икән кухнягыз. Зарланырга һич урын юк дип беләм.

— Гафу итегез, бу бит тавык шулпасы.

Дошманнан курыкмау

— Сезнең бу сырхау өчен иң явыз дошман хәмер икәнен исегездән чыгармагыз.

— Гафу итегез, доктор, дошманым алдында куркып калырга тиешме инде мин?

Алдан күреп

Бер яшь шагыйрь редакциядә:

— Баш редакторыгызны күреп сөйләшергә мөмкинме?

— Ул биредә юк.

— Ничек юк? Әле менә шул минутларда гына күрдем ич?

— Аның каравы, ул сезне бераз алданрак күргән иде.

Яңа эштә

Яңа эштә берничә атна хезмәт иткәч, цех башлыгы үз кул астында эшләүчеләрдән сорый икән:

— Шуны һич аңлый алмыйм, биредә мине ник яратмыйлар икән? Элекке эшемнән киткәндә миңа көмеш табакерка бүләк иткәннәр иде.

— Көмеш? Ә без сиңа алтынны бирер идек.

Имтихан алдыннан

Имтихан алдыннан профессор студентларга әйтә ди:

— Имтихан ул — театр кебек: сез — актерлар, ә мин — тамашачы.

— Бик тә әйбәт яңалык бу!— дип әйтә шунда бер студент.— Театрда суфлер да булырга тиеш ич...

Озак көтә алмый...

Астрономия профессоры студентларга:

— Хәзер мин сезгә яктылыгы күктән җиргәчә ун көн килә торган йолдызны күрсәтәм,— ди.

Бер студент шунда:

— Гафу итегез, профессор, кызык бу, әмма мин ул хәтле озак көтә алмыйм шул.

Тизлектән курку

Асфальт юлдан машина чамасыз зур тизлек белән чаба. Шунда бер пассажир:

— Гафу итегез, куркам мин бу тизлектән,— дип белдерә шоферга.

Ә шофер:

— Ничава, минем дә рульгә әле беренче утыруым,— ди.

СҮЗ — ГАБРОВОГА

Һәйкәл... су уртасында

Габрово каласына нигез салган тимерче Рачо һәйкәлен эшләгәч, авторлар аны Янтры елгасы уртасына кертеп куюны тәкъдим итәләр. Халык моны хуплап каршылый.

— Дөрес, иптәшләр. Суга куйсаң, коры җир мәйданы күбрәк кала ич! *

Өйләнешкәч

— Синең никах балдагың кая?

— Бу атнада аны хатыным кия.

---

* Болгариянең Сәнгать һәм Культура комитеты исеменнән Габровода хәзер инде ел аралаш даими үткәрелеп килгән фестивальләрдә дөньяның иң оста сатириклары һәм юмористларына «Алтын Эзоп» һәм «Хитр Петр» дигән бүләк медальләр бирелә. Бу илдә саранлык, күптән билгеле булганча, дәрәҗәле сыйфатларның беренчесе итеп санала.

Искиткеч хәтер

— Габрово кешеләренең хәтере искитмәле икән!
— Нәрсәдән чыгып әйтәсең?
— Биредә мин моннан егерме ел элек булган идем, ә алар шулчак мине кайсы, кайда һәм нәрсә белән сыйлаганнарын әле дә булса онытмаганнар.

Кирәксез эш

Берәүнең хатыны квартира бүлмәләрен бик еш буйый икән. Шуны күргән саен ачулана төшкән ире көннәрнең берендә аның кулыннан буяу тулы чиләген һәм пумаласын тартып ук ала:
— Җитте сиңа, туктат бу эшне! Күрмисеңмени, бүлмәләр болай да күптән кысанланды ич инде...

Мунчада

— Ванна өчен күпме түләргә кирәк?
— Ике лев.
— Менә сезгә бер лев акча, ваннаны яртылаш кына тутырыгыз.

Билгесен белү

— Миңа биш йомырка бир, апа, ләкин барысы да кара тавыкныкы булсын.
— Әгәр кайсы шундый икәнен белалсаң, үзең сайла.
— Ярый,— ди егет һәм... үзе сайлап иң эре йомыркаларны гына ала.

Экономия

Поездан әле генә төшкән пассажир таксисттан сорый:
— Шәһәр үзәгенә хәтле илтергә күпме аласың?
— Ике лев. Әйдә, утыр!
— Рәхмәт! Мин күпме экономия ясармын икән дип кенә сорадым.

Файдалы клиент

Ресторанда бер официант икенчесеннән сорый:
— Әнә теге типны ник урамга куып чыгармыйсың

инде? Күреп торам бит: син аны дүрт тапкыр уятып карадың, ә ул йоклый да йоклый...

— Ник аны куарга ди?! Уяткан саен счет сорый да миңа акча бирә бит ул.

Йөзьяшәр кеше

Кырда кәҗә һәм сарык көтүе көткән бер йөзьяшәр янына картаймау сере белән кызыксынган журналист интервью алырга килә:

— Нинди сөт эчәсез сез, бабакай? Кәҗә сөтеме, әллә сарыкныкынмы?

— Кайсы арзанрак, шунысын эчәм, улым.

Христо ит яратмый

Бер тол хатын күршесеннән үтенә:

— Алла хакына шушы тавыкны суеп бирсәгезче?

— Алай булса, син Христога кер инде, күрше, чөнки ул итле аш ашамый бит.

Кайсы килерлерәк

Берәүнең улы хирург булырга укымакчы.

Ә атасы аңа:

— Син — юләр! — ди.— Иң яхшысы — теш докторы булу ул! Чөнки кешедә йөрәк бер генә, ә авызда тешләр исә утыз ике була.

Зинһар, озатып мәшәкатьләнмәгез...

— Бик үтенәм, зинһар, мине озатып мәшәкатьләнмәгез.

— Алай булмый, дустым, кунак озату миңа иң күңелле һәм ләззәтле эш ул.

Бушлай хыяллана белү дә кирәк

— Мин ерак сәяхәтләр турында гел хыялланам. Европаны әйләнеп чыгу күпме тора?

— Берни дә тормый.

— Ничек алай?

— Чөнки бушлай хыялланырга мөмкин.

Белгәнен әйтте

Кунакка килгән бер габровец кесәсеннән сигарет чыгара да уң кулда утырган күршесенә тәкъдим итә.

—Рәхмәт, тартмыйм,— ди теге.

— Мин дә,— дип кушыла сулда утыручы күрше.

Шуннан хатыны ирнең колагына пышылдый:

— Ә хуҗаның үзен нигә сыйламыйсың?

— Аның тартканын беләм мин.

Мәңгелек тормоз турында уйлау

— Мәңгелек мотор эшләдем! — дип берәү патент бюросына килә.

— Мәңгелек! Искиткеч шәп бу! Ләкин аңа бит мәңгелек тормоз кирәк. Анысы кая?

...Хәзер ул шуны уйлап баш вата икән.

Соңгарак килергә була

Берәүгә эш тәкъдим итәләр. Ул эш хакы күпме буласын белмәкче була.

— Башта җитмеш лев, аннары — йөз.

— Яхшы,— ди габровец,— шул вакытта һичшиксез киләм.

Бушлай бирү

Габрово кешесе кибеттә йөз грамм колбаса үлчәүне үтенә. Сатучы аңа колбаса белән бергә горчица да биргән.

— Мин бит сездән горчица сорамадым!

— Горчицаны колбасага кушып бушлай бирәм.

— Алайса, миңа горчица гына бирегез.

Яңа ботинка алгач

Атасы улына яңа ботинка ала. Кичен алар икәүләп бер туганнарына кунакка китәләр. Юлда атасы сорый икән:

— Син яңа ботинкаңны кидеңме?

— Әйе, этием.

— Алайса, эрерәк атла, ботинкаң тиз тузмас.

Түләүсез товар

— Сезнең бу йомыркаларыгыз бик күптәнге күренә, чебеш чыгарыр чаклары җитмәдеме икән?

— Ал әйдә, ал, чебешләре өчен түләмәссең.

Яңа эшләпә алгач

Бер габровец үз өенә кәефе күтәрелеп кайтып керә. Ул күзләренә үк төшеп тора торган эшләпә кигән.

— Нигә шундый зурын алдың? — дип сорый хатыны.

— Беләсеңме, карчыккаем, уңдым бит әле мин! Моңардан ике размерга кечкенәрәк эшләпәнең дә бәясе шул ук.

Кызганыч, буш түгелсең икән шул...

— Син бүген бушмы?

— Әйе.

— Ә иртәгә төш вакытында?

— Буш.

— Ә берсекөнгә кичен?

— Буш түгел. Ә нәрсә.

— Кызганыч! Ул көнне сине кичке ашка чакырмакчы идем.

Кешенеке җәл түгел

Ике студент үзләренә бүрек сатып алалар. Урамда коеп яңгыр ява икән. Нишләргә? Юлга чыксаң бүрек чылана бит. Бүрекләрне алмашып кияргә дигән карарга киленә: кеше бүреге чыланса да җәл түгел бит!

Төймәләр генә ала

— Карале, картым, пальтомның бер төймәсе дә калмаган бит. Кияргә оят!

— Ярый, мин иртәгә алырмын.

— Яңа пальтомы?

— Юк, төймәләр.

Иренчәк квартирант

— Әти, безнең квартирант ник көн саен шашлык ашый?

— Помидор утыртырга иренгәнгәдер...

Әзер җавап

Берәүдән «син нигә тукталыш саен трамвайдан төшәсең дә яңадан утырасың?» — дип сорагач, әйтә икән ул:

— Контролерларга «әле хәзер генә утырдым» дия алыр өчен.

Кесәгә генә кергән нәрсә

— Беләсеңме, әгәр бер уй керсә башыма, ул һич тә хәтеремнән чыкмаячак минем...

— Ә миннән әҗәткә алган йөз лев акча турында ни әйтерсең?

— Ул акча бит минем башыма түгел, кесәмә кергән иде.

Түләүне кирәк тапмый

Юлда имгәнгән бер чит ил кешесенә Габрово больницасында кан салалар. Беренче салудан соң ул үзен яхшы хис итә башлый һәм табибка да, кан бирүчегә дә яхшы түли. Ә икенче мәртәбә салгач акчаны азрак бирә, өченчесеннән соң исә түләүне бөтенләй кирәк тапмый, чөнки аның тамырларында инде Габрово каны йөри башлаган була.

Кунак сыйлар өчен

Бер дусты габровецны сигарет белән сыйлый. Теге шуны ала да әйтә икән:

— Ә мин бит күптән тартмыйм инде.

— Алайса, сигаретны ник аласың?

— Иртәгә миңа кунаклар киләчәк. Менә шуларның берсен мин дә сыйлармын.

Кысканың озыны

Бер габровец хатынына Варнадан телеграмма сугарга килә.

— Һәр сүз өчен алты пенс түләргә кирәк,— ди аңарга телеграфист.— Ә имза өчен түләнми.

Берничә минуттан клиент телеграфистка «Каршыла» дигән сүздән генә торган телеграмма суза. Ә имзасы болай була: «Ундүртенче сентябрьдә егерме өченче поездның бишенче вагонында кайтучы ирең».

Тупның бәясе кыйммәт бит

Футбол командасы тренеры уенчыларга инструкция аңлата:

— Иң мөһиме, уен вакытында күзегездән тупны бер минутка да ычкындырмагыз.

— Аңлашыла,— ди шуны ишеткән бер Габрово кешесе,— ул туп бит ким дигәндә утыз лев тора...

Нинди кияү ул?

Вагон купесында бер яшь егет шактый өлкән яшьтәге апайдан сорый:

— Әйтегезче, зинһар, вакыт күпме хәзер?

— Әйтмим, әйтмим, һич әйтәчәк түгелмен! Беләм мин аның нәрсә белән бетәчәген: хәзер сәгать фәләнчә дисәм — сез миңа рәхмәт белдерәсез... Димәк, боз кузгала башлый! Таныш-белешләрчә, дусларча сөйләшү китә. Аннары без поезддан төшәбез. Станциядә сез мине сыйлыйсыз, аннары, бәйрәм ашы кара-каршы дип, мин сезне өемә чакырам. Ә өйдә матур кызым бар. Сез аңа гашыйк буласыз. Миннән аның кулын сорыйсыз, ә мин... Юк, бердәнбер чибәремне сезгә биргәнче, мине алла каргавы яхшырак. Кулында сәгате дә булмаган кеше нинди кияү ул?!

Кабер ташындагы язу

«Биредә минем хәләл җефетем ята. Ул гомер буе сөйкемле, игътибарлы, акыллы, укымышлы һәм бер тиенне дә бушка әрәм итми торган хуҗабикә булды. Әгәр хәзер торып сөйли алса, ул үзе дә нәкъ шул сүзләрне кабатлар иде!»

Бераз кире илт

Такси кунакханә янына килеп туктый. Пассажир:

— Күпме тиеш мин сезгә? — ди.

— Ике сум кырык тиен.

— Алайса, сез мине биредән бераз кире илтеп төшерегез инде, чөнки ике генә сум акчам бар...

КӨЗГЕГӘ КАРАП

(Чех һәм словак мәзәкләре)

Борчулы күренә

— Ник болай бик борчулы күренәсең? — дип сорый берәү ит кибетендә эшләүче күршесеннән.

— Улыма машина алырга вәгъдә иткән идем, әмма алып булмастыр кебек.

— Ник?

— Менә ике ай рәттән инде комбинатта үлчәп пакетларга салынган ит кенә саттыралар.

Хәл белешү

Күрешмичә бик озак торган ике дус очраша.

— Минем хәлләр ничек икәнен ник сорамыйсың әле? — ди берсе.

— Яшәешләрең ничек?

— Сорамавың яхшырак!

Кирәккә күрә борчый

— Ханым, сезнең ирегезгә абсолют тынычлык кирәк, аны берничек тә борчу ярамый.

— Соң, доктор, миңа яңа костюм аласы бар бит!

Көзгегә карап сөйләнү

Амалка ханым көзге каршында торып үзалдына сөйләнә икән:

— Хатын-кыз матурлыгы — җиңелмәс корал ул.

— Дөрес әйтәсең, бик дөрес...— дип үзенекен өсти шулчакны аңа ире.— Ә сине шулай коралландыру өчен акчаны каян алырга соң?

Соңга калу

— Син нишләп болай өйгә бик соң кайттың?
— Ачуланма, кадерлем, мин сәгать алдым.
— Ә сәгатең кайда?
— Ә сәгать... артка калды.

Жалоба кенәгәсе

— Жалоба кенәгәгезне бирегез әле миңа?
— Исегезгә төшерәм, иптәш, ашаганда укып утырырга ярамый.

Контролер кергәч

Вагонда бер әби электричка пассажирларыннан сорый икән:
— Бу, бәлки, азаккы тукталыштыр инде, нигәдер бөтенесе кинәт чыга башлады?
— Юк, әбекәй, алар күзенә контролер күренде.

Ничек аңларга?

— Ничек аңларга икән моны: сезгә инде җитмеш тулган, ә егерме яшьтәге кызга өйләнергә телисез. Артык яшь түгелме соң ул?
— Әйе, сез хаклы. Тагын бер-ике ел көтәм әле, алайса.

Юкка маташу

— Доктор, йокым юк минем. Бер яктан икенче якка әйләнеп ята-ята арып бетәм.
— Бер дә гаҗәп түгел бу! Шулай маташсам, мин дә йоклый алмас идем.

Хәтта үзе дә белми

— Я, хәлләрең ничек, кайда эшлисең хәзер?
— Беләсеңме, дус, эшем шундый серле ки минем, хәтта нәрсә эшләвемне үзем дә белмим.

Егет түгел... кыз, эти түгел, эни... *

Бер сөйләшүдән өзек

— Әх! Лотереяга откан бөтен акчам менә хәзер үз кесәмдә булса икән...
— Нишләр идең аның белән?
— Бөтенесенә тагын лотерея билетлары сатып алыр идем!

Даруның файдасы юк

— Кадерле доктор! Аякларым сызлый башлады. Берәр дару бирсәгез икән.
— Сызлаудан даруның файдасы юк. Минем дә аяклар кайчакта бик каты сызлый. Хатынымнан массаж ясаткач ук авыртуы басыла.
— Ә сезнең хатыныгыз кайчан буш була соң?

Борчылу

— Бик зур борчуым бар: яраткан этем каядыр китеп югалды.
— Ә сез газетага белдерү бирегез!
— Ярдәме булмас шул — этем укый белми иде бит.

Театрга җыенганда

— Лали, ник сакал-мыегыңны кырмадың?
— Мин кырынган идем.
— Кайчан?
— Син киенә башлаганда.

---

* «Венгр юморы» китабыннан. «Сәнгать» нәшрияты, Ленинград — Мәскәү, 1967.

Егет түгел... кыз, эти түгел... эни

— Кара инде ничек ямьсез киенгән бу егет!
— Егет түгел, минем кызым ул.
— Гафу итегез, мин сезнең шул кыз этисе икәнегезне белмәдем бит.
— Ә мин аның этисе түгел, энисе булам.

Вагонда

— Әйтегез әле, бирелә тәмәке тартырга ярыймы?
— Бу купеда тәмәке тартмыйлар.
— Ә бу төпчекләр каян?
— Сез сораганны сорамаучылардан калган чүп алар.

Барысы да безгә буламы?

Бер гаиләдә өч игезәк бала туа. Биш яшьлек балалары шулчакны бик кызыксынып сорый икән:
— Әти, болар барысы да бездә калачаклармы, әллә кирәген сайлап алыр өчен генә бирделәрме?

Нишлим икән?

— Ирем минем — диңгез флоты офицеры. Ул өйдә елына ике атна гына була. Безнең гаилә тормышыбыз бәхетлерәк булсын өчен нишлим икән?
— Шул ике атнага сез дә кая да булса китеп торыгыз!

Китап сөючеләр аңлаша

— Кулына китап алыр алдыннан кем бүлмә һавасын алмаштыра, кем тузан кунган урыннарны сөртә, кем кулын юа һәм тамагын чайкый — мин китапны бары шуңа гына бирәм.
— Ә мин китапны вакытында кире кайтаручыларга гына бирәм һәм бирәчәкмен.

Аягым авыртканда

— Нишләп аягың авырта? — дип сорый миннән бер малай.
— Чөнки мин атам-анам әйткәнне тыңламый торган идем,— дип аңлатам мин педагогикага ишарә белән.
— Синме ул тыңлаучан түгел идең? Менә сиңа мә! Үзе зур кеше, үзе олылар сүзен тыңламый!

Имтиханга кергәндә

— Син әзерләнә алдыңмы соң?

— Әлбәттә! Өстемдә иң соңгы мода белән тегелгән өр-яңа тар кофта икәнен күрмисеңме әллә?!

Спорт белән шөгыльләнә

— Нишләп бу хәтле ябыктың әле син? Тирең белән сөягең генә калган лабаса...

— Беләсең килсә, соңгы бер айда мин туп-тулы өч килога кимедем. Хәзер туксан ике кило гынамын инде.

— Монысы да чамадан тыш. Ник спорт белән шөгыльләнмисең?

— Юктан көләсең, иптәшкәй. Бик шөгыльләнәм.

— Суда йөзәсеңме? Фехтованиеме?..

— Маркалар җыям!

— Шул да булдымы спорт?

— Әлбәттә. Мин бит бары тик олимпия маркаларын гына эзлим һәм табам...

Врач белән сөйләшү

— Ике-өч көн рәттән беркая чыкмыйча өйдә утырыгыз һәм бик яхшылап ял итегез.

— Моны һич эшли алмыйм шул мин, докторым!

— Ә ник?

— Чөнки күптән түгел генә яңа модалы мебель сатып алдым...

Бәйрәмегез кайчан була?

— Хатыныңның туган көне кайчан?

— Без өйләнешкәннән соң шул хәтле гомер үтте ки, хәтта хәзер хәтерли дә алмыйм.

Борылып та карамый

— Уллыкка алган балабыз зур булды инде, бик яхшы хезмәт хакы ала. Үстергән чагында аңа мин үз улым түгеллеген берничек тә сиздермәдем. Үз балам, үз каным санап тәрбия кылдым.

— Ә ул?

— Ул да миңа нәкъ туган санаган атасына булган шикелле мөнәсәбәттә. Минем якка борылып та карамый.

Үзе дә белми

— Мин шикаять язарга телим.
— Кем өстеннән?
— Белмим әле. Ә сез кемне дә булса тәкъдим итә алмассызмы икән?

Мактанышу

— Мин сигарет алган араданиндидер машина тротуарга чыга да ике җәяүлене бәреп ега. Кем белә, әгәр мин тәмәке тартмаучы булсам, нишләтелгән булыр идем?..

Китабы чыккач

— Минем яңа шигырьләр китабым чыкты. Аларның барча нөсхәләрен үзем сатып алдым.

Акыл белән эш итү

— Акыллы кешеләр белән эш итүне яратам мин.
— Ни өчен?
— Үткән атнада бер кечкенә эт тапкан идем. Шуны сатарга теләдем. Ләкин бер форент түләргә теләүче дә табылмады. Этне хуҗасына илтеп бирергә туры килде һәм ул миңа, рәхмәт белдереп, нәкъ илле форент акча бирде.

БЕРАЗ КӨТӘМ ӘЛЕ...

(Куба мәзәкләре, испанчадан)

Буташтырган

Сулышы буылган бер агай сигезенче каттагы врач бүлмәсенә килеп керә:

— Ничек арынырга миңа бу сырхаудан?

— Минемчә, сезгә тартуны ташларга, сыра эчмәскә, күп ашамаска кирәк... Аннары тагын күзлегегезне алмаштырыгыз: мин терапевт түгел, ә терапевт бүлмәсе икенче катта...

Унысы ун төрле

— Боб, синең бүлмәдә ун сәгать йөреп тора, ләкин һәркайсы вакытны үзенчә күрсәткәнен беләсеңме?

— Беләм. Әгәр берүк вакытны күрсәтсәләр, миңа ун сәгать ниемә кирәк булыр иде?

Спортны яратырга өндәү

— Сез барыгыз да көн саен спорт белән шөгыльләнергә тиешсез. Бер король, мәсәлән, дәрескә барганчы киң елга аша өч кат йөзеп чыккан.

— Оһо! — ди икән шунда Боб.— Һәм ул король мәктәпкә шәрә килгәнме?

Бераз көтәм әле

Бер яшь ханым ахирәтенә зарлана:

— Иремне яратмый башладым. Көн саен диярлек куптарган җәнҗалларыннан ябыгып бетәм ахры инде.

— Ә ник аерылышмыйсың, алай булгач?

— Үзем дә шул турыда уйланганым бар. Ләкин бераз көтәм әле: авырлыгым тагын ун килога кимесен инде.

Остаханәдә сөйләшү

Атаклы скульптор мастерскоена кергән берәү сорый икән:

— Шундый искиткеч матур сынны каян алдыгыз?

— Мин аны мрамор кисәгеннән ясадым.

— Ә ул нәкъ шул мрамор кисәге эчендә икәнен каян белдегез?

Өстәл лампасы алгач...

— Мин китап сатып алырга киттем.

— Китап?!

— Әйе. Чөнки кичә ирем искиткеч матур өстәл лампасы алып кайтты.

Икесе кем икән?

Романнары белән киң танылган күренекле әдип бер яшь язучы кыз белән сөйләшә:

— Дөресен әйтергә кирәк, үземнең шактый озын иҗат гомеремдә мин кызлардан нибары бик сәләтле өч кешене очраттым.

— Ә аларның икесе кем икәнен әйтмәссезме икән, остаз?

...Әни сугышка әзерләнә

Бер бала һиндлыларның иреннәрен һәм битләрен буяганын телевизорда күрә дә әтисеннән сорый:

— Ник шулай бизәнәләр?

— Алар, улым, шулай сугышка әзерләнә,— ди.

Кичен бала әтисе янына килә:

— Әтекәем, тизрәк качыйк, әни анда сугышка әзерләнә.

Нинди дә ярый

— Нинди бифштекс китерим сезгә: инглизчә пешерелгәненме, әллә французныкынмы?

— Нинди дә ярый, чөнки мин ул телләрнең берсен дә белмим.

Кайсына ышанырга?

— Беләсеңме, этисе, мин Изабеллалар өенә беркайчан да аяк атламаячакмын,— дип кистереп әйтә хатыны иренә.— Ул начар тәрбияле! Мин нәрсә турындадыр кыска гына сөйләгән арада егерме мәртәбәмедер авыз тутырып иснәп өлгерде.

— Кадерлем, минемчә, бәлки ул сүз башларга теләп шулай егерме тапкыр авыз ачкандыр һәм син аны һаман үзең ни дә булса тәкелдәп бүлдергәнсеңдер.

Әкренрәк барсын

— Сезнең билетыгыз пассажир поездына утырырга алынган. Ә бу — тиз йөрешле поезд бит,— дип кисәтә берәүне контролер.

— Ә миңа барыбер, әгәр телисез икән, машинистка әйтегез: әкренрәк барсын.

Сәбәбе... бәлки көлмәктер?

— Кичә сезнең хатыныгызны күрдем. Урамнан узганда ютәлли иде. Авырый булса кирәк?

— Юк, яңа күлмәген киеп чыккан булгандыр урамга.

Менә сиңа мә

Тиз йөрешле поезд купесында өч пассажир бара. Поезд тоннельгә керә. Бер-ике минут үтүгә пассажирларның бер яше юлдаш ханымга әйтә икән:

— Тоннельнең шулай шактый озын икәнен белсәм, мин сезне үпкән булыр идем!..

— Менә сиңа мә! Алайса, мине кем үпте була соң инде?!

Ничек тирән суларга?

— Тирән сулыштан хәтта микроблар үлә.

— Ә аларны тирән суларга ничек өйрәтергә кирәк икән?

Ишеттеңме әле?

— Мария, ишеттеңме әле син, күренекле әдип Гомес безнең Долореска чиксез матур киләчәк вәгъдә иткән бит: «Син искиткеч оста уйнаучы драматик актриса булачаксың!» — дигән.

— Әллә син ул әдипнең юмор жанрында гына эшләвен белмисеңме?

ПОЕЗДЛАР ЙӨРИ, СӘГАТЬ ТУКТАГАН

*(Поляк фрашкалары *)*

Этисе буш түгел

Егет белән кыз бер бүлмәдә икәүдән-икәү калалар.
— Әгәр хәзер бирегә этиең килеп керсә? — дип курка икән егет.
— Аптырама, ул өебезгә слесарь килгәнче бармак очы белән суыбыз кранын томалап торачак әле. Шундый эш кушылды аңа.

Тешләми... җирәнә генә

— Бу эт тешлиме икән? — дип мыгырдый машинага утырган бер сәрхүш.
— Тешли,— ди таксист,— ләкин курыкмагыз, сасылардан җирәнә генә ул!

Йокласа ни

Театрда пани Ковальская иренә пышылдый:
— Казя, күрәсеңме? Уң ягындагы тип йоклый ич!
— Йокласа ни? — дип мыгырданып ала пан Ковальский.— Шуның өчен мине уятырга кирәк идеме?!

---

* Ф р а ш к а — поляк халык юморының бер төре — тамыры һәм мәгънәсе белән «кечкенә, бәләкәй» дигән сүздән. Кайчакта бераз дорфарак (димәк, катырак бәреп, турырак әйтү!), шул ук вакытта нәфис яңгырашлы кинаяле мәзәк. Башта аны шигырь итеп язганнар һәм 16 гасырда бу жанрны Миколай Рей белән Ян Кохановский башлап җибәрәләр. Соңгы елларда аларны дәвам иткән иң зур оста Станислав Ежи Лец санала.

Үлеп гашыйк

— Пани Зося, мин сезгә үлеп гашыйкмын!
— Инде дә тискәре икәнсез! Кичә үк бик ачык итеп әйттем бит инде: «Юк, юк!»
— Ах, ул сез идегезмени?

Малны янга калдыру

— Әни, мин бүген йөз злотых акчаны янга калдырдым.
— Ничек?
— Бик гади килеп чыкты бу хәл! Синең пани Малиновская өстеннән язган анонимкаңны почта ящигына салмадым, ә аның үз кулына илтеп тоттырдым!

Зур бәла

Ир белән хатын үз өйләре янында нишләргә белми аптырап торалар.
— Ни булды?
— Бәла! Гараж ачкычыбыз бүлмәдә, квартир ачкычы автомобильдә, ә автомобиль гаражда калган...

Ничек әзерләргә?

— Ева, мин бүген кичкә берничә дустымны чакырдым. Ашарга-эчәргә нәрсә дә булса әзерлә инде.
— Ярый. Ләкин ничек әзерлим соң: ул кунаклар тагын килерлек булсынмы, әллә килмәслекме?

Поездлар йөри, сәгать туктаган

— Йозеф, тизрәк чап поездыңа, юкса соңарырсың! Ул бит биш минуттан китәргә тиеш.
— Борчылма, кадерлем. Станциядә сәгать күптән йөрми бит инде.

Ни өчен

— Ни өчен кайбер балалар үзләрен ата-анасызлар кебек тота икән?
— Чөнки кайбер ата-аналар үзләрен баласызлар шикелле итеп хис итә.

Искиткеч малай

Бәләкәй арбада утырган бала янында газеталар ята.

— Малаегыз искиткеч икән ләбаса! — дип соклану белдерә шуннан узып барышлый бер әби.— Инде гәзитә дә укыймы?

— Юк! Ул вундеркинд * түгел бит,— ди бала анасы.— Ул алардагы кроссвордларны гына чишә ала әле...

Тынычландыру

— Минем ашыма таракан төшергәнсез бит!

— Курыкмагыз, ул күп ашамый.

Икесе дә беренче

— Мин бик дулкынланам һәм борчылам — чөнки гомеремдә беренче операциягә керәм бит.

— Мин дә бит ул операцияне гомеремдә беренче мәртәбә ясыйм.

Биегәндә сөйләшү

— Сезнең белән биегәндә мин үземне киң далада кебек хис итәм...

— Ник алай?

— Чөнки сез дөя кебек биисез.

Уклау буш түгел

— Күршем, миңа уклавыңны биреп тормассыңмы икән?

— Кызганычка каршы, бирә алмыйм шул, үзем дә ирем кайтканын көтәм...

Сәер карачкы

— Бу искиткеч карачкыны каян табып кайттың?

— Африкадан. Абыем белән бергә чыккан ауда атып алдым.

— Эченә нәрсә тутырдың соң шулай күп итеп?

— Анда абыем үзе.

---

* Гадәттән тыш сәләтле.

Сәбәпле соңару

— Каян кайтып килешең болай бик соң?
— Лекциядән.
— Иртәнге дүрткә хәтле лекцияме?!
— Әйе, чөнки лекторы тотлыга торган кеше иде.

Нәрсәсе яхшы

— Җәннәтнең нәрсәсе яхшы соң аның?
— Чөнки аннан әле беркемнең дә кире кайтканы юк,— дип җавап бирә ксендз.

Косметик могҗиза

Бер ханым танышына әйтә:
— Җыерчыкларны бетерә торган искиткеч крем турында мин кичә бер журналда белдерү укыдым.
— Беләм, җаным, беләм, минем аны сөртә башлавыма инде тиздән ел тула.
— Кара инде, ник шулай алдалап язалар икән?..

Куркыныч нәрсә

Шоферлар курсында имтихан бара. Имтихан алучы бер укучысыннан сорый икән:
— Машинада йөрткәндә иң куркынычы нәрсә?
— Кабинада шофер белән янәшә утырып барган яшь ханым яки кыз.

Штат буенча

Дуамалрак бер начальник үз кул астында эшләүче бер хезмәткәрен акырып-бакырып тирги.
— Тавышыгызны яртылаш баса төшебрәк кычкыруыгызны үтенер идем мин сездән,— ди аңа хезмәткәре.
— Нишләп алай дисең әле син?
— Чөнки мин бит сездә ярты штат кешесе булып кына эшлим һәм ярты хезмәт хакы гына алам.

Йөзьяшәр бабай сере

— Инде менә йөз яшегезне тутырганда сез тормышыгызда иң зур казаныш дип нәрсәне саныйсыз?
— Минем дошманнарым булмады.
— Ә моңа ничек ирештегез?
— Алар үлеп бетте, ә мин менә яшим әле.

Кайда да уйлап була ич...

— Без быел диңгез буена ял итәргә бара алмабыз, ахры,— ди бер ир,— чөнки әҗәткә алганнарыбызны кайтару турында уйлыйсы бар.

— Ул хакта без,— ди хатыны авызын турсайтып,— диңгез буенда уйлый алмабызмы әллә?

Үлчәп карагач...

— Кичә мин сезнең кибеткә улымны биш кило алма алырга дип җибәргән идем. Кайткач үлчәп карасак — дүрт кенә килограмм чыкты...

— Ә улыгызны үлчәп карамадыгызмы соң?

Кайсы яхшырак

— Син язмыш кушканның кайсын тизрәк сайлар идең: тинтәгенме, әллә пеләш башлысынмы?

— Минемчә, тинтәге яхшырак.

— Ни өчен?

— Чөнки ул күзгә артык бәрелеп тормый.

Кайсы нәрсә ярата

— Улыбыз Владик шәһәрдә яши башлагач хатларны шундый серле-хикмәтле итеп язарга остарды ки, безгә һәрвакыт чит телләр сүзлеген актарырга туры килә.

— Алай гына булса түзәрлек әле ул, кәбәм. Безнекенең һәр хатыннан соң саклык кенәгәбезне карый башлыйбыз.

Уңмау

— Аның ике никахы уңышсыз чыкты бит инде. Беренчесендә аны хатыны ташлап китте...

— Икенчесендә?

— Ә икенчесендә ташламады.

Теория һәм практика

— Әни, нәрсә ул теория һәм практика?

— Теория дигәне, балакай, шул ул: әйтик, әтиең, папирос алырга дип берничә минутка гына чыгып китә. Ә аның төнге бердә генә өйгә кайтуы — чын практика инде.

Еракны күрү

Кинотеатр яныннан узганда ике малай: «Бу фильмны карау уналты яшьтәгечә балаларга рөхсәт ителми», дигән белдерүне укыйлар. Һәм әйтә шунда берәве:

— Күзеңне ача төшеп кара, Антек, һәм хәтереңә кертеп калдыр: ике меңенче елда без әнә нинди кызыклы фильм карый алачакбыз икән!

Икесе дә белдө

— Әни, эти түр бүлмәгә куйган баскычны мин аудардым...

— Бер минут та тыныч утыра алмассың икән. Моны атаң белсә нишләрсең?

— Ул белә инде: чөнки түшәмдәге люстрага эләгеп калды!

Югалту юк

Бер ораторның күңелсез һәм гадәттән тыш озын чыгышын тыңлаган зал борчыла башлый: кычкырып сөйләшүләр китә, тавыш куба.

— Тынычлануыгызны үтенәм, иптәшләр, чөнки мин хәтта үземне дә ишетми башладым хәзер,— ди оратор.

— Һәм беркемгә дә зыян юк монда! — дигән җавап ишетелә залдан.

Шедевр түгелләр

— Портретыгыз үзегезгә ошыймы? — дип сорый рәссам берәүдән.

— Ачыктан-ачык әйткәндә, шунысын билгеләп үтәргә мөмкин: биредә мин сәнгать шедеврын күрмим.

— Ә бит сез үзегез дә — натура шедеврьы түгел.

«Тиз»е дә бар икән

— Сез чамадан тыш акрын-салмак кеше. Мондыйны беренче күрүем әле. Ичмаса бер генә нәрсәне тиз башкара аласызмы?

— Әйе. Теләсә нинди эш башкарырга теләвем бик тиз юкка чыга минем.

Трофейсыз кайтмаган

Ау эшенә әле керешүче генә берәү сунардан кайта.

— Трофейларың нәрсә? — дип сорый хатыны.

— Бик үк зурдан булмады...

— Ә кая ул?

— Больницта.

Баштa танымады

Бер яшь ир-егет косметика залыннан чыккан кызга сылана.

— Бәйләнмәсәнә миңа, юеш борын,— ди аңа кызый һәм ашыгып китеп бара.

— Бу тавыш миңа бик таныш ич?! — дип аптырый да егет, бераздан исе китеп әйтә икән үз-үзенә:

— Бу минем әбием ләбаса!

КИНДЗЮЛИС КИЛӘ ДӘ ӘЙТӘ... *

Бу ат артка карамый

Яшьрәк булып күренер өчен чамасыз бизәнгән-ясанган бер кыз, бәләкәй станциядә поездан төшкәч, колхозчы абзый олавына сак кына менеп утыра да сорый икән:

---

* Моннан ике дистәдән артык еллар элек Литва сатирик журналы «Шлуота» («Себерке») битләренә юморист Витаутас Николаускас керткән әдәби һәм халык иҗаты персонажы. Хәзер ул, күпчелек төрки телләрнең Хуҗа Насретдины сыманрак итеп, коллектив иҗат җимеше буларак гомумиләштерелгән мәзәкче. Тапкыр һәм җор телле бу кеше үзенең гыйбрәтле һәм кисәтүле сүзләрен теләсә нинди урынга «килә дә әйтә».

— Атыгыз тибә торганнардан түгелме?
Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Кызганычка каршы, ул артка борылып карамый шул.

Нәрсә ул корбан

— Хәзер ниндидер югалтулар яки корбаннар турында күп сөйлиләр,— дип гәпләшә икән ресторан янында җыелган берничә ир. Кайсыгыз белә: нәрсә ул корбан?
Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Бер төркем адәми затны исертеп аяктан еккан хәмер бәясен берүзе түләүче абзый дип белик аны.

Кирәкмәс сорау

— Ә эш хакың кая? — дип сорый хатын таң алдыннан гына кайтып кергән иреннән.
Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Провокацияле сорауларга җавап бирми ул хәзер.

Ни өчен шулай...

— Бу ял йорты ник бер көнлек дип атала?
Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Чөнки биредә беркем дә бер көннән артыкка түзә алмый.

Кайсы кош файдалы

— Кешеләргә нинди кошлар иң файдалы?
Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Табада кыздырганнары.

Бишек җырымы

— Карале, синең бу «Бишек җыры»ң финалында нигә бик кискен диссонанслар күп?
Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Тыңлаучыларны йокыдан уятыр өчен.

Атланып очарга түгелме

Хуҗалык товарлары кибетендә чамадан тыш бизәнгән купшы бер ханым себерке сайлый: берсе артык озын, икенчесе кыска, өченчесе кысып бәйләнмәгән, дүртен-

чесе каты, имеш. Аннары, сәгать чамасы шулай сайлап азаплангач, кибетченең тәмам исен китереп, болай ди:

— Менә монысын алам...

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Ханым, сезгә моны төреп бирикме, әллә хәзер үк шуңа атланып очасызмы?

Шәп чара

— Ишеттеңме әле син, Пятрас кызын кияүгә бирә икән бит? Ә шул кияүнең атасы белән аның ун ел инде сөйләшкәне дә юк — бер-берсен җан дошман күреп яшиләр,— дип гәпләшә ике күрше.

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Үч алыр өчен, күр син аны, нинди шәп чара тапкан!

Этле-мәчеле тору...

— Бар микән бу дөньяда миннән дә бәхетсезрәк кеше? Мәче шикелле, тәрәзәдән карап көннәр буе өйдә ялгызым утырам бит,— дип зарлана бер хатын. Ә ире аңа җавап итеп әйтә:

— Ә мин, эт шикелле тел салындырып, көннең көн буе эштә чабам...

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Алар этле-мәчеле тора дип юкка әйтмиләр икән алайса.

Клуб кем өчен

Бер башлык үзләренең Культура сараен күкләргә күтәреп мактый икән:

— Ул көн саен эшчеләр белән тулы була!

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Әйе шул! Хәзер анда күптән башланган бик зур ремонт бара.

Ире күрмәгәндә

Кафеда бер кыз бергә утырган ахирәтенә белдерә:

— Әнә теге чатка күз төшер әле, Онута үзенең өченче ире белән күгәрчендәй гөрләшеп утыра.

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Әгәр моны дүртенче ире белсә, дөньяның астын-өскә китереп тавыш куптарачак әле!

Кайсы балык кирәк

Хатын ирен балыкка озатырга җыештыра.

— Бүген җан кисәгем, ала балык алып кайта күр әле, зинһар!

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Әгәр кибетләрдә ала балык булмаса, карп та ярый...

Аяклары ник кыска

— Ни өчен куянның ал аяклары кыска? — дип сорый берәү үзенең дустыннан.

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Чөнки ходай тәгалә аны дүртенче квартал азагында тудырган.

Соң түгел

Укытучы бер укучыны дәрескә соңга калып килгәне өчен шелтәли.

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Укырга беркайчан да соң түгел.

Андый чир янамый

Булыр-булмас бер композитор көнче хатын-кызларга аңлата:

— Гениаль оста булу — чир кебек үк яман нәрсә ул.

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Сезгә андый куркыныч янамый: кыяфәтегез белән бик таза күренәсез.

Дусларча киңәш

Туган көн кичәсенә баручы ике дус киңәшә:

— Нәрсә белән хуҗаның исен китәрергә икән?

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Бер шкалик та аракы алып бармагыз.

Ул белгеч түгел

Фатирда торучы бер агай хуҗадан сорый:

— Яңгыр яуган саен бүлмәне су баса. Күпме шулай дәвам итәр икән?

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Ул каян белсен? Метеоролог түгел ич.

Кем хаклы

— Хәзерге яшьләрнең күбесе эшнең рәтен белергә теләми,— дип зарлана бер мөдир.

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Аның каравы карт белгечләрнең дә ничек эшләмәскә кирәген белгәннәре аз түгел.

Кәҗәнең үзенә дә килешә иде...

Универмагта берәү күн пальто киеп карый да:

— Бу миңа бик тә килешә! — дип куана.

Шулчакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Ул тире кәҗә тәкәсенең үзенә дә бик килешә иде!

ШӘКИДӘ* КӨЛКЕ БӘЙРӘМЕ

Сәер сатулашу

Гаҗи бабай бервакыт төбе тишелгән чиләген остага алып килә.

— Шуны ямаган өчен күпме алырсың?

— Илле тиен.

— Әгәр чиләкнең үз төбен алып килсәм күпме түләргә тиеш булам?

— Барыбер илле тиен.

— Минем чиләк төбем белән дә илле, синеке белән дә? — дип гаҗәпләнә Гаҗи.— Сәер бит бу.

---

* Шәки — Азәрбайҗанның Дагстан белән чиктәш төньягында кечкенә шәһәр — район үзәге. Биредә 1983 елда, Габроводагыча, беренче мәртәбә көлке бәйрәме үткәрелә. Анда күпчелек мәзәкләр Гаҗи ами (Хаҗи бабай) исеменнән сөйләнелә.

— Бернинди сәерлеге юк моның,— ди оста.— Әгәр синең чиләкне аның үз төбе белән үк ремонтласам, миндәге төпне кая куярга?

Туган-тумачалы ишәк

Гаҗи бабай ишәк сатып ала. Шуны алып кайтуына ишек шакыйлар.

— Кем бар анда?

— Ишәген син алган кешенең энесе.

— Рәхим ит. Кунагым бул!

Икенче көнне ишек тагын шакыла.

— Кем?

— Ишәген син алган кешенең агасы.

Хуҗа монысын да кунак итеп каршылый. Соңыннан тагын бер агасы, бер апасы, туганнан туган энесе һәм бабасы да килә...

Гаҗи ишәкне базарга кире илтә.

— Ни булды, мал начар булып чыктымы әллә?

— Юк, ишәге ярыйсы. Тик менә туган-тумачасы чамасыз күп икән.

Техника үсеше

Гаҗи бабай поездда аскы ятак пассажиры белән сөйләшә:

— Кай тарафка юл тотасың?

— Мәскәүгә.

— Ә син?

— Мин Евлахка.

«Күр син аны,— дип уйлый Гаҗи,— аскы ятак Мәскәүгә, ә өскесе Евлахка бара ич. Ай-һай шәп үсә безнең техника!»

Дөресен әйт әле...

— Я, дөресен генә әйтеп бир әле, кордаш, хатыныңнан уңдыңмы?

— Юк, мин уңмадым, ә хатыным уңды: чөнки мин аның дүртенче ире булып чыктым.

Сәбәбен белергә теләп

Бер ханым бала тапмаудан зарлана.

— Бәлки бу нәселдән киләдер,— ди аңа доктор.— Әйтегез әле, сезнең анагызның балалары бар идеме?

Үзеннән үзе көлә

— Берәр юләрлек эшләсәм, үземнән үзем көләм мин.
— Бәхетле икәнсең, гел көлеп кенә үтә алайса гомерең!



ТАНЫШ БУЛЫЙК: ПЫХЫ ТАГАН*

Кулай кисәтү

Пыхы аганың сызлаган тешен алгач врач аны кисәтә:
— Ике сәгать узмыйча берниндн ризык капмаска тиешсез!
— Бу киңәшегез бик тә кулай бит әле, доктор. Иртән хатын белән сүзгә килеп юләрлек эшләдем. Ачы тәҗрибәмнән чыгып беләм: ул бүген ашарга берни пешермәячәк.

Киңәш сүзе

Бер абзый Пыхыдан киңәш сорап килә:
— Әллә ничә тарафка димче җибәреп карадым, һаман бер сорау белән кайталар: «Эчәме егет?» Нинди җавап бирергә дә белгән юк.
— Менә нәрсәне онытма, абзый, кайнанаң ни әйтсә, шуны тыңларга тиеш булачак синең улың.

Капкын алгач

Пыхы кибеттән капкын алып кайтканда бер салмыш дусты очрап сорый икән:

---

* Хәзерге төрекмән әдәбиятында халык мәзәкчесе образы.

— Бу нәмәстәң нәрсә тотачак инде?

— Кайсына нинди җим куясың бит: ипи катысына — тычкан, иткә — мәче каба. Ә синең ишеләргә — ярты савыт хәмер белән бәләкәй кыяр кисәге әрәм итәргә кирәк...

Иң яхшы транспорт

— Кая барышың, Пыхы?

— Шәһәргә.

— Ник мондый транспорт белән әле? Синең автомашинаң бар ич...

— Бу юлы иң шәбе ишәк инде аның. Кунакта күпме телисең — шулхәтле аша, эч. Анда күтәреп атландырсалар, өйгә исә бу озын колак үзе алып кайта. Автоинспекторның синдә бернинди эше юк.

Ияргә атланасы килү

Алар бер арык атка икәү атланып каядыр баралар — баба кеше ияргә утырган, малай исә, аңа тотынып, шактый сөякле сыртка кунакламыш. Җитмәсә тагын бабай аны, «син тормышны белмисең, дөньяны аңламыйсың» дип, бертуктаусыз шелтәләп тә бара һәм нәтиҗә ясап әйтә:

— Мин булмасам нишләр идең икән син?

— Ияргә атланган булыр идем! — дип җавап бирә икән онык.

Таганның кып-кыска җаваплары

* * *

— Хатын-кызлар кайчан бик аз сүзле була?

— Февральдә. Чөнки ул иң кыска ай.

* * *

— Әгәр ике башлы булсаң, син, Пыхы, нишләр идең?

— Бүтән кешеләр башын юләр сораулары белән аптыраткан берәүгә бирер идем.

* * *

— Бу күлдә балык тотарга ярамый.

— Ә мин ник бер дә чиртми монда дип баш катырып утырам бит.

* * *

— Ни өчен бу мөхтәрәм әдип бары тик җәнлек-җанварлар турында гына яза?

— Чөнки алар бит укый белмиләр.

* * *

— Син ник бензин мичкәсе өстендә утырасың?

— Үз-үземне саклар өчен: чөнки тәмәке тартуны ташладым.

* * *

— Эштә эчкәнсең икән, ник өеңә кайтып китмисең инде?

— Хатын кертмәячәк.

БАШКОРТ КӨЛӘМСӘЛӘРЕ*

* * *

— Син ничек уйлыйсың, әнкәсе: малайны өйләндерергә кирәк, минемчә?

— Яшь бит әле, бераз акыл җыйсын иде.

— Акыл җыйгач ничек өйләнсен инде ул?!

* Көлдергечләре.

* * *

— Өеңдә бу карганы ниемә дип асрыйсың, күрше?
— Карга өч йөз ел яши дип раслый галимнәр. Шуңа үзем күреп ышанасым килә.

* * *

— Коймаңны ник шул хәтле биек итеп эшләдең, күрше?
— Бурлар кермәсен өчен.
— Кайсылары: тыштагылары эчкәме, әллә эчтәгеләре тышкы яккамы? — дип елмая сорау биргән күрше.

* * *

— Әмма уңдым да соң инде хатыннан! Кичен, эштән кайтуыма, өстемне салдыра, йомшак туфлиләр, пирчәткәләр китереп бирә.
— Ә пирчәткә нәрсәгә?
— Савыт-сабаны гел шулай резин пирчәткә кидереп юдыра ул миннән.

* * *

— Кичә ник эшкә килмәдең? — дип сорый мастер токарьдан.
— Чирләдем.
— Справкаң бармы?
— Анысы юк югын, әмма пичәте бар — әнә күз төбемдә ул.

* * *

— Доктор, мин йоклаганда кычкырып сөйләшәм. Нишләргә инде?
— Моның гаҗәпләнерлек бернәрсәсе дә юк. Була торган хәл.
— Ләкин эшемдә минем белән бер бүлектә утыручылар да шуңа кушылып сөйләшә икән бит.

* * *

— Сезнең завод эшләгән буяуның сыйфаты гаять начар бит: яңгырдан юыла! Шуны беләсезме?
— Аның каравы безнең буяудан тапланган әйберләрне химчисткага биреп мәшәкатьләнәсе юк...

* * *

— Бу айда без файданы бик күп бирдек.

— Ничек алай булды соң — продукциягезне реализацияләү планын үтәмәгәнсез ич?

— Хикмәт менә нәрсәдә: договор йөкләмәсен үтәмәгән өчен биш меӊ сум, брак өчен — дүрт меӊ, вагоннарны үз вакытында бушатмаган өчен өч меӊ сум штраф түләдек — җәмгысы күпме була? Дәүләт бюджетына менә нихәтле керем!

* * *

— Үткән айда күпме алдыӊ?

— Өчне!

— Өчне? Бик, бик аз?

— Аныӊ каравы бу айда күбрәк булачак!

— Ничек?

— Прогул ясаган өчен беренче яртыда ук дүрт шелтә алдым инде!..

* * *

— Кибетегездә ник черегән яшелчә сатасыз?

— Дөрес түгел! Ни бар запасыбызны үткән атнада ук чүплеккә илтеп аудардык.

* * *

— Ник күрше белән шахмат уйнамый башладыӊ әле? — дип сорый берәүнеӊ хатыны.

— Отылган саен тавыш куптарып чын-чыннан ызгышкан кеше белән син үзеӊ уйнар идеӊме?

— Юк, әлбәттә.

— Менә шуӊа күрә ул минем белән уйнауны ташлады.

* * *

— Бу врачларны әйтәм: рецептларын бераз адәм таныырлык итеп язсалар ни була инде?

— Шаулама, шулай язулары яхшырак: мин бу рецептны күрсәтеп былтыр ел буе трамвайда түләүсез йөрдем һәм... ярты ел опера тыӊладым.

* * *

— Киңәш бирегез әле, доктор, нишләргә икән: минем ирем төн буе саташып сөйләшә?!
— Сез аңа көндез сөйләшергә ирек бирегез!

* * *

— Минем иремә ике хулиган бәйләнгәч качтың, күрше? Ай-һай куркак икәнсең...
— Якын күршеңне кемнәрдер тукмаганны карап торырга кайсыбызның йөрәге җитсен?!

* * *

Караклыкта гаепләп, директор бер хезмәткәре белән аңлаша:
— Алайса, сез цементны каравылчы гына урлый дисез инде?
— Дөп-дөресен әйтәм: чөнки үзем ун ел буе каравыл торган кеше мин.

БЕР ҖЕПКӘ ТЕЗЕП*

«Мине беркем дә яратмый...»

— Нинди җан иясен бик каты яратасың?
— Тычканны,— ди кладовщик.
— Нинди ризык сиңа бик ошый?
— Тычкан,— ди мәче.

* Молдаван, таҗик, кыргыз һ. б. халыклар мәзәкләре.

— Нинди кунакны бик яратып көтеп .аласың?
— Тычканны,— ди тәбе.
Ниһаять, тычканга сорау бирелә:
— Үзең турында нинди фикердә?
— Шуны бик яхшы беләм: мине беркем яратмый.

Хәләл җефет кайгысы

— Зинһар дип әйтәм, дөресен аңлатыгыз әле миңа, доктор: кулы шулай бик чәрдәкләнеп сынгач, минем ирем кайчан да булса савыт-саба юа алырмы икән?

Эше бармый

— Менә аш-су әзерләү китабы алдым әле. Хәзер үзем пешекче булачакмын,— ди икән бер тол ир.— Әмма эшләр бер дә барып чыкмый бит әле...
— Ник?
— Киңәш бирүче бу китапның һәр сүзе «башта чиста савыт алыгыз!» дигән кисәтү белән башлана.

Эшләп ашарга өйрәнү кирәк

Колхоз идарәсендә эшкә елына нибары бер чыккан Ионның гаризасын карыйлар. Ул үзенә акчалата ярдәм итүне сорап язган.
— Сиңа акылга утырырга һәм эшләп ашарга өйрәнергә кирәк,— ди шулчак идарә вәкилләреннән берәү.
— Мин бит киңәш сорарга килмәдем, миңа акчалата ярдәм кирәк! — дип бүлдерә аны хөрәсән булса да әлеге горур зат.

Мәетләрнең телләре юк...

— Мин өшкергәннәрдән берәүнең дә зарланганы юк әле,— дип мактана им-томчы.
— Шулайдыр, шулайдыр. Кәфенгә чорналып ятучыларның телләре юк бит, ничек зарлансыннар?! — дип, авызын томалаганнар мактанчыкның.

Бәхетле егет

— Син кайчаннан бирле машинкада үзең басасың?
— Секретарьшам кияүгә чыкканнан бирле.
— Ә ул бәхетле егет кем инде?
— Үзем.

Үгезен тычкан ашаган

Дәһкан, үгезен сатып, акчасын сандыкка яшергән булган.

Бервакыт әлеге сандыкка тычкан юл салып, шул акчаны кимереп бетергән икән. Бу хәлне абайлап алган дәһкан урамга йөгереп чыгып сөрән салган:

— Җәмәгать, үгеземне тычкан ашады!

«Мунча керергә ярыймы?..»

— Исәнмесез, хөрмәтле табип әфәндебез, хәтерлисезме, узган ел буыннарым сызлап җәфалангач, миңа юештән сакланырга киңәш иткән идегез.

— Хәтерлим,— дигән табип.— Нәрсә, аякларың тагын сызлый башладымы?

— Юк,— дигән хаста,— юештән сакланасы булгач, миңа мунча керергә ярыймы икән дип сорарга килгән идем...

Әбисе аласы пенсия

— Бабай, миңа бурычка егерме биш сум биреп тор әле, пенсия алгач кайтарырмын.

— Нинди пенсия? Сиңа бит әле егерме дә тулмаган!

— Әби аласы пенсиядән.

Ул эштән алынгач кына...

— Кадырали, әйт әле, синең эштә башлыгың нинди — яхшымы әллә яманмы?

— Моны мин ул башлык эштән алынгач кына әйтә алам, беләсең килсә...

Табылган... бүләк

* * *

— Бу эшне ник судка хәтле җиткердегез. Алтын сәгатьне табылдык әйберләр бюросына илтеп бирергә мөмкин иде ич?!

— Шулай итмәкче идем дә, сәгатьтәге: «Бу алтын әйбер сезгә бүләк итеп бирелә!» — дигән язуны укыгач аны үземә калдырырга булдым.

КАЗАКЪ КӨЛКЕЛӘРЕ

Хөрәсән

Каратау авылыннан Каки исемле берәү бала чагында ук чамасыз ялкау була. Бер чакны әтисе аңа ат эчерергә куша икән. Ә Каки әйтә:

— Булдыралмыйм.

— Ник?

— Чөнки алгы тешләрем юк минем.

— Ат эчертү өчен синең алгы тешләрең ниемә кирәк?

— Сызгырып тормасаң, ат бит су эчми диләр...

Вакыт әрәм итеп юкка йөрмә

Дәрәҗәле урын алырга теләүче ике ялагай идарәче бер башлыкка бүләк итеп ришвать китерәләр: берсе бик матур бизәкле касә бирә: тәмләп чәй эчәрсең, ди. Икенчесе исә үгез калдырып китә.

Шуларның беренчесе урын биләргә өметләнеп килгәч теге башлык аңа болай ди икән:

— Синең пиалны үгез басып ватты. Вакыт әрәм итеп юкка йөрмә инде.

Ашатып кара...

Берәүдән сорыйлар икән:

— Ашау-эчүгә нәфесең ничек синең?

— Ризыгыңны куй да ашатып кара, үзең белерсең.

Аксакал киңәше

Бер яшь егет аксакалдан киңәш сорап килә:

— Ата, мин тәмәке тартырга өйрәнәм. Сезнеңчә ничек, файдалымы бу?

— Тәмәке тартуның өч төрле яхшы ягы бар,— дип тезеп китә зирәк агай.— Бердән, тарткан кеше картаймый.

— Ник?

— Чөнки картаерга өлгерми ул, яшьли үлә. Икенчедән, аның өенә беркайчан да бурлар кермиләр...

— Ничек алай?

— Чөнки тарткан кеше төн буе ютәлли, шуңа күрә караклар ул йокламый дип уйлыйлар. Аннары тагын шунысы бар: тарткан кешене эт тешләми.

— Ни өчен?

— Чөнки тәмәке тартучы бик иртә гарипләнә һәм таякка таянып йөри башлый. Ә таяктан, улым, барча эт курка!

Ә килүем өчен өч...

— Эшнең сыйфаты өчен «биш» сиңа,— ди хуҗабикә.

Сантехник слесарь исә аңа үзенекен өсти:

— Ә килүем өчен өч... Димәк, сездән сигез сум тиеш.

Уйлана гына

(Маричадан)

— Сезгә йөзьяшәр булырга нәрсә ярдәм итте?

— Оныгым табыштырган модалы дарулар.

— Шуларны күп куллангдыгызмы соң?

— Ә нигә кулланырга ди? Мин аларның этикеткаларына карап уйланам гына: сырхауласам, бер-ике көн эчендә үк терeләчәкмен!

УЙГЫР МӘЗӘКЛӘРЕ

Асты өскә килүгә каршы

Өй салдырган бер хуҗа балта остасына:

— Син идәнгә дигән такталарны түшәмгә, ә түшәмгә дигәннәрен идәнгә җәй,— ди икән.

Балта остасы, гаҗәпләнеп, ник алай эшләргә кирәк, дип сорагач исә, ул:

— Тиздән мин өйләнәчәкмен. Ә кеше өйләнгәч, өйнең асты өскә килә диләр бит. Менә мин шуңа каршы алдан ук чара күрергә телим,— дип җавап биргән.

Хәйләсен тапты

Бер егетнең бик өйләнәсе килә, әмма эти-әнисенә әйтергә кыймый йөри кән. Беркөнне ашка утыргач, ни булса шул булыр дип, егет үз теләген белдерергә карар кыла. Шулай да җае чыкмый да чыкмый гына бит. Аптырагач, ул янындагы песине:

— Кит эле моннан, җиңгәң утырасы урында мырлап утырма! — дип куа башлый.

Бәп-бәләкәй парчалар *

* * *

— Син, су, нигә шаулыйсың?
— Чөнки үзәнем ташлы.

* * *

Өйләнергә бик теләгән бер Бөкрегә кыз бирмиләр, ә ул исә хатынының әнисе дә матур булуын тели.

* * *

Тычканнарны мәче бары тик үзе өчен тота, ә мәченең хуҗасы аның турында: «И, кыю да соң минем мәчем»,— дип мактана.

* * *

— Сез, азчылык, кая барасыз?
— Күпчелек тарафларына.

* * *

Җиде бажа бергә каядыр атлый һәм аларның барчасы да бары тик бер нәрсә турында уйлый икән: «Йа, хода, янымда бер генә дә сөйләшер кешем юк...»

* * *

Тыйнак кеше бирергә тартына, ә бер оятсыз әйтә икән: «Ул бит миннән курка».

* * *

— Сукырга нәрсә кирәк?
— Ике күз.

---

* Әрмән фольклор персонажлары Чарчи Завен, Никол Петрович, Галоенц Сало һәм Абос иҗатыннан.

Кем кушты, кем үтенде?

(Монголчадан)

Ике дус урамнан уза. Берсе кинәт җиргә авыша башлагач, икенчесе аны куллары белән эләктереп өлгерә. Әгәр ул шуны эшләмәсә, тегесе, әлбәттә җиргә авып имгәнәчәк иде. Ә ул исә иптәшен ачулана:

— Кем кушты сиңа, кем үтенде? Миңа бер бөек зат белән баш иеп исәнләшергә комачауладың ич...

Ник өйләнмәгән?

(Вьетнамчадан)

Ирләр арасында хатыныннан кем күбрәк курка төшә дигән сүз кузгала. Шунда бер монах та бар икән һәм ул, беренче булып: «Мин»,— дип белдерә.

— Соң, сезнең хатыныгыз юк лабаса?!

— Менә шул-шул, куркам, шуңа өйләнмәдем дә.

Егет ник елый?

Бер яшь егет багучыга күренергә килә. Ул аңа син атаңнан егерме ел артыграк яшәячәксең, ди. Ә егетнең атасы аңардан нәкъ егерме яшькә олы икән. Шунда ул кинәт кычкырып елый башлый.

— Этиеңне кызганасыңмы шулай?

— Юк, үземне. Нинди бәхетсезмен мин. Этием үлгәч минем тамакны кем туйдырыр икән?!

Ә ник качтың?

Бер бай хуҗаның ишеге төбендә теләнче күренә. Ләкин байның аңа хәер бирәсе килми.

— Тизрәк кит, табан ялтырат моннан. Кыяфәтләрең җәһәннәмнән качкан кешенекенә охшый.

— Әйе шул. Тәмугътан ычкындым мин.

— Бер эләккәнсең икән, качмаска иде!

— Калган булыр идем дә бит, байлар артыннан барып буламы соң? Бөтен урыннарны анда да шулар алып бетергән.

Кайсы беренче бит

(Немецчадан)

Фрау Мюллер күршесенә зарлана:

— Юк, болай түзеп булмый: минем кызым җыр күнекмәләрен башлауга сезнең этегез улап өрә башлый.

— Аңлыйм сезне, җаным, ләкин бит беренче булып һәрвакыт сезнең кызыгыз керешә.

Ресторанда

— Котлетыгыз тимер кисәгедәй каты бит.

— Әгәр инде шул хәлгә китереп бөккәнсез икән, ашап та бетерегез.

Үтенү

Генрих исемле малай күршеләренең бакча капкасы янына килеп үтенә икән:

— Угымны кереп алырга рөхсәт итсәгез икән?!

— Рәхим ит, балакай. Ә кая булыр икән ул?

— Мин аны сезнең мәчегезгә тидергән идем.

ПАЯШ* УЕНЧА

Аерма нинди

— Транзистор белән дуңгыз абзары арасында нинди аерма бар? — дип сорау биреп Паяш ферма мөдирен аптыраашта калдыра.

— Белмим шул... Бәлки менә дуңгыз караучы кызларыбыз әйтер...

Ә кызлар дәррәү көлеп алалар.

— Батареясы ** булмаса транзистор сызгырып кына тора башлый. Ә дуңгыз абзарында исә йөзләгән чучка ду килеп берьюлы мең төрле тавыш куптара.

Җылы хат...

— Беләсеңме, Паяш,— ди әләкче, гайбәтче һәм бәйләнчек бер зат,— безнең редакция хезмәткәрләре шул хәтле кайгыртучаннардыр дип һич уйламаган идем.

---

* Мари халкының фольклор герое.

** «Батареясы» — биредә «ашамлык» (азык) сүзе белән уйнатыла.

— Нәрсә? Язганнарыңны яратып кабул итәләрме әллә?

— Юк. «Бездән почта расходларын бик күп чыгартмавыгызны үтенеп сезгә ошбу кәрзинне җибәрергә булдык, рәхим итеп алсагыз икән!» — дигән бик җылы хат һәм... кәрзин килде.

Мәче ник юкка чыкты?

— Әбекәй, нинди мич салып бирим сиңа?

— Үзең ничек теләсәң, шулай сал, әмма морҗасы яхшы тарта торган булсын! Монысын үзем тикшерермен.

— Ә ничек тикшерә аласың?

— Мәчегә карап: әгәренки йоны кабара икән шуның, димәк, морҗа шәп тарта. Белгәннәрдән ишеткәнемне әйтәм...

— Ярый, тырышырмын,— дип мыек астыннан гына елмая мичче.

Мич чыгып бетүгә әби шунда мәчесен кертә дә... акылдан язар хәлдә аптырап кала:

— И ходаем, ничек шулай юкка чыкты соң әле минем йомшаккаем?

— Мәчең синең түбәдә инде, әбекәй! Ышандыңмы инде морҗаның ничек шәп тартуына!

Карар кылу

Авылда күмәкләштерү башланган елларда әле яңа гына оешкан колхозга лектор килә. Кабат җыелып тормас өчен, лекцияне дә гомуми җыелышта ук тыңларга булалар. Лекциянең әгәр дә җир менә хәзер кире якка таба әйләнә башласа... нәрсә булыр иде икән дигән фикере тыңлаучыларны бик кызыксындыра... һәм беркетмәгә ул да теркәлмичә калмый:

— Тыңланды: җир шарының әйләнүе турында лекция.

— Карар кылынды: җирнең әйләнүен расларга, ләкин ул бары тик бер генә якка әйләнсен!

Бабай кебек...

— Бабайга ник «Чучка» дидең син, әби?

— Чөнки бераз хәмер капса пычракка керми калмый.

— Ә алай булгач чучкабызны нигә гел иркәлисең генә?
— Чөнки ул синең бабаң кебек.

Ачыкавыз карга түгел, имеш

— Кибетче булып керергә телисең алайса?.. Ярый. Ә моңарчы эшләгән җирләрдә өстеңә чыкмадымы соң?
— Ачыкавыз карга түгел мин, эземә төшә алучыларның булганы юк әле.

Йокы һәм юрган

— Тормышта иң уңайсыз нәрсә ни булганын син, бәлки, беләсеңдер, Паяш?
— Минемчә,— ди ул шактый уйланып торгач,— иң уңайсызы түшәмдә йоклау булырга тиеш.
— Нигә?
— Чөнки ничек кенә ябынсаң да өстеңнән юрган төшәчәк.

ҮЗЛӘРЕ ТУРЫНДА ҮЗЛӘРЕ

Шотландлылар

Сәбәбе бар

Радио тыңлаган өчен ярты бәя генә түлим дигән карарга килә берәү. Сәбәбе шул: чөнки аның бер колагы ишетми икән.

---

* Англия белән Төньяк Ирландия Кушма корольлегенең бер өлешендә — Бөекбритания утравының Төньягында һәм шуңа якындагы Гебрид, Оркней, Шедленд һ. б. утрауларында яшиләр.
Болгариядәге атаклы Габрово кешеләре кебек үк, Шотландия, Фрисландия, Лайхиа, Берген кешеләре дә, барыннан да элек саранлыктан көлеп, үзләре турында үзләре мәзәк сөйләүләре белән бөтен дөньяга танылганнар.

Күп акча

— Син үзеңнең улыңа көндәлек вак-төяк расходка күпме акча бирәсең?
— Атнасына ун шиллинг.
— Бу күп ич!
— Шулай.Ләкин бит ул аны газ өчен акча исәпләүче автоматка сала — шуны копилка дип уйларга өйрәттем.

Курку

— Мин бер пенс акча югалттым, кесәләремне актарып эзләдем инде — юк та юк. Актармаган бер генә кесәм калды.
— Алайга киткәч соңгысын да актар!
— Куркам. Бәлки ул анда да булмас. Аннары мине инфаркт аяктан егуы ихтимал!

Мәетне җирләү кыйммәт...

— Шотландия кешеләре ни өчен бик озак яши?
— Чөнки бездә мәетне җирләү бик кыйммәткә төшә.

Гомерен страховать иткәч

Хатынына кистереп әйтә икән Патрик исемле ире:
— Хәзер сиңа врачларга йөреп акчабызны җилгә очырырга туры килмәячәк.
— Нигә?
— Кичә синең гомереңне страховать иттем!

Өйрәтелгән эт

— Этем бик яхшы бит минем хәзер! Һәркөнне иртән миңа газеталар алып кертә.
— Яхшы өйрәтелгән теләсә нинди эт тә эшли ич моны.
— Ә бит минем газетага язылганым юк.

«Әгәр бер аякка гына бассам?..»

Бер шотландец Парижда кафега керә дә бер рюмка коньяк күпме тора дип сорый.
— Террасада утырып эчсәгез — ике франк, әгәр аяк өсте генә булса — бер ярым.

Шотландлы исә бераз уйланып ала да тагын сорый:

— Әгәр мин бер аягыма гына баскан килеш эчсәм?

«Ярты фунт стерлинг та җитәр...»

Берәүне суга батудан коткарып диңгез ярына яткыралар. Бераз сулыш ала башлагач сөйләшкәндә хатыны аңа әйтә икән:

— Коткарган егеткә бер фунт кына булса да акча бирик инде без!

— Гомумән, бирү, әлбәттә кирәк, кадерлем, ләкин менә нәрсәне дә искә аласы бар: ул ярга чыгарганда мин ярым исән хәлдә генә идем. Димәк, аңа ярты фунт стерлинг та җитәрдер кебек.

Маркасыз конверт

Берәү үз танышларына шатлыгын белдерә:

— Кичә миңа Австралиядәге туганымнан хат килгән. Егерме елга беренче хат!

— Ә нәрсә яза соң ул?

— Белмим. Конверты маркасыз иде, ә мин аны түләп алмадым.

Чәйлек биргәне юк

— Мин инде бер булган ресторанга һичкайчан икенче кат кермим.

— Минем дә официантларга чәйлек акча биргәнем юк.

Онытылмас тәэсир

Күренекле инглиз әдибенә сорау бирәләр:

— Күңелегезгә нинди мактау сүзе бигрәк тә ошаган иде?

— Яшь чагымда бер шотландецның,— ди каләм остасы,— «сезнең бу китап миңа шулхәтле ошады ки, аны сатып алудан көчкә тыела алдым» дигән сүзләрен, һич онытасым юк.

Хакы барыбер ич

Берәү ярты битен диярлек каплаган эшләпәдән кайтып керә өенә.

— Ниемә дип алдың шундый зур эшләпәне?

— Бәхетем булган күрәсең! Бу эшләпә бүтәннәрдән шактый зур үлчәүле булса да шул ук бәягә сатыла иде!

Туп табылган

Ике таныш сөйләшә:

— Син бик куанычлы яңа хәбәр ишеттеңме әле? Безнең теннис клубы биш ел эшләми торганнан соң яңадан ачылган икән бит.

— Димәк, моннан биш ел элек югалган туп табылган...

«Шырпыны да язган...»

Берәүнең өе янгач суд тикшерүчесе бу кеше страховка алу өчен өенә үзе ут төртмәдеме икән дип шикләнә. Прокурор исә аңардан:

— Сезнең бу шигегезне ничек нигезләп була соң? — дип сорый.

— Беләсезме, янып юкка чыккан әйберләр исемлегенә өй хуҗасы ун литр бензин һәм бер тартма шырпыны да язган.

Файдасы бар

Автомобиль фирмасы агенты шотландияле берәүгә:

— Автомобиль сатып алсагыз, ул сезгә бары тик файдага гына булыр,— дип киңәш бирә.— Елына ким дигәндә ике пар ботинкалык акчагыз янга калачак...

Пәкеләре булмаган

Берәү Европа буйлап алты айлык сәяхәттән кайта. Өйдә аны шыксыз итеп сакал-мыек баскан ике энесе каршылый.

— Ник болай ямьсезләндегез?

— Чөнки пәкебезне син алып киткәнсең икән бит.

* * *

— Юл йөргәндә,— дип өйрәтә бер шотландияле үз оныгын,— вагоннан яки каютадан чыкканчы үз әйберләреңне барларга кирәк. Аннары, кем дә булса нәрсәсендер онытып калдырмадымы икән дип, бүлмәне җентекләп тагын бер кат карау бик урынлы.

Теш алу озакмы?

Берәү теш докторына килә:

— Бер теш алдыру күпме тора?

— Ике фунт та сиксән пенс.

— Ә аның өчен күпме вакыт кирәк?

— Ун минут.

— Ун минут өчен өч фунт чамасы!

— Әгәр түзсәгез, ул эшне мин бер сәгатькәчә суза алам.

Кем кемне...

Кондитер кибете хуҗасы бер сатучысына:

— Син сатып алучыларны җентекләп күзәтергә тиешсең. Әнә тегендә берәү алты урынына җиде пирожное алды бит.

— Күрдем мин аны, ләкин акчасын сигез пирожное өчен түләткән идем инде.

Кемгә бу?

Үзен доктордан караткач, берәү ике пенс вак акча суза. Доктор, үзен мыскыл ителгән санап, сорый икән:

— Кемгә бу — миңамы әллә медсестрагамы?

— Икегезгә дә.

Үз үлчәве

Берәү балыктан кайткач хатынына мактана икән:

— Мондый зур балыкның миңа беркайчан эләккәне юк иде әле!

— Соң, кулыңда бит синең балык түгел, ә иске галош!

— Әйе, ул бит әле кырык алтылы үлчәүле галош.

Иртәгә туган көне

Ире эштән кайтуга хатыны яшь аралаш белдерә:

— Зур бәхетсезлек, Джонни! Бәләкәчебез бер шиллинг көмеш акча йотты!

— Әллә ни куркыныч юк, иртәгә бит барыбер аның туган көне...

Ярты хакка эшли

Кунакханәдә берәү лифтерга әйтә:

— Миңа унынчы кат кирәк. Ә син бишенче катка гына җиткердең ич әле.

— Мин биредә ярты хак кына алып эшлим шул, әфәнде.

Файдалы киңәш... янган

Күптән түгел генә өйләнгән яшь ир эштән кайтуга хатынын шелтәли:

— Син кухняда тагын нәрсәдер яндыргансыңмы, әллә көйдергәнсеңме?

— Әйе шул,— дип туп-туры әйтә хатын.— Бусы инде бигрәк тә кызганыч: «Тәмле һәм файдалы ашлар» китабыбыз янды шул...

Алдатмаган

Хуҗа белән хуҗабикә сөйләшеп утыралар:

— Беләсеңме, Шейла, кичә миннән «Савой» ресторанында эчкән бер чынаяк кофе өчен әллә ничаклы акча каердылар! Ләкин гаделлек тә бардыр ахры дөньяда...

— Каян беләсең аның барын-югын?

— Кайтканда кесәмә кулымны тыккан идем, анда ике пар бал кашыгы барлыгын белдем.

Соң ачыклау

Бер хатын ахирәтенә зар белән белдерә:

— Аерылышам...

— Шулай бик тизме? Ә ник?

— Әй, беләсеңме, миллионер картым, аңа иргә чыкканда, миннән ун елга яшьрәк булган бит. Шуны хәзер генә ачыкладым.

Тынычландыру

Бер әби кибеттә ун кило он үлчәүне үтенә һәм шиген дә белдереп өлгерә:

— Белмим, күтәреп кайта алырмынмы икән?

— Курыкма, әбекәй, унны ал: мин аны син өеңә бик җиңел күтәреп кайтырлык итеп үлчәрмен,— дип тынычландыра карчыкны кибетче.

Кем остарак

— Әй бу хатыннар безнең! Юк кына нәрсәдән дә кирәкле әйбер эшли алалар бит! Минеке, мәсәлән, иске юбкасыннан миңа галстук текте.

— Нәрсә ул галстук! Минеке киресенчә, галстугымнан үзенә юбка текте.

Батса да ярый

— Минем дә эти йөзгән тирән суда йөзәсем килә,— дип шыңшына малай.

— Ярамый, улым!

— Ә ник этигә ярый?

— Ул бит страховать ителгән.

Уймак та бүләк

— Мин бүген тапшырасы бүләк синең бармакта бик матур күренер дип ышанам.

— Рәхмәт, иркәм, ләкин кыйммәтле нәрсә ала күрмә, зинһар.

— Алай итмәм. Уймак дигән нәрсәнең кыйммәтлесен кайчан һәм кайда күргәнең бар?!

Балдакны кире кайтара алмый

Берәү якын дусты Мак-Грегордан сорый икән:

— Син Рейчел белән аерылышудан баш тарткансың диләр, дөресме?

— Бүтән чара табалмадым шул: чөнки ул шулхәтле чамасыз симерде ки, мин биргән никах балдагын да бармагыннан салып кире кайтара алмый.

Исәп-хисап...

Ире ниндидер ерак сәфәргә җыенгач, хәләл җефете аңа маркалы конверт бирә икән.

— Син кәгазь алырга, әлбәттә, акча әрәм итмәячәксең, үзең турында хәбәр белдерү өчен дә, билгеле, акча тотмаячаксың һәм язарга иренүеңә дә ышанычым җитәрлек. Менә конверт һәм марка тоттырам сиңа, буш конверт кына җибәреп булса да үзең турында белдерә күр инде, этисе!

— Конвертны алам, карчык, хатны исә шул конвертта биредә түләп алу шарты белән маркасыз гына җибә-

рермен. Син аны түләп алмаска тырыш, почта миңа кире җибәрсен, димәк, мин синең исән-саулыгың хәбәрен бер тиен түләмичә белгән булырмын.

Ничек җылытыла

— Шотландиядә шифаханәләр ничек җылытылганын беләсеңме?

— Юк.

— Югары температуралы сырхаулар аны палатадан палатага кереп җылыталар.

Автомобиле матур

— Киявең матурмы, Эльза?

— Искиткеч! Күзләре нәкъ әнинеке кебек зәп-зәңгәр, ә автомобиле — этинең ярышларда чабыш машинасы шикелле.

«...Анысы түләүсез»

Таксист белән сөйләшү:

— Вокзалга илтеп куйган өчен күпме аласың?

— Өч фунт.

— Ә чемодан өчен?

— Аның өчен түләнми.

— Алайса, кунакханәдән алып минем чемоданны китерерсез. Үзем алдан җәяү барып сине көтә торам.

Счетны этисенә яздыра

Бер шотландлы яшь хатынын теш докторына алып килә. Шуны карагач доктор әйтә икән:

— Өч тешен моннан өч ел элек үк алдырырга кирәк булган...

— Миңа иргә чыкканчы укмы?..— дип сорый аптыраешта калган ир.— Алай булгач аны дәвалаган өчен счетны үз этисенә җибәрегез!

Берьюлы ике шырпы сызып

— Җитте! Моннан соң саранланып бер пенса акча җәлләп калтырап торасым юк. Бер лотерея билетыма биш мең фунт оттым бит! — дигән бер шотландлы, сигарасын берьюлы ике шырпы сызып кабызган икән.

Ярты хакына...

Берәү кибеттә телевизор сайлый. Кибетче аңа күп төрлесен күрсәтә, ә ул башын гына чайкый бирә. Ниһаять, сатучы аңа тагын бер киңәш-тәкъдимен әйтә:

— Тагын бер телевизор бар, анысы каталог бәясенең яртысына сатыла.

— Ә каталогы күпме тора соң аның?

Арзанрагын эшлә

— Чәч кыркыту күпме тора? — дип сорый бер шотландлы Париж парикмахерыннан.

— Биш франк та илле сантим.

— Ә кырыну?

— Ике франк.

— Алайса минем башны кырыгыз гына әле.

Исеңә төштеме

Ике шотланд әдибе очраша:

— Нәрсә язасың хәзер?

— Автобиографиямне.

— Я, эшләрең барышы ничек соң? Мин сиңа бурычка ун франк акча биргән елларга җиттеңме әле?

Сәүдәгә өйрәтү

Күз докторы үзенең эш тәҗрибәсен улына өйрәтә:

— Кем дә булса күзлек пыяласы сорап килсә, 15 шиллинг тора дип әйт һәм бу аңа ничек тәэсир иткәнен җентекләп күзәт. Бернәрсә дә сизмәсәң күзлекнең тирәлеге бәясен әйт һәм ике линза өчен тагын 10 шиллинг түләт. Аннары ул үз-үзен ничек тотканын кабат күзәт. Әгәр тотышында үзгәреш күренмәсә, сездән күзлек өчен җәмгысе фәлән хәтле шиллинг кирәк дип зуррак бер сан әйт.

Чемоданда... энем

Вагонда билет тикшергәндә кондуктор бер өлкән агайның бала билеты белән баруын белә һәм аңардан штраф түләүне таләп итә. Шотландлы агай моңардан катгый рәвештә баш тарта. Ә кондуктор исә шул чакны, тәмам шашынып диярлек, аның юл чемоданын тәрәзәдән ата, ә шул минутта поездның тимер юл күпереннән узуы була икән.

— Сез тәмам акылдан яздыгызмы әллә?.. дип кычкыра шотландлы ярсу белән.— Башта минем билетны ошатмадыгыз, инде менә энемне дә суга батырдыгыз.

Күпсену

Аппендицит операциясеннән соң больницадан чыкканда бер шотландлы шактый кызып һәм ачуланып врачка соңгы сүзләрен әйтә:

— Нибары алты мәртәбә энә чәнчеп алган өчен миннән утыз фунт аласыз. Беләсе иде, әгәр костюм тектергән булсам, мин күпме түләргә тиеш булыр идем икән?

Үтенеч

Берәү кибеттән этенә ашатырга дип сөяк сатып ала.

— Тагын нәрсә теләр идегез? — ди сатучы.

— Шул үлчәгән сөякне генә бүгенге газетага төреп бирсәгез икән!

Яртысын үтүкләү җитә

Берәү тегүчегә килә һәм сорый:

— Чалбар үтүкләгән өчен күпме аласыз?

— Егерме пенс.

— Яхшы. Миннән унны гына алыгыз. Чөнки фотографиягә барышым, мин анда бер яным белән генә басып төшәчәкмен.

Фрисландлар *

* * *

— Ни өчен фрисландларның колаклары тырпаеп тора да маңгайлары бик яссы була?

— Чөнки алар, «Син нәрсә әйттең әле?» дип сорап, кулларын колакка бик еш якын китерәләр һәм соңыннан исә: «Ә, шулаймы әле!» дип, маңгайларына учлары белән сугып алалар.

---

* Фрисландлар — Германия Федератив Республикасында Голландия белән чиктәш Түбән Саксониянең бер өлеше халкы.

* * *

— Ни өчен Фрисландиядә диңгезнең ярга тулган һәм ярдан чигенгән чаклары күп була?

— Фрисландлар диңгез ярына беренче тапкыр килеп чыккан чакта, диңгез, аларның кыяфәтләреннән куркып, чигенә. Шуннан бирле ул, һәр алты сәгать узган саен, тегеләрнең киткәнме-китмәгәнме икәнен белер өчен ярга кире кайта.

* * *

— Ни өчен Фрисландия җирләре тоташ тигезлектән тора?

— Фрисландларның һәркайсы якшәмбе көнне аларга кунакка кем киләсен сишәмбе көнне үк алдан күреп торсыннар өчен.

* * *

— Ни өчен Фрисландиядә полицейскийлар парлашып йөри?

— Чөнки аларның берсе бары тик укый, ә икенчесе бары тик яза гына белә.

* * *

— Ни өчен кичке аш вакытында бер фрисландлы ут кабызган фонарьлы велосипед белән өстәл тирәли йөри?

— Гаиләсе ут яктысында ашасын өчен.

Берген кешеләре *

Вагонда сөйләшү

— Тронхейм яхшы кала бит, дөресме,— ди беренчесе.— Әгәр Ослода тумаган булсам, үземнең Тронхеймда тууымны теләр идем.

Тронхейм кешесе бу комплиментка үзенчә җавап бирә: — Әгәр Тронхеймда тумасам, мин Ослода туарга теләр идем.

---

* Норвегия шәһәре Берген кешеләре дә үзләре турында үзләре уйлап чыгарып мәзәк сөйләргә бик осталар икән.

Бергенлыга инде әйтер сүз калмады дип болар икесе дә бер төрле уйлый һәм Ослоныкы аңа юри сорау бирә:

— Ә сезнеңчә ничек?

— Әгәр Бергенда тумаган булсам, мин гомумән беркайда да тууымны теләмәс идем.

Балык базарында

— Менә хәзер генә судан тоткан балык сатам!

— Хәзер генә дисеңме? Яле башта мин аның беләи сөйләшеп алыйм,— дип бер ханым нидер мыгырдап балыкка иелә.

— Нәрсә лыгырдыйсыз анда?

— Диңгездә нинди яңалыклар бар дип сорадым.

— Ә-ә! Я, нәрсә диде соң балык?

— Белмим, чөнки мин инде диңгездә ике атна булганым юк,— ди.

Берген яңгыры турында

Читтән килгән бер кеше бер баладан сорый икән:

— Сездә бу яңгыр кайчан да булса туктыймы?

— Белмим,— ди малай,— чөнки миңа ун гына яшь әле.

Тикшереп белде

Осло шәһәреннән дәрәҗәле бер әфәнде, Берген балалары сүз эзләп кесәгә кереп тормый, дигәнне ишетә дә шуны Бергенга беренче килүендә үк тикшереп карамакчы була. Вокзал тирәсендә газета сатып йөргән бер малай янына килә дә сорый:

— Ә иртәгәге көн гәзитләре бармы синдә?

Малай күз ачып йомганчы әйтә аңа:

— Әлбәттә юк. Мин, аларны, абзыкай, инде кичә үк сатып бетердем.

Душ бүлмәсе

Берәү яңа өй сала, ләкин аның бер бүлмәсе өстенә түбә япмый.

— Бу ни гаҗәп эшләвең? — дип сорый аңардан күршесе.

— Душ бүлмәм була ул минем,— ди исәп-хисабы бик хирыс хуҗа.

Ит кибете ачкач

Ит кибете хуҗасы газетада кыска гына белдерү бастыра: «Түшкәләр турарга ярдәмче яллыйм. Эшкә керергә теләүче вегетарианец булсын иде дигән теләгем бар».

Борчылма, алырсың

— Кичер, хуҗа, ләкин бит мин, үзара әйткәндә, өч кеше өчен эшләп тә быел әле бернинди эш хакы алганым юк,— ди бер көнлекче.

— Яхшы, яхшы. Кичерәм, әлбәттә,— ди хуҗа аңа.— Эш хакы турында гомумән киләчәктә дә борчылма син, тиешен алырсың... Ә менә теге ике кешенең исемнәрен әйт, аларны мин эштән чыгарырга тиешмен!

Лайхиалеләр иҗат үрнәге *

Редакциягә хат

Бер газета редакциясенә Лайхиадан хат килә. Тулы тексты менә нинди була аның: «Әгәр безнең хакта мәзәкләр бастыруны туктатмасагыз, мин беркайчан да сезнең гәзитне күршемнән алып торып укымаячакмын».

---

* Финляндиядә Лайхиа дигән бәләкәй кала кешеләренең үзләре турында үзләре уйлап чыгарган мәзәк һәм шаян хикәятләр сөйләүләренең дә шундый бер хикмәте бар икән: гадәт буенча, көненә берәрне сөйләргә, бары тик икенче көнне генә көләргә, ә өченче көнне аны иң якын дустыңа ирештерергә кирәк.

МӘСӘЛЛӘР БУКЕТЫ

Кибетче һәм куян

Азык-төлек кибетенә бер куян килеп керә дә:
— Сездә какао бармы? — дип сорый.
— Юк, бездә какао булмый.
Шуннан соңгы икенче, өченче, дүртенче көннәрдә шул ук куян килеп шушы ук сорауны кабатлый.
Кибетче җеннәре чыгып ачулана да әйтә аңа:
— Бездә какао юк, әгәр тагын бер килеп күренсәң, мин синең колагыңны кибет ләүкәсенә кадаклаячакмын!
Иртәгесен куян тагын килеп керә һәм сорый:
— Сездә кадак бармы?
— Юк һәм булмый да! — дип акыра кибетче.
— Алайса, сездә, бәлки, какао бардыр?..

Ике әтәч

Ике әтәч бик каты сугышкан икән. Җиңелгәне каядыр кереп поскан, ә җиңгәне биек бер түбәгә менгән дә тамак ярып кычкыра, мактаныпмы-мактана. Шунда аны бер бөркет күреп алган һәм... эләктереп тә киткән.

Шуны көтәргә кирәк иде дә

Ишәкне «Дуслар-куяннар» исемле журналның баш редакторы итәләр. Ул исә редколлегиягә бүрене, төлкене, селәүсенне һәм бөркетне сайлата да үзе иҗат командировкасына китеп бара.
Журналның беренче санында ук редакция: «Куян итеннән куырдык» дигән темага иң яхшы рецепт яза алучы аш-су осталарының конкурсын игълан итә.

Юл уңае түгел

Мәскәүнең ике зур урамы чатында такси машинасын туктата бер дөя:

— Хөрмәтлем, Сахарага илтеп куймассыңмы икән мине? — ди.

— Юк, булдыра алмыйм,— ди шофер гадәтенчә,— паркка кайтышым минем.

Таяныч кирәк...

Урманда яңа ял йорты салырга булалар. Биек үргә мендереп, саф һавалы иң яхшы урында! Ләкин анда бүрәнәләрне меңгерү кыеннан да кыенрак эш булачак. Шуңа күрә төзелеш башлыгы итеп төлкене кую хуп күрелә:

— Бик зур хезмәт хакы алырсың, квартал саен бүләк булачак. Тау итәгендә семьяңа дүрт бүлмәле фатир эшләтербез, телефоның булыр. Алын шул эшкә!

— Мин риза,— ди төлке,— ләкин бер шарт белән: миңа урынбасар да бирерсез.

— Кемне алырга телисең?

— Үгез яхшы булыр.

...Хәзер төлке көннәр буе телефоннан тәкелди, ә үгез җан тирләрен түгеп эле дә булса үргә агач ташый, ди.

Үз урынында

Бүре, барс һәм селәүсен бергәләп колхоз фермасын басарга җыена. Караңгы төннәрнең берендә алар юлга да чыга. Шулчакны барс аларга ияреп төлке дә барганын күрә дә бүрегә сорау бирә:

— Ә төлкене ник чакырдың?

— Эзебезне яшерергә кирәк ул! — дип белдерә бүре.

Бюрократизмның файдасы да була

Ач бүре аңардан качып йөргән бер кәҗәне тарлавыкта очрата:

— Я, эләктең бит, ниһаять! Менә шушы минутта ук тотам да ашыйм сине.

— Рәхим итәсез, олугым. Мин үзем дә шуның өчен сезне күптән эзләп йөрим бит инде.

— Ничек? Димәк, сине үз теләгең буенча ботарларга тиеш булам?

— Бик тә дөрес әйтәсез.

— Алай булгач, эш үзгәрә бит: сездән миңа үз кулыгыз белән язган гариза кирәк. Бездә тәртип шундый.
Кәҗә әле һаман да исән-сау икән.
Ә гаризасы аның инстанцияләрдә йөри, ди, әле.

Сөзә дә сөзә

Кәҗә нәшриятта баш редактор булып ала. Берсеннән берсе калынрак яңа китаплар бер-бер артлы чыга башлый: «Яфраклар»... «Яшь бөреләр»... «Куактан — куакка». Шулар өстенә бакчачылык турында инде күптән язылган кулланмалар кат-кат чыгып тора. Ә бүтән кульязмаларның барысына да кәҗәнең бары бер генә кыска имзасы салына: «Сөзәргә!»

Керми...

Кәҗәне сәүдә оешмасына чакыралар да җаваплы эш тәкъдим итәләр: «Яшь кәбестә» кибетенең директоры буласың. Бүген үк эшне кабул ит!
Куанасы урынга, кәҗәбез еларга җитеп ялвара башлый:
— Кермим, кермим! Зинһар, көчләмәгез. Берәр гаебем булып эштә аклатасыгыз килә икән — бүтән урын табылсын. «Кәбестә»гә кереп ачтан үләсем килми минем.

Сәнгать белгече

Сәнгатьне бик яхшы белә дигән дөяне урамда ишәк очрата:
— Сез, хөрмәтлем, «Өнсез бозлык» дигән фильмны карадыгызмы? Аның турында менә дигән шедевр дип сөйләүчеләр дөресен әйтәме?
— Нинди шедевр булсын, ди! Эчпошыргыч бер нәрсә шунда! — дип белдерә дөя үз фикерен.— Кинотеатрда ике сәгать чамасы катып утырдым. Һәм нәрсә булды дисеңме? Өтек кенә булса да бер дөя дә күрсәтмәделәр!

Чыпчыклар

Бик елгыр һәм үтә үткен ике чыпчык бәхәсләшә:
— Мин акыллыракмын!
— Юк, мин!
— Юк, мин!

Шуны бер тукран күреп һәм ишетеп тора икән һәм аңа: «Кайсыбыз хаклы?» дигән сорау бирелә.

— Минемчә, чыркылдавыннан беренче булып туктый алганыгыз хаклы булачак,— ди аларга кырыс тукран.

Кирәк түгел

Трибунага чыгып куян сүз башлый:

— Безнең барыбызга да шуны белергә кирәк...

— Кирәк түгел,— дип бүлдерә аны бүре шул минутта.

— Әйе, шулай,— дип дәвам итә куян,— безнең барыбызга да белергә кирәк түгел.

Ни өчен мактыйлар

— Ни өчен барысы да сандугачны мактый болай? — дип аптырый бер тутый кош.— Ул бит кеше төсле бер авыз сүз дә әйтә алмый...

Әтәч түгел... күркә

Көннәрнең берендә тавис кошы театрда әтәч булып уйный. Ә тамашачы исә, «Әтәч түгел, күркә ич бу!» дип уйлый икән.

Керпе һәм барабан

Бер керпе бакчага каяндыр барабан өстерәп килә дә алмагач төбенә куеп калдыра.

Төнлә барабан өстенә алмалар коела башлый һәм ул дөбердәргә тотына.

Шуны ишетеп керпе бакчага йөгереп килә, коелган алмаларның бөтенесен үз энәләренә кадап оясына алып китә.

Төнге утлар

Бер төнне куяннар ут кортына: «Без караңгыдан куркабыз»,— дип әйтәләр икән.

Ут корты тиз генә каядыр китеп бара да бик күп бүтән ут кортларын ияртеп килә һәм алар куак ботакларына сибелеп урнашалар. Урман эчендә бик күп фонарьлар кабынган кебек була.

Юл бирсеннәр өчен

Бер арыслан урман буйлап труба кычкыртып бара — кырмыскалар, вак бөҗәкләр һәм коңгызлар әйтә икән шул чакны:

— Таптап узмас өчен безнең аңа юл бирүебезне сорый,— дип юаналар икән.

Бәла булмый кала

Бер кырмыска чык тамчысы эченә кереп бата да бүтән кырмыскалар ярдәмгә килсен өчен тавыш бирә.

Оядан кырмыскалар күпләп йөгерешеп киләләр дә аңа ярдәм итәр өчен салам кисәге эзләргә китәләр.

Алар шуны тапкан арада исә чык тамчысы инде кипкән була.

Үрмәкүч

Куак ботаклары арасына пәрәвез үрә бер үрмәкүч.

— Нишлисең болай? — дип сорый кырмыскалар шуңардан.

— Шауламасын өчен, җилне бикләп куям. Чөнки йокыма комачаулый.

Бердәнберне сайлау

Килен буласы бер чибәр бик акыллы һәм хуҗалыкчыл икән. Аңа өйләнергә теләгән һәр ир күктән йолдызлар чүпләп бүләк итәргә әзер ди. Ә ул француз туны табып биргән бердәнбер кешегә чыга.

Кирегә атлаучы зат

Ул үтә заманча кеше була. Үзен шуның белән бер адымда атлаучы дип саный. Бары тик алга гына карап атлый. Ә бервакыт як-ягына күз салса, беркемне дә күрми икән. «Шулай бик күпләрне артта калдырдыммы икән эллә?» — дип уйлый. Чөнки үзенең һаман кире якка атлавын белмәгән икән.

Кемгә ничек

Барча җәнлекләр дә кешкә соклана:

— Менә ичмасам моның мех!

Ә кеш исә, уфтанып, әйтә:

— Сез дә минем тиремдә булып карасагыз икән...

Хәйләкәр ләкләк

— Нишләп син болай һаман сыңар аягыңда гына басып торасың? — дип сорый камчат ләкләктән.

— И тилекәем! Нишләп ди әле мин ике аягымны да берьюлы чылатырга тиешмен?

Куяннан качуы кыен

Аю бер куян артыннан куа-куа бик тиз арый, төп башына утыра да үзалдына уйлый: «Менә сиңа җен каккан әрсез җан да икән ләбаса бу. Ярый әле мин аны куа килдем... Әгәр ул минем арттан чапкан булса?»

Үтә нәзберек

Кыргаяк зоопарк җәнлек-җанварлары җыелышына соңгарып килә.

— Ни галәмәт бу? — дип гаҗәпләнә һәммәсе.— Соң бит син кырык аяклы җан иясе.

— Шул шул менә, һәр бусагада аяк сөртергә кирәк иде миңа.

Тавык һәм йомырка

Безнең кайсыбыз якты дөньяга беренче булып килде дип, тавык белән йомырка бәхәсләшә.

— Мин,— ди тавык.

— Юк, мин,— дип каршы төшә икән йомырка.

Шуны үзләре берничек тә хәл итә алмагач, алар, ниһаять, судьяга киләләр.

— Беренче булып тавык дөньяга килә,— ди судья.— Йомыркадан, әлбәттә...

Арыслан һәм тычкан

— Әйт әле, арыслан, нигә сине күрүгә бөтен җәнлек-җанвар качып котылырга ашыга. Ә миннән берсе дә курыкмый,— дип сорый тычкан.

— Шуңа ул...— ди арыслан, һәм авызын бик зур итеп ачып, янәсе үзе дә сизмәстән, тычканны йотып та куя.

Кеше һәм ишәк

Бер кеше ишәк сатып ала.

— Әй, кеше, нигә кирәкте сиңа ишәк? Шундый тискәре җан иясе белән эш итү урынсыздыр кебек.

— Әйе! Әгәр үземә атланып йөрергә тырышучылар табылса, мин дә шулай үз сүземдә ничек торырга кирәген белергә телим.

Роза һәм чәнечкеләр

— Роза бик яхшы һәм матур чәчәк,— ди лилия,— ләкин чәнечкеләре бар.

— Роза? Болай ярыйсы чәчәк кебек. Әгәр чәнечкеләре булмаса...— ди икән кактус та.

Чырай һәм көзге

Бер чырай көзгегә карый. Ә көзге:

— Күрәсеңме, нинди зурмын мин. Иркенләп сыя алдың ич менә. Син генә түгел, меңләгән бүтән чырайлар да сыя ала шулай.

— Чөнки бит синең үз йөзең юк,— дигән җавап ишетә көзге.

* * *

Куян, җәнлекләр җыелган аланга килгәч, тиеннең елап торуын күрә.

— Бу ни эш, кем кыйнады тиенне? — дип сорый ул, гайрәтләнеп.

— Мин,— ди аю.

— Шул кирәк аңа! — ди куян пышылдап кына һәм тиз-тиз китеп бара.

Бурсык законы

Юл буйлап искиткеч зур тизлек белән ике тычкан чаба.

— Кая ашыгасыз болай? — дип сорый бер тиен агач башыннан.

— Менә үзара талаштык әле. Шуны ачыклар өчен бурсыкка барырга булдык.

— Ә ашыгуыгыз нигә?

— Чөнки бурсыкның бит законы-кагыйдәсе шундый: беренче булып килгәннәрнең барысын да хаклы саный ул.

Бәхәс

— Син нәрсә бүре булып карыйсың әле? — дип сорый бер ана бүре иреннән.— Кем дә булса үпкәләтте яки ачуландырдымы әллә?

— Әйе, әлеге дә баягы куян инде,— ди бүре күзен ялтыратып.— Фәнни конференциядә арабызда бәхәс чыкты. Мин кырыккан дим, ә ул үзенекен сукалый — пәке белән кырган дип тукый! Мин — кырыккан! Куян — кырган! Мин — кырыккан. Куян...

— Я, ни белән бетте соң? — дип кызыксына бүребикә.

— Ә мин аны тоттым да ашадым,— дип йомгаклый сүзне бүре.

Тәртипле тәкә

— Сез чакырдыгызмы мине? — дип сорый тәкә, абзарга кереп.

— Килдеңме? — ди үгез, бераз җиңел сулап.— Юкса нишләргә белми баш ватып тора идем әле менә. Ике көн рәттән инде эштә күренмисең. Тагын прогуллыйсыңмы?!

— Һич юк! — ди тәкә бераз үпкәләгән итеп.— Сезнең әмерегезне үтим.

— Ниткән әмер ул?

— Соң бит сез миңа ачыктан-ачык әйттегез: «Моннан соң минем күземә күренәсе булма!» — дидегез.

Сахарада... аюлар

Ике ак аю Сахарага барып чыккан, имеш.

— Шайтан алгыры, монда бик тайгак, ахрысы!

— Ник алай дисең?

— Күрмисеңмени, күпме ком сипкәннәр?!.

Бүләк... бүтәннәргә

...Кызга ул йөрәген бүләк итә. Ә кызый исә, бик салкын канлы һәм саксыз булганга, бүләкне кулыннан төшереп чәлпәрәмә китерә. Егет исә шул кыйпылчыкларны җыеп бүтән хатын-кызларга бүләк итә башлый.

Кеше арасына кергәч

Булган, ди, яшәгән, ди, мәсәлдән мәсәлгә күчә-күчә бер ишәк. Ниһаять, бу яшәеш рәвеше аны тәмам туйдырган булса кирәк, ул да кеше арасына керергә тели. Һәм керә дә. Шул хәтле ошый икән бу аңа, инде хәзер бернинди көч белән дә мәсәлгә кертү мөмкин түгел, ди, ишәк хәтле ишәкне.

Ничек бүләргә?

Бервакыт арыслан, бүре һәм төлке табышларын үзара бүлешергә сүз куешалар. Икенче көнне үк аларга сарык, куян һәм тавык эләгә.

— Гадел генә итеп бүлеп бир әле шуларны,— ди арыслан бүрегә.

Бүре бүлә башлый:

— Сарык,— сиңа, куян — миңа, тавык — төлкегә.

— Тинтәк! — дип үкерә арыслан һәм бүрене кисәк-кисәк теткәләп ташлый. Аннары ул төлкегә дәшә:

— Ә син ничек бүләр идең?

— Сарык — сиңа иртәнге ашка, куян — сиңа әбәткә, тавык — сиңа кичке ашка.

— Яхшы,— ди арыслан.— Кем өйрәтте сине шулай гадел бүләргә?

— Бүре...

Дөя уенча

— Маймылны кеше иткән нәрсә — хезмәт, диләр. Шулайдыр. Әмма,— ди дә дөя көрсенеп бер төкереп куя.— Эшләп чыгарган бер бөкресе дә юк бит аның. Биредә, әлбәттә, ниндидер кулның катнашы бар. Бары тик шулай гына булу мөмкин...

Аю әйтә

— Тормышта иң мөһим дип нәрсәне санныйсыз?

Аю әйтә:

— Минемчә, тәпи белән табандыр алар.

— Ә музыкага карашыгыз ничек?

— Рөхсәт итсәгез, колагыгызга пышылдап кына әйтим моңа җавапны.

Кара каргага сорау

Кара каргага сорау:

— Ак каргага карашыгыз һәм аңа карата теләгегез нинди?

— Аны ничек кенә булса да каралтырга иде.

Яхшы фикер нәрсәдән туа?

— Сезнең күңелдә иң яхшы фикерләр нәрсәдән туа? — дип сорыйлар филдән.

— Тычканнар кыштырдавыннан.

Чебешләр көзен санала

— Чебешләрне көзен санылар дигән фикер дөресме?
— Минемчә, көзен аларның саны кими дип әйтергә кирәктер,— дигән җавап бирә төлке.

Бер оядан дүрт чебеш

Кем алдан килә

— Нишләп син бу бөртекне кабып йоттың? Аны бит башта мин күрдем! — ди бер чебеш.
Икенче чебеш исә аңа болай ди:
— Ә мин аңа беренче булып йөгереп килдем.

Чебеш фикере

— Зур үскәч мин дә күкәй басып чебеш чыгарам, ләкин аларны карамаячакмын,— ди бер чебеш.
Икенчесе әйтә аңа:
— Кая куячаксың балаларыңны?
— Аның өчен минем әнкәм тавык бар!

Ник куркасың?

— Бүген гомеремдә беренче йомырканы салдым,— ди тагын бер чебеш.— Ләкин шуны әнигә әйтергә куркам.
Икенчесе сорый:
— Ник куркасың?
— Шул минуттан башлап бәлки ул мине канат астына алмый башлар!

Дәү үскәч

— Күрәм, син инде әтәчләргә күз төшерә башлагансың! — ди бер чебеш.
Икенчесе әйтә аңа:
— Нигә төшермәскә ди? Мин бит инде ояга үзем очып керә алам.

ШИНЕЛЬЛЕ ЮМОР

(Бүгенге көн хәрбиләре елмаюларыннан)

Нәрсә комачаулый

— Әйтегез әле, рядовой Синько, сезгә иң алдынгы һәм үрнәк солдат булырга нәрсә комачаулый?
— Тумыштан ук тыйнак һәм тәбәнәк булуым.

Көтеп тә тора ала

— Сез нәрсә, чираттан тыш наряд алырга телисезме әллә?
— Юк, иптәш старшина! Мин аны бик озак көтеп тә тора алам.

Минемчә... бик башлы кеше

— Матрос Кариев! Гальваник ударлы минаны кем уйлап тапкан?
— Минемчә, бик акыллы һәм башлы кеше.

Киресенчә

— Сержант Крапивин! Сезне минем сорау бик уңайсыз хәлгә куйдымы әллә?
— Киресенчә. Үзем бирәсе җавап уңайсызландыра.

Артымда ни була

Сержант, солдатларга дөнья кыйтгаларын аңлатып сөйли дә:
— Әгәр мин йөзем белән көнчыгышка карап бассам, артымда ни була? — дип берсеннән сорый.
— Сезнең күләгәгез, иптәш сержант,— ди солдат.

Язусыз хат

Бер солдатка килгән хат конвертыннан чип-чиста кәгазь бите генә чыга.

— Бу ни? — дип сорый иптәше.

— Хатын хаты.

— Бернинди язусыз ич ул?

— Бер үпкәләшкән идек, шуннан бирле сөйләшә башлаганы юк әле.

Бүгенге яра түгел...

Бер офицер сакал-мыегын кырырга парикмахерга керә.

— Мин сезне моңарчы да кырган идем бугай, иптәш капитан?

— Ялгышасыз, бу минем сугыштан калган яра эзе,— ди офицер елмаеп.

«Кассалардагы билетларны яндырырга...»

Лейтенант яңа солдатлар белән тактика буенча занятие үткәрә.

— Барысы да аңлашылдымы? — дип сорый ул соңыннан.— Яле, рядовой Кнопка, дошман тимер юлдан файдалана алмасын өчен нишләргә кирәк?

— Кассаларны кулга төшерергә һәм бөтен билетларны яндырырга.

Повар мактаган

— Хезмәт итә башлавыңа ел тула инде, бер мактау да алганың юк бит әле.

— Юк, син генә белмисең! Ротада һәркем раслар: аппетитым әйбәт булган өчен повар әллә ничә тапкыр мактады инде.

Очраклы очрашу

Самолетта солдатның күзе бер кызга төшә. Ләкин аңа эндәшеп ни дә булса әйтергә һич кенә дә кыймый. Ниһаять, кыюланып, сүз башлаган була ул:

— Гафу итегез, сез дә бу самолетта очасызмы әллә?

Син шаярттыңмы?

Сержант үз кул астындагы рядовой Петровтан сорый:
— Погоныма тегелгән сары тасмалар саны аның ничә баласы барын белдерә дип син шаяртып аңлаттыңмы әллә мин яратып йөргән кызга?

Әнисе яза

Бер солдат үзен ефрейтор иткәннәрен белдереп әенә хат юллый.
Карт әнисе исә аңа үзенең киңәшен әйтеп яза:
— Кара аны, улым, үз генералларыңны берничек тә рәнҗетә күрмә анда син.

Солдатча караш

Вакытлыча ялга кайткан бер солдат әтисе белән каядыр барган юлда һәммәсе бер үк төрле мини юбка кигән дүрт кыз очрый. Солдат кинәт туктап кала һәм шуларга күзен тутырып җентекле карый икән һәм әйтә әтисенә:
— Күрәсеңме, әнә берәве бүтәннәр белән бер аякка бердәм басып атлый белми.

Сәбәбен ачыклау

— Ефрейтор Калючкин синең белән ник бик коры сөйләшә? Үпкәләштегезме әллә?
— Юк, без тату хезмәт итәбез. Ә Калючкин минем кимчелекләрем белән килешә алмый. Шуңа корырак күренәдер, бәлки.

Ник соңарган

Әле яңа гына хәрби частька килгән солдаттан сорый старшина:
— Сафка чыгып басарга ник соңардың?
— Гаеплемен. Ашыгу сәбәпле ялгышлык эшләнелгән: уң аяк итеге сул аякка киелгән.

Белә, имеш

— Солдат Ивашкин, автомат нинди төп частьлардан тора?
— Тимердән, агачтан һәм пластмасстан эшләнгән частьлар алар, иптәш сержант.

Йөз процент гарантия

— Сөйгән кызың сине көтәсенә чын күңелдән ышанасыңмы, Гәрәй.

— Йөз процент гарантия белән!

— Нәрсәгә таянып әйтәсең моны?

— Армиягә киткәндә мин аның транзисторын ремонтладым, ләкин ул яртылаш кына эшләнде. Калган хәтлесен хәрбидән кайткач ремонтларга тиешмен әле.

Әгәр чыпчык кунса...

— Яңа килгән бер солдаттан юри сорый икән сержант:

— Әгәр карабинның мушкасына чыпчык кунса, солдат нишләргә тиеш?

— Йокыдан уяныргa кирәк!

Төшендәдер дип уйлаган

— Урыннардан торыгыз! — дигән команда буенча яңа алынган солдатлар ятактан бердәм кубалар. Бары тик берәве генә ятып кала.

— Сез нәрсә, команданы ишетмәдегезме әллә? — ди аңа офицер.

— Ишетүен ишеттем, ләкин нигәдер төшемдә генәдер дип уйланылды.

Казан кайната белү

Армиягә яңа алынучыларны сафка тезә дә:

— Арагызда казан кайната белүче бармы? — дип сорый сержант.

— Мин беләм! — ди берәү.

— Зур казанны да кайнатканыгыз булдымы?

— Әлбәттә!

— Нәрсә кайнаттыгыз?

— Сумала.

Ике яңалык

Старшина армиягә яңа алынучыларны сафка бастыргач:

— Сезгә ике яңалык әйтергә телим. Аларның берсе начар, икенчесе — әйбәт. Беренчесе — безнең рота бөтен дивизия өчен әбәткә бәрәңге чистартырга тиеш. Икенчесе — бәрәңгебез, шөкер, бөтен дивизиягә җитәрлек.

Укуга тәкъдим итү

Офицер үз ротасының бер солдатына:

— Сине уку бүлекчәсенә тәкъдим итәчәкбез. Уйлавымча, бик яхшы сержант була аласың.

— Ә мин берни дә чыкмас дип уйлыйм,— ди солдат уфтанып.— Сержантларны бит йокыдан бүтәннәрдән алданрак уяталар. Ә мине өйдә еш кына «йокы чүлмәге» дип йөртә торганнар иде.

«Мин санаган уңайга атла»

Шәһәрчек буйлап хәрби бүлекчә уза. Соңгы рәттәге бер солдат рота белән бер адымга атлый алмый азаплана икән әле.

— Солдат Воробьев, әйдә, мин санаган уңайга атлап кара әле,— ди аңа командир.— Бер, ике, өч! Сул белән, сул белән!..

— Борчылмагыз, барасы җиргә мин болай да җитми калмам.

Ложкин фамилияле солдат

Старшина бөтен яңа солдатларына күз йөртеп чыга да берәвеннән сорый:

— Фамилиягез ничек?

— Рядовой Ложкин.

— Рота ашханәгә барганда әйтәм сез сафка беренче булып басасыз.

Трамвайда

Яхшы хезмәт иткәне өчен Нагнибеда фамилияле солдатка шәһәргә чыгарга рөхсәт бирелә. Ул утырып барган трамвайга юлда капитан керә.

— Рәхим итеп, утырыгыз! — ди аңа солдат урыныннан сикереп торып.

— Утыр, утыр үзең,— ди капитан һәм аның янәшәсенә баса.

Алдагы тукталышта да шул ук хәл кабатлана. Капитан, кул болгап кына, урыннан тагын баш тарта.

Тагын бер тукталыш. Солдат тагын сикереп тора һәм төз басып, кулын козырегына тидереп ала. Капитан исә ачуланадыр шикелле.

— Утыра бирегез. Мин аяк өсте барам.

Солдат кинәт кызара һәм әкрен генә итеп әйтә шунда:
— Ачулана күрмәгез, иптәш капитан, мин бит инде өч тукталышкача утырып килдем.

Йөзә белми икән

Хәрби хезмәткә алу пунктында офицер флотка китәсе бер егеткә сорау бирә:
— Йөзә беләсеңме?
— Ә ник? Мин бит корабта булачакмын.

МӘКТӘПТӘ ҺӘМ ӨЙДӘ

Мәкерле сорау

— Әти, син кеше йөзен бер күргәч яхшы хәтерләп каласыңмы?
— Үземә шулай кебек.
— Алайса, әйбәт икән, югыйсә, мин синең кырынганда карый торган көзгеңне ваттым бит...

Икесе дә телевизор карамаячак

— Дәфтәр битләрең тулы икеле дә икеле икән ләбаса, малай актыгы. Моннан соң сине телевизор янында күзем күрмәс булсын!
— Ә өйгә бирелгән эшләрнең, әтием, күбесен син эшләгәнне әйтсәм, әни сине дә телевизор караудан мәхрүм итәчәк бит.

Әтиең белән кил

— Иртәгә мәктәпкә әтиең белән бергә килегез!
— Ул килә алмас шул, апа: чөнки эш хакы аласы көне.

Тагын «икеле»...

— Тагын ике «икеле» алып кайткансың бит. Нишләп җенә утырасың соң, балакай, дәресләрдә?
— Звонок булганны көтеп.

Аяклары чыланмасынга

— Атны ни өчен дагалыйлар?
— Юлда йөргәндә аяклары чыланмасынгадыр...

* * *

— Әхәт, бер кило йон авырракмы, әллә бер кило тимерме?
— Мәгънәсез сорау. Бер кило барыбер бер кило инде ул.

Кесәсендә алма бар

Укытучы беренче класс баласыннан:
— Бишкә берне кушкач, ничә була? — дип сорый.
Малай эндәшми.
— Алайса, мин сиңа бер мисал китерәм. Әйтик, мин сиңа башта биш алма, аннары бер алма бирәм. Шуннан соң синең ничә алмаң була инде?
— Җиде.
— Ничек җиде?
— Чөнки минем кесәдә бер алма бар инде.

Врач әйтмәгән

— Врач миңа кан басымың югары диде.
— Башың әйләнәме әллә?
— Нишләптер анысын әйтмәде врач, әллә яңадан сорыйммы иртәгә?

Кадакны Госман тотып тора

— Исмәгыйль,— ди әнисе малаена,— бармагыңа чүкеч белән суга күрмә.
— Сукмам, әни, кадакны Госман тотып тора.

Директор кайда утыра

Бер апа укучыдан сорый:

— Улым, мәктәп директорын кайда очратып булыр икән?

— Аны табуы бик җиңел,— коридор буйлап дөбердәп чапсаң, каршыңа үзе үк килеп чыгар ул.

Ник яшергән

Малай әнисенә әйтә:

— Мин абыйның буяу карандашларын яшереп куйдым.

— Ник, улым?

— Син бит кичә аңа: «Чәчемне син агарттың, битемне син кызартасың»,— дидең.

Сорауга сорау белән җавап

Укытучы:

— Узган дәрестә без нәрсә турында сөйләгән идек?

Укучы:

— Апа, әллә сезнең ул дәрес планыгыз юк идеме?

Машина алырга җыя

Малай бер атна инде мәктәп ашханәсенә керми.

— Хәниф, әллә сиңа әти-әниең акча бирмиме?

— Бирәләр! Мин аны машина алырга дип җыям.

Дәфтәрен ерткан

— Апа, апа! Илсөяр сезгә мине әләкләмәкче була.

— Әләкләшү бик начар гадәт ул. Үзең әйтсәң яхшырак.

— Аның дәфтәрен мин ерттым бит.

Әтисе турында

Сүзлек өстендә эш бара. Балалар табышмак табыша. «Иелә дә бөгелә, иелә дә бөгелә, өйгә керсә сузылып ята». Нәрсә ул?

— Безнең әти! — дип тиз генә әйтеп куя Ирек.

Мин дә шулай дидем шул

— Ник тагын икеле алып кайттың, улым?
— Икене өчкә тапкырлагач күпме була дип сорады апа. Мин алты дидем. Аннары шуның артыннан ук: өчне икегә тапкырлагач күпме? — дигән сорау бирде.
— Барыбер түгелмени?! — ди шунда ук этисе.
— Мин дә шулай дигән идем шул...

Студент булып уйнау

— Әйдә студент булып уйныйк!
— Ә ничек?
— Һәркайсыбыз берничә пирожок алабыз да урамда ашыйбыз!

«Син чиш, мин булышырмын...»

— Әйдә, күрше, мин сиңа мәсьәләләр чишәргә булышыйм, аннары бергә уйнарга чыгарбыз.
— Яхшы, ләкин, тизрәк булсын өчен, мәсьәләләрне син чиш, ә мин булышыйм.

Әтисенә охшавын әйтте

— Әткәй, синең кайчандыр миңа: «Мәктәптә мин начар укыдым», дип сөйләгәнең хәтереңдәме?
— Ник исеңә төште әле бу?
— Мин нәкъ сиңа охшап туганмын икән дип әйтәсем килде.

Апасы иргә чыккач

— Кичә ник мәктәптә булмадың?
— Апам иргә чыкты.
— Ярый. Ләкин бу бүтән кабатланмасын.

Бакчачы юк чакта

— Укучылар, алманы кайчан җыялар әле?
— Әлбәттә, бакчачы киткәч,— ди алда утырган Әхмәт.

Тарихның озынаюы

— Кызым, бүген тарихтан нинди билге алдың?
— Дүртле, әнием.
— Ә минем һәрвакыт «биш»ле була иде.
— Ул вакытта тарих фәне кыскарак булган.

Аерма нәрсәдә?

— Алмаз, электр тогы белән яшен арасында нинди аерма бар?

— Электр яндырган өчен акча түләргә кирәк, ә яшен бушлай ялтырый.

Белмәвенең сәбәбе

— Әхмәт, зәңгәр кит нинди семьядан икәнен әйтеп бирерсеңме безгә?

— Әйтәлмим. Чөнки мин белгән семьяларның берсе дә кит асрамыйлар.

Башланган була

— Син гел соңга калып йөрисең, Вольфганг. Дәреснең кайчан башланганын белмисеңме әллә?

— Юк шул. Чөнки мин килгәндә ул инде гел башланган була.

Сәбәбен әйтте, имеш...

— Карале, син бит инде такта янында утыз минут чамасы торасың, ә физик законны һаман аңлата алганың юк?!

— Ашыктырмасагыз икән мине, зинһар, Фарадей үзе дә бит аны берничә ел уйлагач кына ачкан.

Агачсыз урман

— Сирәк урман турында җөмлә әйт әле.

— Без шундый бер сирәк урманга барып кердек — анда бер генә агач та юк иде.

Кулында... елан булган

— Мин урман юлыннан атлыйм. Кинәт елан күренә.

— Аннары ни булды?

— Якынрак килеп карасам, ул таяк булып чыкты. Ләкин аны алгач котым чыгып курыктым.

— Нәрсәдән?

— Чөнки кулыма тоткан таяк елан иде.

Бөтен сәбәпләр дә әйтелгәч...

Дүрт малай мәктәпкә вакытында килмиләр.

— Син ник соңгардың, Курт? — дип сорый укытучы.

— Әнием чирләде, аптекага дару алырга бардым.

— Ә син, Франц?

— Безнең сәгатебез туктаган булган.

— Ә синең сәбәбең нинди, Карл?

— Башым авыртты.

Вальтер исемле малай исә җилкәсен генә җыера:

— Ник соңга калуымны белмим дә инде мин. Чөнки бөтенесен әйтеп бетерделәр.

Алма төшкәнне көтә

Дәрестә Ньютон законын аңлата алмаган һәм аны иртәгә белеп килергә тиеш укучысын бер укытучы урамда күргәч аптырап кала: ул алмагач төбендә дәшмитынмый утыра.

— Нишлисең син биредә?

— Башыма алма төшкәнен көтәм.

Уртачасын куегыз

— Белмим дә инде, бу чирек өчен сиңа нинди билге куяргадыр. Журналда синең ике икелең һәм ике өчлең бар.

— Ә сез шуларның дүртесен кушыгыз да уртачасын чыгарыгыз!

«Куймаса әни тирги...»

— Томми, әйт әле: ни өчен этиең синең көз җитүгә тәрәзәгә икенче кат рамнар куя?

— Әгәр куймаса, аны бит әни тирги.

Үз хатасы да җитәрлек

— Зинһар, азаплама инде баланы, әткәсе, дәресен хәзерләшәм дигән булып. Үзе ясаган хата да җитәрлек ич.

Чеметеп елаткан өчен

— Бу әфлисунның яртысын син миңа бирергә тиешсең,— ди малай үзенең сеңелесенә.

— Ә ни өчен?
— Әгәр мин чеметеп елатмаган булсам, энидән сиңа бу җимеш тәтеми иде.

Үзләре әйтер әле

— Кая болай бик ашыгасың әле син?
— Сынау тапшырырга.
— Нәрсәдән?
— Анда үзләре әйтерләр әле.

Сабын табалмаган

— Әллә кайда да булса көньякта булдыгызмы? Битең-башың бик шәп каралган.
— Юк. Иртән юынганда сабын табылмады.

Яхшылык эшләү турында

— Бер малай белән таныштым, әни. Миңа яхшылык кына эшләсәң иде син, ди.
— Ә нинди яхшылык икәнен әйттеме?
— Математика биремнәрен минем эшләвемне үтенә.

Искиткеч малай

— Менә, әни, мин бер классташымны алып кердем әле безгә. Искиткеч малай ул!
— Нәрсәсе искиткеч соң аның?
— Миннән дә начаррак укый!

«Кайсын әйтим соң...»

— Африкадагы бер елганың исемен әйтеп бир әле.
— Тәгаен кайсын әйтергә соң?

Анда да бала тапырга кирәк бит

— Ни өчен ләкләкләр кышка җылы якларга очып китәләр?
— Чөнки андагы кешеләр дә бит үзләренең балалары булуын тели.

Инде әзер...

— Син имтиханнарга хәзерләнәсеңме инде?
— Әлбәттә! Инде уникe шпаргалка эшләдем.

«Берсе дә исән түгел...»

— Унҗиденче гасырда яшәгән һәм иҗат иткән атаклы химиклар турында нәрсә әйтә аласың?

— Әйе. Аларның хәзер берсе дә исән түгел инде.

Сигаретен тартып алганнар

— Ник елыйсың, шәрик? Әллә икеле эләктеме?

— Ю-у-ук... Унынчы класстан бер малай сигаретымны тартып алды...

Нәкъ безнеңчә

— «Коену» немецча ничек була?

— Нәкъ безнеңчә үк — чишенәсең дә суга чумасың.

Куркусыз ата улы

— Әти, син сугышта булдыңмы?

— Әйе.

— Димәк, бер нәрсәдән дә курыкмыйсың? Алайса, мә, минем көндәлекне карап кул куй әле!

Икесе дә яхшымы

— Син бик яхшы инша язгансың, ләкин ул нигәдер нәкъ Маркныкы кебек үк. Нәрсә уйларга тиешмен икән мин хәзер?

— Ник? Маркның да иншасы яхшымы әллә?

Әтисе дә зур түгел әле...

— Әти, синең кебек зур үскәч мин дә, әнидән рөхсәт сорамыйча теләсә кая барып, өйгә теләсә кайчан кайта аламмы?

— И, балакаем, мин әле үзем дә ул хәтле зур түгелмен.

Бүтән болай эшләмәм

— Ник дәрескә соңгардың?

— Башыңны, муеныңны, колакларыңны юмыйча бер кая да бармыйсың диде әни. Гафу итегез, бүтән болай эшләмәм.

«Өйдә булмыйм...»

— Әниең сиңа бик еш ачуланамы?
— Әлбәттә.
— Моны син ничек беләсең?
— Ачуланыр алдынан ул унга чаклы саный башлый.
— Ә аннары?
— Анысын белмим: чөнки мин инде өйдән чыгып киткән булам.

«Акбур табалмыйм...»

Өченче класс укучысы өйгә арифметикадан бирелгән эшне башкарганны әтисе күзәтә.
— Син күзеңне йом да,— дип киңәш итә ул,— каршымда минем класс тактасы ич әнә дип уйла! Булдымы?
— Әйе.
— Хәзер шул тактага үз мисалыңны яз. Булдымы?
— Юк әле... Чөнки акбур табалмыйм.

Каян беләсең

— Кичә нишләдең син, Фәрит?
— Форель тотарга бардым.
— Күп эләктеме соң?
— Берне дә тоталмадым.
— Алайса, аның форель икәнен каян беләсең?

Тараклары юк

— Ник син мәктәпкә көн дә тузган баш белән киләсең? Чәч таравы авырмыни?
— Тарагым юк.
— Әтиеңнеке бардыр ич?
— Юк шул.
— Ник?
— Чөнки ул такыр башлы.

Үзе дә белми

— Нишләп син мәктәптә гел икеле дә өчле билгеләре генә алып кайтасың?
— Үзем дә белмим. Бәлки яхшы билгеләрне кая да булса читкә җибәрәләрдер...

Кайсы программа күрсәтәчәк

— Балалар, бүген ай тотылачак, сезгә аны карарга кирәк.

— Кайсы программа күрсәтә?

Тәмәке тартмаса

Улының тәмәке белән шаярганын белеп алган бер ана аңа:

— Тәмәке тартсаң зур үсә алмассың әле менә! — дип яный.

— Ә ник энә бабай алтмыш яшькә җитте инде. Ул да бит тәмәке тарта.

— Тәмәке тартмаса күптән инде җитмештә булыр иде.

Көнче апа

— Эти, безнең укытучы апа бик көнче икән.

— Каян беләсең?

— Мине берничә тапкыр инде класстан куып чыгарганда, их, әгәр атаң булсам, бирер идем синең кирәгеңне, диде.

Яраткан бер сүз

— Укучылар нинди сүзне күбрәк әйтә?

— Белмим.

— Дөрес.

Китаптан карап

— Улым, термометрны кара әле, бүген ничә градус?

— Ундүрт.

— Ә кояшта?

— Хәзер китаптан карыйм... Алты мең чамасы, дигән, эни.

Кызганыч

— Людовик XIV нең грек короле булмавы бик кызганыч бит әле...

— Ник?

— Чөнки мин кичә аны грекныкы дип инша яздым...

Күплек санда

— «Музыкант» сүзе күплек санда ничек була?
— Оркестр.

Ком кермәсен өчен

— Чүлдә кешеләр ни өчен дөягә атланып йөриләр?
— Аяк киемнәренә ком кермәсен өчен.

Ә дүрт аяклап йөрдеме

— Нәкъ атаңа охшап үсәсең син дә, юньсез,— дип тирги бер әби үз оныгын.— Ул да шулай баштүбән диярлек йөреп азына торган иде балачакта.
— Ә дүрт аяклап йөрергә ул кайчан өйрәнде, әби?

Анда башлык тора

— Нишләп сезнең йортта лифт гел эшли?
— Чөнки уникенче катта йортлар идарәсе башлыгы тора.

Җәнлеген мактый

— Синең нинди дә булса җәнлегең бармы?
— Бар. Бәләкәй бер тычкан асрыйм. Бәясе егерме ике сум унбиш тиенлек.
— Күр син аны, нинди төгәллек! Ә бәләкәй тычкан шул бәя торганны каян беләсең?
— Чөнки мин аның өчен велосипедымны бирдем.

Әтисен куркытырга...

— Көндәлегең кая, Петик?
— Мин аны, әти, Карелга бирдем.
— Ник?
— Шуны күрсәтеп ул да әтисен куркытырга тели.

Куанычлы белдерү

Беренче класска беренче тапкыр барган кызчык мәктәптән кайтып керүгә кычкырып белдерә икән:
— Бүген, әбекәй, синә бишле, ә бабайга — дүртле.

Мәктәпкә чакыру

— Әнкәем дим, әнием! Мәктәпкә бер генә тапкыр булса да ичмаса син барсаң иде, юкса классташларым «атасыз бала» дип йөри башладылар инде?!

Сәбәбен тапканнар

— Петя, ник соңга калып килдең дәрескә?
— Әти белән балыкка барырга теләгән идем... Ә ул мине ияртмәде.
— Әтиең бик дөрес эшләгән.
— Селәүчәннәрем бик аз, икебезгә җитмәс дип кенә алмады бит ул мине.

Сораугa сорау

— Исем алмашлыгына ике мисал китер әле, Нәби.
— Кем? Минме?

Сәгатькә карамый киткән

— Бәй, нишләп мәктәптән бик иртә кайттың әле бүген?
— Ә мин, әни, сәгатькә карарга онытканмын.

Булмаган җирдә булачак

Гаиләдә җәен кемнең кайда ял итәргә теләве турында сүз бара.
— Мин инде күптән үзем булмаган бер тарафка китәр идем,— ди малай.
— Бик яхшы! — ди әтисе һәм аңа парикмахерская-га барып чәчен кыркытырга бер сум акча тоттыра.

Тәнәфесләре күңелле

— Улым, ничек, яңа мәктәп ошадымы?
— Бик ошый, әни.
— Ә нәрсәсе күбрәк ошый?
— Тәнәфесләрендә бик күңелле була!

Тотылды

Укытучы:
— Марат, ник дәресеңне әзерләмәдең?
— Ут юк иде.

— Телевизор карадыңмы соң?

— Әйе, караңгыда карадым, мультфильм күрсәттеләр.

Тавык-чебеш түгел, имеш...

— Өченче этәчләр кычкырды бит инде, тор, улым. Мәктәбеңә җыенасың бар.

— Бутама әле, әни, мин тавык-чебеш түгел бит, кешемен.

Ник йөрми?

— Әти, пианиноның да тәгәрмәчләре бар бит, ник үзе йөрми ул?

— Күрәсеңдер бит, уйнаганда пианист аның тормозына бертуктаусыз басып тора.

Базардан кайткач

Малай әтисе белән бергә Яңа ел алды базарыннан кайта: аның кулында синтетик чыршы, атасы исә аркасына зур капчык аскан. Әниләре аларга киң итеп ишек ача. Беренче сүзне малай башлый һәм:

— Менә, әнкәй, чыршы, ә аңа запчастьлар әти капчыгында,— дип белдерә.

* * *

Көндәлегендә берьюлы биш «икеле» күргәч, малаен җәзаламакчы икән бер ата: сул култыгы астына аның үзен кыстырган, уң кулында каеш... Күрәсең, почмакка да куймакчыдыр инде — шул килеш ишек тарафларына атлый.

Ә кулына биш «икеле» белән кызартылган ике бите ачык көндәлек тоткан малай:

— Әтием, эткәем, бу бит минеке түгел, шкаф артыннан синең иске көндәлекне тапкан идем,— дип кычкыра икән.

Ник туктатмыйлар

Мәктәп баласы театрда:

— Әтием! Әнә теге бәләкәй будкадагы берәү сәхнәдәгеләргә берөзлексез пышылдап нәрсәдер әйтеп тора. Нигә аны беркем дә кисәтми һәм туктатмый икән?

«Бик якын килмә...»

— Әни, кояш тотылганны карарга чыгыйм әле мин дә?
— Бар, ләкин аңа бик якын килә күрмә! Ерактан гына күзәт.

«Әниеңнән сора»

— Әти, Альп тавы кая ул?
— Әниеңнән сора, чөнки өйдә һәрнәрсәне урыннан-урынга ул күчерә бит.

«Чыркылдауларын яхшырак тыңла»

Тәрәзәләренең урам як төбенә кунган ике чыпчыкны күргәч сорый бер малай:
— Әти, шул ике кошчыкның кайсы ир, кайсы хатын икән?
— Син аларны күбрәк тыңлап тор, черелдәүдән кайсы иң соңыннан туктаса, хатыны шул булыр.

Сөт турында

— Сөт турында синең инша нибары ун юллы гына, ә бүтән балалар икешәр бит язганнар...
— Шулайдыр, чөнки мин консерв итеп куертылган сөт турында яздым.

Ата зары

Бер ата үз улыннан зарланып якын дустына сөйли:
— Бик нык үзгәрде. Инде тәмам түзәлмәс булдык. Бары тик ниндидер идиотлар сүзен генә тыңлый. Зинһар, шуның белән гәпләшеп кара әле син!

«Әйдә, шуны бел әле...»

Бер малай сабакташы өенә бара һәм алар ишеге төбендә бик дәү бульдог эт күреп курка кала.
— Кер! — дип кычкыра аңа сабакташы коридордан.
— Ә бу эт тешләмиме соң?
— Моны белү безнең үзебезгә дә бик кирәк әле. Чөнки без аны бүген генә сатып алдык!

Сәбәбен әйтте

— Мәлик, дәрескә ник соңардың?
— Ун тиен акча табуым сәбәпле.
— Тапсаң соң, алалар да кесәңә салалар аны тиз генә.
— Мин бит аны бик озак эзләдем дә әле...

Бик тә шәп булды

— Абый, машинаңа утыртып мине мәктәпкә чаклы алып бар әле?!
— Мин бөтенләй икенче якка юл тотам бит.
— Бик тә шәп, чөнки мин бүген дәресләремне хәзерләмичә бара идем.

Бишек җыры тыңлап

— Җыр дәресендә йоклап утырды диде укытучың, дөресме бу?
— Бөтен класс бишек җыры көйләгәндә ничек йокламый түзәргә иде миңа, әни!

Аптырап калмады

— Дәфтәр битеңнең кыры кайда? — дип сорый укытучы.
Ә укучы әйтә:
— Кыр бит ул шәһәр читендә була.

«Әти-әниләр моны аңламый»

— Шуны белегез, балалар,— ди укытучы,— сез минем өчен һәм яхшы билгеләр алыр өчен укымыйсыз.
Класстан шул чакны бер тавыш ишетелә:
— Кызганычка каршы, безнең әти-әниләр моны аңламыйлар шул.

Сер ачылмый калмады

«Без кичә сарык суйганны беркемгә дә әйтәсе булма», диләр малайга өйдә. Менә ул бүген күршеләренә керде. Сүз арты сүз чыгып, сорашулар башлана.
— Сарыгыгызның мае күп чыктымы?
— Белмим,— ди малай.
— Ә ите күпме булды?
— Белмим.

— Тиресе бармы соң?

— Бар. Лэкин эти аны нигэдер, «бик юка тире», диде...

Яшерелгэн билге

— Сез, эби, бу балага нигэ тэре тагасыз? Кеше көлэчэк бит...

— Ә без аны, абзыкаем, шэп кенэ итеп галстук астына яшерэбез.

Этисе булышкан...

— Дэреслэреңне эзерлэшергэ этиең булыштымы эллэ сиңа?

— Әлбэттэ. Мин яздым, э ул кулына каеш тотып минем янда басып торды.

Кармакка элэккэнчедер...

— Эти, балык күпме яши икэнен белэсеңме?

— Берэр балыкчы кармагына яки җэтмэгэ элэккэнче яшидер дип белэм.

Этисенеке түгел, апасыныкы

— Бэп-бэлэкэй башың белэн сигарет капкансың түгелме соң? Атаңныкын алдыңмы?

— Юк, апамныкын.

Үзенчэ җэзалаган

Этисе югында Янис аның челемен һэм тэмэкесен алып үзе дэ тартып карамакчы була. Лэкин кинэт кайтып кергэн ата моны күрэ. Бераздан бала елап энисе янына керэ.

— Ни булды?

— Челем кабып караган идем, эти тотты. Лэкин — кул да тидермэде үземэ. Челемдэге бөтен тэмэкене генэ үземнэн тарттырып бетерде.

Кызгану хисе

— Мэктэптэ тарих укытучысы һаман безнең малайга бэйлэнэ икэн, этисе.

— Нэрсэ дип?

— Бары тик ул туганчы гына булган нэрсэлэрне сорап аптырата, ди.

Берсе зур, берсе кечкенә бит

— Ник син «Петро» сүзен баш хәреф белән яздың да, ә җөмлә башындагы «каләм»не кечкенә белән генә?

— Чөнки Петро буйга зур, ә каләм бит ул кеп-кечкенә бер нәрсә.

Яхшы буласы килә

— Син ул Сашка белән аралашма, улым! Чөнки ул бик начар малай бит.

— Әнекәем,— дип әйтә улы аңа бик тыныч кына,— мин аның белән аралашмыйм, Сашка үзе минем белән дус булырга тырыша: чөнки аның да яхшы буласы килә.

Сорауга каршы сорау

— Әгәр бер сыер көненә алтышар литр сөт бирсә, атналык савым күпме булачак?

— Ә савымчы бер атнада ничә көн эшли?

Төймәсез пальто

Балалар чишенә торган бүлмәдә ут сүнә.

— Хәзер үз пальтоңны ничек танырсың инде? — дип сорый бер укучы үзенең классташыннан.

— Төймәләреннән таныймын.

— Кызык! Ә нинди соң алар?

— Минем пальто төймәсез.

Күрше абый күбрәк бирә

— Балакаем, әгәр бу көйне көн саен уйнасаң, мин сиңа көн саен егерме тиен акча бирәм.

— Кирәкми, энкәй. Чөнки әгәр дә уйнамасам, күрше абый миңа көненә кырык тиен бирәчәген әйтте.

«Уртак» дәфтәр

— Ник син минем дәфтәр битемне ертып алдың?

— Чөнки бит аның тышына «Общая тетрадь» дип язылган.

«Курыкмавымны күр...»

— Ирек, син караңгыдан куркасыңмы?

— Юк.

— Алайса бар, әнә теге бүлмәдән тупны алып чык әле.

— Әйдә бергәләп керик! Минем курыкмаганымны үз күзең белән күрерсең.

* * *

— Кеше су ярдәмендә яктылыкны ничек булдыра?

— Тәрәзәне чиста юып.

Ник кычкыра?

— Әни, миңа бераз акча бир әле.

— Нәрсәгә ул сиңа?

— Урам чатында кычкырып торган бер кешегә бирәсем килә.

— Ә ник кычкыра соң ул?

— Мороженое сатам дип.

Кәвеш... сумкада

— Минем кәвешне алмадыңмы син, балам?

— Юк.

— Кая китте икән соң ул?

— Минем сумкада ята, әни.

Язуын үзе яза

Әнисе малайның өйгә бирелгән дәресен эшләшеп утыра. «Үзе башкарсын!» — ди атасы. Ә малай әйтә:

— Әни бит миңа бары тик әйтеп кенә утыра, ә язуын үзем язам.

* * *

— Әче туфрак нидән була?

— Җирдә кузгалак үскәнгә.

Ярты гына көн

— Әнием, әгәр мин дүртле билге алсам, син мине паркта йөрергә көн буена җибәрәм дигән идең.

— Әйе, улым.

— Димәк, мин бүген паркка ярты көнгә генә барам.

Су астында кем сөйләшә ала соң

— Балыклар ни өчен телсез булалар?
— Моның бернинди гаҗәбе юк! Син үзең, мәсәлән, су астында сөйләшә алыр идеңме?

Селедка күпкә күрә

— Диңгез суы нидән тозлыдыр дип уйлыйсың?
— Чөнки анда селедка күп була!

Санады...

— Сөтле булган биш нәрсәне санап чык әле!
— Май. Эремчек... һәм... һәм... өч сыер.

Сабынлап юылачак китап

— Бөтен китабыңны карага буягансың бит, балакай, нишләвең бу?
— Аптырама, әнием, аны бит син сабынлап юмаячаксың.

* * *

— Мин аңлатканнардан чыгып, балалар, инде хәзер тереклек ияләренең тышкы мохит шартларына ничек ярашулары турында мисаллар китерегез.
— Мин китерәм,— ди Пиштике.— Безнең тавык, мәсәлән, йомырка гына сыешлы ояларга бүлгәләнгән савытыбызга сыярлык кына зурлыкта йомырка сала.

Бик үк шәп түгел

— Я, улым, шәп җырладыларммы концертта артистлар?
— Бик үк шәп түгел. Берничәсен сәхнәгә чыгарып башта җырлаганын яңадан кабатлаттылар.

Ә китапларны кая куярга

— Менә мин сиңа күн букча алдым, улым! Кара аны: шуңа тутырып гел бишлеләр генә алып кайта торган бул.
— Ә китапларны кая йөртергә кала аннары?

Берьюлы тыңлый алмый

Балалар, нindидер кызык бер яңалык әйтергә дип, этиләре янына йөгереп киләләр.

— Кычкырынмагыз әле бу хәтле! Башта берегез сөйләсен, чөнки икегезне берьюлы тыңлап булмый ич.

— Әллә синең, эти, бер колагың начар ишетәме?

Рәхмәт, әни

— Улым, син кат-кат тукыганны да тыңламыйсың бит. Әнкәң сүзләре бер колагыңнан керә дә икенчесеннән чыга тора.

— Рәхмәт, әнием! Бер кешегә ике колак нигә кирәген бик яхшы аңлаттың.

Ярты билет кына сорый

— Ку кинога билет күпме тора?

— Утыз тиен.

— Минем акчам унбиш тиен генә, ярты билет сатыгыз, бер күзем белән генә карармын.

Әле ашамаган икән

— Тулы бер җөмләне инглизчә әйт: мәсәлән, бүген иртән син нәрсә ашадың? — ди укытучы.

— Ә мин, апа, бүген бернәрсә дә ашамадым әле...

Охшашлыкка мисал

— Искиткеч охшашлыкның яки туры килүнең кем нинди мисалын китерә ала!

— Мин,— дип кул күтәрә Мишка һәм әйтә: — Этиемнең дә, әниемнең дә туе бер үк көнне булган.

Үзен йоклаганда күрәсе килә

— Нишләп күзеңне йомып көзгегә шулай бик озак карап торасың?

— Йоклаганда үземнең нинди икәнемне күрәсем килә.

Бара алмый

— Әйдә, кино карарга киттек!

— Юк, бармыйм, чөнки этиемә минем дәресләрне әзерләшәсем бар.

Исеннән чыккан

— Мин һаш хлор дип яздым. Нинди формула була ул?
— М-м, менә тел очында гына үзе, ә истән чыккан.
— Алайса төкер син аны тизрәк, чөнки тоз эчелеге ул.

КЫСКА ЫШТАНЛЫ ЮМОР

(Күпбелмеш китабыннан) *

Нәрсә кирәкми?

Балага тиздән өч яшь тула. Көннәрдән бер көнне әтисе белән урамда йөрергә чыккач ул күккә карый да:
— Ай-һай зур йолдыз!
Әтисе аңа бүтән нәрсәне аңлатмакчы:
— Йолдыз түгел ул, безнең җир шары кебек үк зур планета. Бәлки, анда кемнәр дә булса яшиләрдер дә әле.
— Җитте, әтием, кирәкми! — ди бала.
— Нәрсә кирәкми?
— Әкият сөйләвең.

Пенсиягә чыгу турында

— Безнең тәрбиячебез инде пенсиягә китте,— ди бакча баласы.
— Димәк, ул хәзер сезнең белән урамда йөрергә эштән соң гына чыга ала? — дип сорый күрше малае.

---

* Бу китапны төзүче һәм тәрҗемә итүченең үз иҗатыннан үрнәкләрдә нәниләр сөйләме Күпбелмеш исемле бала исеменнән әйтелә.

Әбисе бәйләнмәсен өчен

Зоопаркта «җәнлекләрне ашату катгый тыела» дигән язуны укыгач Күпбелмеш:

— Әти, әйдә миңа да шундый язу язып так әле? — ди икән.

— Ниемә ул сиңа?

— Ашамыйсың дип әби бәйләнмәсен өчен.

«Көндез килми ул»

— Тизрәк менеп ят караватыңа, улым, юкса төлке килеп алыр үзеңне...

— Көндез килми ул.

— Ник килмәсен ди?

— Чөнки аңардан тун тегәселәрен белә,— ди Күпбелмеш.

Моторы кызып җитмәгән

Бала атланган ат урыныннан кузгалмый да кузгалмый.

— Ник китмисең инде?

— Чөнки мотор кызып җитмәде әле.

Арсланнар башы күргәч

Инде шактый борынгы бер бина ишегенең як-ягында таштан эшләп куелган арсланнар башын күргән бала сорый:

— Ә койрыклары аларның, әни, эчтәге фатирларындамы?

«Ник бинтлыйсыз?»

Күршеләрендәге бер апа бала биләүсәләгәнне күргәч сорый икән бер бәләкәч:

— Сез аны ник шулай бинтлыйсыз?

Күзлексез укый алмау

Әле өч кенә яшендәге оныгына бераз укыгач, әбисе, арыдым дип, китапны читкә куя:

— Калганын иртәгә укып бетерербез.

«Бир, үзем укыйм әле...» дип алган китапны онык, әлбәттә, укый алмый.

— Син, әби, хәйләлисең! Үзең күзлек белән укыдың, ә миңа аны кидермисең. Бир, киим әле!

Витаминын күрмәгән

— Кишер аша, балам, аңарда витаминнар күп.
— Әллә күпме ашадым инде. Ә бер генә витамин да күргәнем юк әле.

Борыны ачулангач

— Әни, минем борыным нигәдер ачуланды. Хәзер төчкерә башлаячак...

Ул да дөресен әйтә

— Чамасыз арылды бүген эштә! — дип зарлана әтисе,— хәтта кул да кыймылдата алмыйм.
— Чынлапмы, әтием,— дип каршылый аны Күпбелмеш.— Алайса мин дә дөресен әйтим инде сиңа: — Вазаны мин ваттым...

Баштүбән карый белергә кирәк

— Әби, нишләвең бу? Син бер бөҗәкне таптадың ич!
— Гафу ит, бәләкәчем. Мин аны ничектер күрмәгәнмен.
— Күрмәгәнмен! Йөргәндә баштүбән карый белергә кирәк.

Егылмабыз, әби

Әбисе онычын күтәреп икенче катка менә.
— Егылмабыз микән, балакаем?
— Ю-у-к! Мин сине муеныңнан тотып менәм бит.

Мөгезсез сөзгәк булмый

Әбисе белән болыннан узышлый бер бозау күрәләр.
— Безне сөзмәсме икән ул? — дип юри сорый әбисе.
— Аның мөгезләре юк ич. Әллә колагы белән сөзсенме? — ди Күпбелмеш.

Үзе ватылды

— Улым, чәйнекне син төшереп ваттыңмы?
— Ю-у-ук... Ватылганын күрдем генә. Мин эскәтерне тартмакчы идем, ә чәйнек, куркыптыр ахры, идәнгә төшәргә булды һәм шунда ватылды.

Үз өйләре янында гына офицер

Күпбелмеш әтисе белән бакчада йөрергә чыга.

— Әйдә, улым, мин офицер булам, ә син солдат. Солдат күп нәрсәне булдыра, ә офицер бөтенесен белә. Шуңа күрә солдат офицерны тыңларга тиеш...

Менә офицер адашкан булып кылана.

— Инде нишләргә хәзер безгә? Кая барыйк икән?

— Әллә син, әти, үз өебез янында гына офицермы?

Тыныч булганы өчен

Күпбелмеш бакчада тагын «бишле» билгесе ала.

— Молодец, улым! Ә нәрсә өчен соң?

— Тыныч булганым өчен.

«Оят түгел, кытыгым гына килә»

— Син бит инде дәүсең. Ә колготкаңны әниең салдыра. Оят түгелме?

— Оят түгел, бары кытыгым гына килә.

Теш чистартасы юк

— Әби, сезгә рәхәт ичмасам: тешләрегез төшеп бетә язган инде.

— Нәрсәсе яхшы моның?

— Беркем дә теш чистартырга кушып аптыратмый...

Зоопарк булып уйнау

— Әйдә зоопарк булып уйныйк,— ди Күпбелмеш бер бәләкәчкә.

— Әйдә... Ә ничек ул?

— Мин маймыл булам, син мине чикләвек белән сыйла.

Җитәрлек кенә салыгыз

Күпбелмешне кунакта ашарга утырталар.

— Апай, бик күп саласыз, минем аңа әпититем җитәрме икән?!

Шофер булырга теләү

— Үскәч кем булырга телисең, улым?

— Шофер.

— Ни өчен, мәсәлән, очучы түгел?
— Күктә бит мин аңардан уза алыр кеше юк.

Антеннасыз җырлый гынамы?

— Әти, радиога ни өчен антенна кирәк?
— Сөйләсен өчен.
— Ә антеннасыз ул җырлый гынамы?

Бала булып эшли

Бер бабай ботинка шнурларын ничек җитте шулай бәйләп маташкан нәнидән сорый:
— Кая ашыгасың болай?
— Эшкә.
— Синме?
— Әйе, мин дә.
— Ә кая эшлисең соң син?
— Бакчада. Бала булып.

Күзлеген салмаган кунакка киңәш

Күршеләреннән кемдер берсе кереп пальтосын, бүреген салгач һәм шарфын чишкәч Күпбелмеш әйтә икән:
— Күзлегегезне дә салыгыз, безнең өй бик җылы бит.

Ләкләген күрсәтсәң иде...

— Кызым, ләкләк китергән энеңне күрәсең киләме?
— Энемне түгел, ләкләген күрсәтсәң иде миңа?

Бабасының күңеле булсын өчен

— Ник болай үкерәсең, бала?
— Бабам колагымны борды. Ләкин авырттыра алмады.
— Алайса ник тавышлыйсың бу хәтле?
— Бабамның күңеле булсын өчен...

Яхшы очрашу

— Әти, син кайда тудың?
— Төкедә.
— Ә син, әни?
— Белоруссиядә.
— Ә мин кайда тудым?

— Казанда.

— Безнең шулай очрашуыбыз бик тә яхшы булган бит, әйеме?

Шакмаклардан... сыер

Төсле-төсле шакмакларга язылган хәрефләрне кушып, Күпбелмеш сүзләр җыя. Әбисе аңа «М» белән «У»ны янәшә куйдыра да:

— Я, нәрсә булды? — дип сорый.

— Сыер! — ди бәләкәч.

«Түр бүлмәгә чакырмыйм»

Күпбелмешне өйдә Кыш бабайны ничек каршыларга кирәген өйрәтәләр.

— Зур сакаллы, өстенә тун, аягына киез итек кигән булыр. Килеп керүгә, син аны түр бүлмәбезгә чакырырсың.

— Чакырмыйм. Итектән булса ул безнең паласыбызны пычрата ич!

Белде

Урамнан йөгереп керә дә Күпбелмеш:

— Әби, минем алма ашыйсым бик килә,— дип үтенә.

— Әнә, ал шкафтан. Ләкин башта кулыңны сабынлап ю, микроблары булмасын.

— Ә нәрсә соң ул микроб?

— Алар, балакаем, күзгә күренми торган бәп-бәләкәй җан ияләре.

— Кулны югач күренмәячәкләрме?

— Сабынлап юган кулда алар төрле якка качып бетәчәкләр.

— Белдем, белдем! Сабын күбеге аларның күзләренә кергәнгә ул.

Тузан суыргыч белән...

Әнисе өй җиһазларының тузанын сөрткәндә ачып куйган тәрәзәдән бүлмәгә бал корты очып керә. Ана аны кулындагы чүпрәкне болгап куып чыгармакчы.

Күпбелмеш әйтә:

— Әни, аны тузан суыргыч белән тотып булмыймы?

Әни урынына этисе калгач

Кибеткә чыгып киткәндә әнисе бәләкәй улын этисе карамагында калдыра.

— Әни, минем белән уйна әле? — ди бераздан Күпбелмеш.

— Син кем белән сөйләшәсең? Мин сиңа эти кеше ләбаса.

— Соң бит хәзер син әни урынына калдырылдың.

Серле һәм сәер үтенеч

Әбисе әйтә:

— Бәбкәм, әгәр әбиеңне яратсаң, хәзер үк уенчыкларыңны тиз генә җыеп куй!

Күпбелмеш исә бабасы белән сөйләшә башлый:

— Әбине бик яратасыңмы син, бабакай?

— Яратам шул.

— Алайса минем уенчыкларны тиз генә җыеп куеш әле.

Әрчемәгән бәрәңге биргәч

— Улым, ник ашамыйсың? Урамнан кергәндә бүредәй ачыктым дигән идең бит...

— Ә синең, әни, бүренең әрчемәгән бәрәңге ашаганын күргәнең бармы?

Мороженое сатучы була

— Абыкаем, син минем кем булуымны теләр идең?

— Мороженое кибетендә сату итәргә теләгең бик зур икәнен беләм.

Кычыткан өрә беләме?

— Бабай, кычыткан тешлиме ул?

— Ничек кенә тешли әле!

— Ә өрә беләме соң?

Кем челтәрләткән?

— Әни, син якаңа нинди бант тактың?

— Юк, бу бант түгел, кызым, ә шундый челтәр.

— Ә кем челтәрләгән соң аны?

Фотода күренми ич ул

— Кая барабыз, әни?
— Фотога төшәргә, кызым.
— Ә нигә духи сөртәсең? Фотода ул барыбер күренми ич.

Онытып калдырылган тәпиләр

Кар өстендә кош эзләрен күргәч:
— Кара әле, кошлар тәпиләрен онытып калдырганнар,— ди бала.

Ник үзләре ашый-эчә белми?

— Әни, нишлисең син?
— Ашарга әзерлим. Синең туган көнеңдә кунаклар килер, аларны ашатырга-эчертергә кирәк бит.
— Син ашатасыңмыни аларны? Үзләре ашый да, эчә дә белмиләрмени?

Башы гына йөзә...

— Әни, кара әле, әнә теге абый бата бит.
— Юк, йөзә генә ул.
— Түгел шул, батып бетә язды инде... Башы гына йөзә.

Бензин беткәч

Велосипедта тауга күтәрелгәндә туктап калгач:
— Нәрсә, әллә көчең беттеме?
— Юк, көч җитә. Бензин бетте менә...

Күзлеген салган елан

Рәсем дәфтәрен ике бала карап утыралар.
— Менә монысы — күзлекле елан?
— Каян беләсең? Күзлеге күренми бит.
— Ә ул аны салган,— ди берсе.

Ашап бетерүе кызганыч

— Әллә ботка тәмле түгелме, балам?
— Нишләп алай булсын ди! Шул хәтле тәмле — хәтта аны ашап бетерүе дә кызганыч.

Ял итә

— Елап бетердеңмы инде?
— Юк, бераз ял итәм әле.

Көн саен шулай булсын

— Менә, балам, сине инде йокларга да яткырам. Бүген үзеңә бернинди дә шелтә-фәлән ясамадым.
— Рәхмәт, әни, көн саен шулай булсын бу!

Әгәр, әгәр...

— Ник синең кече энең шул хәтле каты кычкырып елый?
— Ничек кычкырмасын ди ул? Әгәр чәчегез һәм тешегез булмаса, әгәр аягыгызда басып торалмасагыз һәм әгәр кулларыгыз әйбер тотмаса, сез аңардан да катырак кычкырыр идегез әле.

ЧӘНЕЧКЕЛӘРДӘН МУЕНСА

Куркытырга ярамый

Нәни балалары йокыга китми интектерә. Әнкәсе иреннән сорый шул чакны:
— Тәмам туйдым бу азаптан... Әллә берәр җыр җырлап карыйммы икән?
— Алай куркытырга ярамас. Син аны яхшырак юатып кара.

Файдалы үрнәк

Яңа гына әзерләнгән тортны кабып карый да хатынына әйтә бер ир:

— Гөлгенә, шундый пешекчелек тәҗрибәңне кая да булса уртаклашсаң яки матбугатта язып чыксаң икән. Бу метод бит цемент промышленностенда яңалык ясый алачак.

Акчасы аз

— Хатынның туган көненә бүләккә нәрсә алыйм икән?
— Ә син башта аның үзе белән сөйләш.
— Шул да булдымы киңәш! Ә андый акчаны мин каян алырга тиешмен аннары?

Урынсыз хыял

Бер абзый китап кибетендә: «Хатын-кыз — ирнең идарәчесе ул» дигән китап бармы? — дип сорый һәм:
— Хыялый әсәрләр күрше залда сатыла,— дигән җавап ишетә.

Куандырмас өчен

Ир белән хатын сөйләшә:
— Шул Шиһапларга барырга теләгем һич кенә югын белсәң иде син, әтисе!
— Мин үзем дә шулай. Ләкин бит без килмәсәк бик куаначаклар алар.
— Син хаклы. Әйдә киттек.

Күп сөйләүчегә

— Яшь чагымда мин стенографистка булып эшләдем. Дөресме, әтисе! — дип сөйли хуҗабикә табынга җыелган кунакларга.
— Әйе, кадерлем! — дип куәтли аны ире.— Син хәзер минутына ике йөзгә чаклы сүз сибеп сөйлисең бит әнә.

Касәсе юылмагандыр?

— Официант, бу шәрабны кире алыгыз! Чамасыз болганчык ул.
— Алай түгел. Бездә шәраб болганчык булалмый. Бәлки касәсе юылмагандыр?

Кызыгыз укытучымы әллә?

— Сезгә ничә яшь, ханым?

— Үзегез чамалап карагыз эле. Минем кызым мәктәпкә йөри.

— Ул укытучымы әллә?

Чукрак та, телсез дә

Зоомагазинда бер ханым сатучыдан:

— Нигә бу тутый кош шулай кыйммәт! — дип сорый.

— Алыгыз аны. Бернинди дә кыен хәлгә калдырмас ул сезне. Чөнки чукрак та, телсез дә ул.

Дөрес уйламаган

— Бөтен кеше алдында мине юләр хатын дип атарга ничек җөрьәт иттең!

— Кичерә күр, мин сине юләрлегеңне кешедән яшәрәсеңдер дип һич кенә дә уйламаган идем.

Ана киңәше

— Кызым, кияү белән ничек яшисез?

— Бик әйбәт, әни. Ул мин кушканның барысын да эшли.

— Аз кушасың, димәк!

Үзеннән эшләт

— Әни, дим, әнекәем, нигә дип инде оныгыңа өйгә бирелгән музыка күнекмәсен дә үзең уйный башладың. Ул бит әнә рубик кубигын гына боргалап утыра...

Димәк, ашау зыянлы?

— Көненә бары тик бер генә ашавы да зыянлы инде сезнеңчә, доктор? — дип сорый чамасыз симергән бер ханым.

— Әгәр ул ашау иртәдән алып кичкәчә дәвам итсә, әлбәттә...

Ачык авызга җавап

Бер ханым пляжда суга төшеп чумучыларны күзәтә-күзәтә дә иренә әйтә:

— Әнә теге егетләрене күр әле син, су астында нихәтле тора алалар. Мин биш секунд та чыдый алмас идем.
— Юктыр шул! Чөнки анда авыз ябык булырга тиеш бит...

Гаражда... күн пальто

Семья тормышында, дустым, бер-береңә юл биреп, килешеп яшәргә кирәк. Менә минем хәләл җефет, мәсәлән, күн пальто алу турында бик көчле хыялланды, ә мин автомашина алыйк дип каты тордым. Нәтиҗәдә килештек, юл куештык та хәзер гаражыбызда аның күн пальтосын тотабыз.

Эчкерсез җавап

Зиратта бер ир тыелгысыз үкереп елый:
— Ник үлдең син? Ник шулай бик иртә вафат булдың?
Аның янына бер әби килә дә:
— И бичаракай! Синең әтиең яки агаң кабереме әллә бу? — дип кызганыч белдерә.
— Юк,— ди әлеге ир тагын да авыррак сулап.— Биредә минем хатынның беренче ире күмелгән.

Кызыннан тугыз айга гына олырак

— Син, энкәсе, әлбәттә, үзеңне теләсәң ничек яшәртә аласың, ләкин һичкайчан шуны онытмасаң иде: кызыбыздан һәрчак тугыз айга олырак булырга тиешсең.

Һәркайсы үзенчә хаклы

— Минем хатыннан да мыжыграк кеше булыр микән? Менә өч ел инде бер чүбекне чәйни дә чәйни генә бит.
— Нәрсә дип бәйләнә соң?
— Яңа ел чыршысын ник инде һаман чыгарып ташламыйсың, ди.

Үзе турында гына...

— Мәстүрәнең беркем турында беркайчан, бер нәрсә сөйләгәне юк...
— Шулай булмый ни, үзе турында гына сөйләргә ярата ич ул.

Үзе гаепле

— Сезнең кызыгыз миңа кияүгә чыгарга ризалык бирде.

— Үзегез гаепле, һәр кичне безгә килеп йөрмәскә иде.

Алдакчы да, эшләми дә

— Сез нәрсә, Әминәгезне Әнәскә бирергә булдыгызмыни?

— Әйе шул. Нигә соравың бу?

— Соң ул бит зур алдакчы һәм өч ел инде эшләми.

— Менә сиңа мә, эшкә ике генә ел йөрмим диде бит безгә.

Балага бөтенесе алынган

Өйләнешеп бер ай торгач, яшь ир белән хатынның беренче балалары туа. Бала табу йортына шуларны алырга килгәч эти кеше әйтә икән:

— Менә, әнисе, малайга кирәк нәрсәләрнең бөтенесен алдым да инде! — Һәм сумкасындагы әлифба, көндәлек һәм карандаш тартмасын чыгарып ук күрсәтә.

— И тилекәем, әллә баланың ничек үскәнен белмисеңме... Ул бит мәктәпкә әле җиде ел үткәч кенә барачак.

— Ә безнең малай андый түгел,— ди яшь ата.— Без өйләнешкәч бер айдан ук туган икән, бер ай үтүгә мәктәпкә дә барыр.

«Авиакатастрофа»

Өйгә кайткач бер ир хатыныннан сорый:

— Хәл-әхвәлләр ничек?

— Тагын авиакатастрофа: авылдан синең туганнар очып килеп төште!

Экономия турында

— Беләсеңме нәрсә? — ди хатын үзенең иренә.— Иртәгәдән башлап без акчаны ашау-эчү исәбенә экономияле тотыйк. Аннары янга калдырылган шул акчага кер югыч машина алырбыз, ә кер юудан экономияләнгән сумага — телевизор, бу исә кино һәм театрларга акча әрәм иттерми... Нәтиҗәдә син миңа шушы экономияләнгән акчабызга тун сатып ала аласың!

Яшермәгән дә, эзләргә дә теләми

Улы көзен каладан алып кайткан киленгә икенче көнне үк каенана эшләр дә куша башлый:

— Менә бүген бәрәңге казышырсың, Аллага шөкер, ындырыбыз зур!

Килен каенананың туфрак ябышып каткан кулларына, аннары үзенең кызыл тырнакларына карый да шактый җитди булырга тырышып әйтә:

— Ул бәрәңгене җиргә мин яшермәдем һәм эзләмәячәкмен дә.

Диета өстәле турында

— Нишләп сезнең ашханәдә диета өстәле эшләми башлады?

— Чөнки андый ризыкка мохтаҗ йөрүчеләр юк. Бер клиент бар иде, аны да больниска салганнар икән.

Практик раслау чарасы, имеш

Кинәт бик каты дөбер-шатыр булып ала, пыялалар коела һәм автомагазинга тупа борыны шактый яньчелгән машина бәреп керә. Шоферы кабинадан чыга да ямьсез кычкырып кибетчедән сорый:

— Сатуда, ниһаять, тормоз накладкалары бармы инде, әллә һаман юкмы?

Дүрт урынына алты

— Конторада эшләрегез ничек бара?

— Сорама! Башлыгыбыз безне дүрт кеше өчен эшләтергә тырыша!

— Ә мөмкинме соң бу?

— Аныңча мөмкин, чөнки без бөтенебез алтау бит...

Җене сөйми

— Шул ике нәрсәне җенем сөйми,— ди ир.

— Нәрсәләр соң алар? — дип сорый хатыны.

— Өйдә ип-җай булмау һәм күп нәрсәнең кая җитте шунда аунап ятуы һәм бүлмәләрне җыештыру.

Икесе дә хаклы

— Кадерлем, куян итен бик шәп кыздыргансың бит! Үзең эшләдеңме шулай?

— Мин синнән «куянга үзең атып тидердеңме?» дип сорамадым ич...

Яшерен отыш

— Лотереяң отканын хатыныңнан ник яшердең?
— Ә лотереялык акчаны каян алдым дип әйтергә кирәк иде миңа?

Тыйган нәрсәне авыз итәсе килү

— Хәзер үзегезне ничек хис итәсез? — дип сорый доктор үзе дәвалаган берәүдән.
— Начар сизәм. Инде сез катгый тыйган нәрсәне дә авыз итәсем килә.

Кадерлең түгел, бу — мин

Берәү өенә бик соң кайта һәм ут та кабызмыйча чишенә дә йокы бүлмәсенә уза.
— Синме бу, кадерлем? — дип сорый йокы аралаш хатыны.
— Юк, бу мин, синең ирең.

Хатын хакына

— Ник бу хәтле иске бүректән йөрисең?
— Бары тик хатыным хакына.
— Ничек аңларга моны?
— «Шул бүрегеңне ташламый торып, синең белән беркая бармаячакмын»,— диде ул миңа.

Чыланган акчалар

— Гафу итегез, акчаларым бераз юешләнгән,— ди ханым мех кибетендә.— Аны миңа биргән ирем шулай елаган...

Уңышсызлыкны аклау

— Минем яңа пьесага һава хәлләренең йогынтысы бик зур,— дип зарлана бер драматург ханым.
— Ничек ул алай?
— Һава яхшы булса, халык театрга килми, шәһәр читләренә чыга, ә яңгыр яуса яки буранлап торганда — өйдә утыра.

Берсенә тәмсез, берсенә әз

— Бу Робертларга артык беркайчан аш мәҗлесенә бармыйк, картым,— ди хатын иренә.— Аның Гөлбикәсе бер дә рәтле нәрсә пешерә белми икән.

Ире исә аны куәтли төшә:

— Җитмәсә тагын порцияләрне искиткеч аз итеп салалар — мәчегә биргән хәтле генә.

Дәшми генә сөйләшү

— Хатын белән ызгышканда соңгы сүзне һәрвакыт мин әйтергә тиеш булам.

— Ничек шуны булдыра аласың?

— Чөнки мин дәшми генә сөйләшәм бит.

Ике фонарь һәм газ исе

Шактый йомшап кайтып кергән иреннән хатыны:

— Кайларда адашып йөрдең шул хәтле,— дип сүз башлый.— Газ һәм ут өчен түләдеңме?

— Күрмисеңмени битемә кундырылган ике фонарь әзен һәм миннән газ исе аңкымыймы әллә?!

«Ат типте» ди

— Иреңнең күз төбе ник каралып шешкән?

— Спортта ниләр генә булмас...

— Әллә ул бокс белән дә шөгыльләнәме?

— Юк, шахмат уйный.

— Ничек инде бу: шахмат һәм күгәргән күз төбе?

— Шахматта ат фигурасы була бит... шул ат типте ди...

«Кибеттән бүтән нәрсә алдым...»

— Менә, хатын, күпме балык кайтардым бүген!

— Күрше хатыны синең кибеттән чыкканыңны күргән ич...

— Бик мөмкин! Чөнки, артык күп булгач, тоткан балыгымның бер өлешен кибеткә дә тапшырдым.

Куанычтан һәм... акчасы юкка

— Фәтхерахман, ник бу арада бик күп эчәсең син?

— Хатыным киткән куанычтан.

— Ә ул киткәнгә елдан артык бит инде.

— Әйе. Ә минем элегрәк акчам юк иде.

Культуралы алдашу

— Алмагыз кыйбатмы, эби?
— Килосы өч сум, бабай.
— Бэлки сез менэ шул акчама ике кило бирерсез, кызыкай?
— Рэхим итегез, бирэм, егетем!

Бер-бер артлы өч үтенеч

— Миңа бурычка егерме сум биреп тор эле?!
— Акчам юк.
— Алайса, сигарет бир.
— Мин тартмыйм.
— Эй, шайтан алгыры! Ичмаса, вакыт күпме икэнен эйт?

Өендэ онытып калдырган

— Кичэ и коеп яуды да соң яңгыр! Энэдэн җебемэ хэтле чыландым. Бер зонтигым гына юешлэнмэде.
— Ничек шулай булала инде ул?
— Чөнки мин аны онытып өйдэ калдырганмын.

Белмэдең...

Кафеда утыручы ике кыз сөйлэшэ:
— Бу нинди пластинка эйлэнэ хэзер?
— Я Битлз, я «Бони М»?
— Юк, белмэдең, залның вентиляторын кабыздылар.

Сорап тору юк

— Хатыным беркайчан һэм бернэрсэ сорап тормый миннэн...
— Минеке дэ шулай: эмер генэ бирэ.

Гомергэ истэлек

— Медальоның бигрэк тэ матур инде!
— Мин аның эчендэ иремнең бөдрэ чэч бөртеклэрен йөртэм. Истэлеккэ.
— И ходаем! Мэрхүм булды да мэллэ үзе?
— Кем эйтте сиңа? Юк, чэче генэ коелып бетте аның.

Авылдан дәреслекләр килгәч

— Нишләп болай бик күңелсез күренәсең, курсташ?

— Дәреслекләр алырга дип акча сорап әтиләремә хат җибәргән идем.

— Ну?

— Алар миңа... дәреслекләр җибәрде!..

Юктыр ла ул әдәп дигән нәрсә

— Юк, әдәп дигән нәрсәнең барлыгына һич ышанмыйм мин хәзер.

— Ник шулай дисең әле?

— Бездә төнге каравылчы ханым складтан көндез дә шактый күп товар урлаган булып чыкты.

Уятучы булмаган

— Мин бүген ике смена эшләгәнмен бит!

— Ник? Ничек?

— Үзем дә сизмичә йоклап кителгән дә вакытында берәү дә уятмаган...

Иргә чыккач

Иске заманда була бу хәл. Имза куярлык та белемсез бер апай хезмәт хакы алу кәгазьләренә аркылы-торкылы ике сызыкчалы тамга гына сала икән. Көннәрнең берендә исә ул, түм-түгәрәк боҗра билгесе ясап, үзгәртеп куя кулын.

— Нишләп тамгаңны бүтәнчә иттең әле болай? — дип сорый кассир.

— Мин бит иргә чыктым, сеңелем, шуның өчен имза да үзгәрергә тиештер бит?!

Чөнки туны юк

— Беләсеңме, кодагый, быелгы кыш нинди салкын булачак?

— Чынлапмы?

— Коточкыч салкыннар...

— Ә син моны каян беләсең?

— Чөнки һаман туным юк бит әле...

Арифметиканы начар белү

— Әни, Оля апа белән син укыган кечке мәктәптә укытучы математик кем иде?

— Ник сорыйсың әле моны?

— Чөнки арифметиканы бик начар белә Оля апа: биш тиен сдача урынына гел өч тиен генә бирә.

Читән аша гәпләшү

Бер ханым үз читәне буена якынрак чакыра да әйтә икән күршесенә:

— Марина түти, сезнең тавыклар (ходай тәгалә дөмектерсен иде үзләрен!) минем шалкан түтәлләремне бөтенләй айкап чыкканнар бит.

— Хак сүз түгел бу! Минем тавыклар шалкан ашамый. Ә синекеләр кичә (җир упсын иде үзләрен!), бөтен керәннәремне астын өскә китереп утаганнарын беләм. Анттыр әгәр. Менә чын дөресе шул сиңа.

«Алайса су бир»

Берәү кунактан бераз кызмача кайта.

— Берәр стакан хәмерең юкмы, әнкәсе?

— Юк, кадерлем.

— Ә сыра?

— Анысы да юк.

— Мин кайда соң хәзер?

— Үз өебездә.

— Алайса кайнаган су бир.

Үзе гаепле

Яшь кияү кәләшен шелтәли:

— Нишләп болай бик акрын кыймылдыйсың һәр эштә, ә биегәндә күбәләктәй очынасың бит?

— Үзең гаепле. Син бит миңа эш эшләгәндә түгел, танцыларга йөргәндә гашыйк булдың.

БУ УКЛАР КЕМГӘ ТИЯР?

Алар да газета укый бит

— Прогноз бюросында эшләүчеләр һава хәле кайчан нинди буласын айлар буена алдан ничек шулай билгели беләләр икән?

— Әллә син алар гәзит укымый дисеңме?!

Телевизор булмаганга

— Элек син, этисе, сәгатьләр буе гел миңа гына карап тора идең.

— Телевизорыбыз юк чакта ич ул.

Әгәр аерылышмасак...

— Барый, син мине чынлап та нык яратасыңмы?

— Әйе.

— Үлгәнче шулай яратырсыңмы икән?

— Әлбәттә! Аерылып-нитеп куймасак...

Ике көн һәм унбиш тәүлек

Ике абзый гәпләшә:

— Мин кайнаткан көмешкә шундый шәп,— дип мактана берсе.— Эчсәм, ике көннән генә аңыма киләм.

— Шул да булдымы көмешкә! Ә менә мин үземнекен эчсәм, унбиш тәүлектән соң гына өемә кайтып керәм!

Әйтүе кыен

— Алло! Надяны телефонга чакырсагыз икән?!

— Ул чыкты.

— Әгәр сер булмаса, кая?
— Кияүгә!
— Озаккамы?
— Әйтүе кыен.
— Алайса, кайткач әйтегезче аңа, зинһар, Васяга шалтыратсын әле!

Мактаулы малай

— Мин улымны берәр тынлы оркестрга бирергә телим.
— Булдырыр дип уйлыйсызмы?
— Әлбәттә. Аның хәтта өч метрдан торып шәмне өреп сүндергәне бар!

Фикерләр уртаклыгы

— Мин беркайчан да ахмаклар белән бәхәсләшмим.
— Димәк, һәрвакыт алар белән бер фикердәсең!

Отыштан соң

— Ник сезнең капитаныгыз бүген бик ачулы?
— Кичә лотереясына зур отыш чыккан.
— Моңа бит шатланырга кирәк?!.
— Чөнки отышы диңгездә бер айлык сәяхәт икән.

«Анда сыра сатмыйлар»

— Ни өчен син сыраханәгә шулай еш йөрисең?
— Музыка яратам.
— Ә нигә концертка бармыйсың?
— Анда сыра сатмыйлар.

Бердәнбер хезмәткәр

— Местком членнарыбыз исемлегендә таныш булмаган бер фамилия күрәм, кем икән ул?
— Ә-ә, бәлки, ул бөтен эшләребезне башкаручыдыр.

Чынга ашкан хыял

— Яшь чактагы хыялларыгыздан берәр нәрсә инде чынга аштымы?
— Әйе. Әни чәчемне кырыкканда мин һәрвакыт такыр баш булу яхшырак дип хыяллана идем.

Бүтән чара юк

— Әйтегез әле, Бари ага, сез, юан гәүдәле кешеләр, ни өчен икән, киң күңелле һәм олы җанлы буласыз?

— Чөнки бүтән чарабыз юк: без бит ни кыйнаша, ни чабып кача алмыйбыз.

Таксист әйтә

— Бу калада инде егерме ел торам дисез, ә вокзалга хәтле иң кыска юлны ничек белмисез?

— Гафу итегез, мин таксист бит...

«Алайса яңгырны язмыйк...»

Метеорология бюросы башлыгы һава хәле прогнозын машинкада әйтеп яздыра:

— Якшәмбе көнне болытлы һава көтелә, вакыты-вакыты белән яңгыр һәм көчле җил.

— Их, кызганыч! — ди машинистка.— Мин ял көнне кем белән дә булса берәр урманга китәргә уйлаган идем.

— Алай булса, яңгыр белән җилне язмыйк әйдә.

Сүгенмичә генә әйткәч...

Мастер белән эшче сөйләшә:

— Ник мин кушкан детальләрне эшләмәдең?

— Чынлап кушкан идегезмени? Сүгенми генә әйткәч, ашыгыч кирәк түгелдер дип уйлаган идем шул.

Чын күңелдән сөйләшү

Эстрада концертында берәү күршесенә:

— Аңламассың сезне,— ди.— Җырчыга әле генә черек алмалар ыргытып утыра идегез, хәзер кул чабасыз!

— Тагын сәхнәгә чыксын дип кул чабам — кесәмдә ике черек алма бар әле.

Күрәзәче түгел...

— Миңа бурычка ун сум биреп тор әле.

— Ярый. Ә кайчан кайтарырсың?

— Аны белергә мин сиңа пәйгамбәр яки күрәзәче түгел ләбаса...

Бүтәнне теләгән

Бер чибәр кыз артынан ике егет атлый. Кыз дигәнебез, моны сизеп, юри кулъяулыгын җиргә төшерә. Егетләрнең әпен-төпенрәк атлаучысы кулъяулыкны шунда ук иелеп ала да кызга бирә:

— Бу сезнеке иде булса кирәк?

— Әйе, минем кулъяулыгым бу. Ләкин, турысын әйтәм, аны сезнең иптәшегез алып бирүен теләгән идем мин.

Гади фәлсәфә

— Син ник эчәсең?

— Хатыным тирги.

— Ә ни өчен тирги ул?

— Эчкән өчен.

Кире алу юк

Бер сатып алучы кибет директорына зарлана:

— Сезнең сатучыгыз мине мыскыл итте. Үз сүзләрен кире алуны таләп итәм.

— Кызганычка каршы, без бер нәрсәне дә кире кайтарып алмыйбыз, шундый ук бүтән нәрсәгә генә алыштырырга мөмкин.

Бер генә билет

— Кадерлем,— ди икән хатынына бер ир,— сиңа искә күлмәктән театрга бару килешмәс дип уйладым мин.

— Әллә яңа күлмәк алдыңмы?

— Юк, театрга бер генә билет алдым.

Эш бирәбез дигәч

Танылган бер футболчыны үзләренә чакырырга көндәшләре клубыннан вәкилләр килгән:

— Әгәр безнең командага күчсәң, сиңа мең ярым сум бүләк һәм заводта иң-иң яхшы эш бирәчәкбез.

— Акылдан яздыгызмы әлле сез! — ди икән уенчы, кәефе кырылып.— Миңа — эш?!

Сальдо баш түгел ич колхозга

Яңа гына куелган колхоз председателе бухгалтерына әмер биргән:

— Менә счетлар, иртәгә бөтенесе түләнгән булсын.

— Сальдо кушмый бит, сальдо. Счетыбызда акча юк чак. Чыгымыбыз керемнән күбрәккә киткән...

Моңа бик ачуы чыккан икән председательнең:

— Сальдо башмы колхозда, әллә минме? Күчер дигәч күчер.

Чуалган хәтер

— Нишләп бик тиз әйләнеп тә кердең әле?

— Хәтер дигәнемне син генә шулай төпсез иләк иттең: чаңгыларымны алырга онытканмын ич...

Мылтыгын яшереп йоклаган

— Складтагы бөтен нәрсәне алып чыкканнар дисең алайса? Соң бит син мылтыклы каравылчысың?!

— Анысын ничектер күрми калганнар...



ОЗЫН СҮЗНЕҢ КЫСКАСЫ

Көнче ир

— Боргаланма-сыргаланма, бөтенесен беләм бит...— дип мәсьәләне кабыргасы белән куя бер көнче ир хатыны алдына.

— Алайса әйт инде, җаным: атаклы Полтава сугышы кайсы елда булган?

Кызыгу

— Бәхетле кеше син, күрше: хатының турист ичмаса.

— Нәрсәсе кызыктыра моның?

— Үз хатынымны шундый дәү биштәр күтәреп йөрергә һич өйрәтә алмыйм.

Гадәте шундый

— Бабай, ник сезне «космонавт» дип йөртәләр?

— Гадәтем шундыйгадыр ахры, чөнки карчыгым гәпләшә башласа, космик тизлек белән очып өйдән чыгып китәм мин.

Кыйммәтле ихтирам

Юл уңаенда очраган бер машинаны туктатып калага хәтле утырып бара бер әби. Барып җиткәч шоферга зур рәхмәтләр әйтә. Шофер исә:

— Ни пычагыма миңа синең зур рәхмәтең, бер кечкенә бишлегең юкмы әллә?

Әбисе туган көндә

— Ник, балам, болай расходланып шундый дәү букет алып килдең? — ди куанычтан күңеле бик нечкәргән әби.— Үз бакчабыз тулы чәчәк бит.

— Тулы иде, ә хәзер бик әз калды инде.

Кызганыч

— Улым, бүген нинди биремнәрең бар мәктәптән?

— Бүген өйдә эшлисе дәресләрем бөтенләй юк, әби.

— Кызганыч. Кухняда тагын савыт-саба юарга туры килә алайса.

Ни өчен дисең...

— Акыллы ханым өйдә яхшы хатын булалмый диләр. Дөрестер, ахры.

— Ни өчен?

— Чөнки андыйлар иргә бик сирәк чыга.

Бәлки тагын бер тустыган...

Күршесе шактый каты сырхаулаганын ишеткәч шуның хәлен белергә керә берәү. Тегенең хәләл җефете аңа җимеш шәрабы салып бирә:

— Ирем саулыгына авыз итсәгез икән! — ди.

Күрше эчә һәм сырхауга шактый озак карап тора да әйтә:

— Бичараның хәле бик шәптән түгел икән шул. Бәлки аның саулыгына тагын бер тустыган каптырырсын?

Ике фикер

Бер абзый үлә һәм шуны ни җәннәткә, ни тәмугка алмыйлар. Шайтаннар әйтә:

— Нигә моңа сумала әрәм итәргә?!.

Фәрештәләр уйлый:

— Барча алмагачларны селкеп бөтен алмаларны коеп бетерер кебек бу...

Тротуарга бор

Машина рулен тоткан бер ханым үзе белән янәшә утырган иренә ишеттереп сөйләнә:

— Кара нинди әшәке җаннар! Машина астына керәләр бит инде... Нишләргә миңа?..

— Зур тротуарга бор әйдә.

Кайсын сайларга?

Врачка күренеп кайткан хатын әйтә икән иренә:

— Миңа быел Кара диңгезгә барырга тәкъдим итте. Син ничек уйлыйсың: нинди курортны сайлау яхшырак булыр?

— Минемчә, син бүтән врачны сайларга тиешсең.

Бер-ике көннән... Кайта

Каравылчы Охрим кибет ишеге төбендәге карны себергәндә килеп чыккан Параска әби сорый аңардан:

— Ә кибетче кайда, ник ишеген һаман ачмый?

— Әбәткә китте, бер-ике көннән килерсез, шунда кайтырга тиеш.

Таныш таш

— Күрше, бу ташны ник минем бакчага ташладың?

— Мин икәнен каян белдең?

— Ничек каян? Кичә мин үзем ташлаган таш бит бу.

Үземнеке качмый

Бер исерекне күршесе өенә озата килә. Тәрәзә шакыгач тегенең хатыны чыга да моны кыйный башлый.

— Нишләп әле болай бу? — дип аптырый күршесе.

— Шулай менә. Үземнеке беркая да качмый ул.

Кәбестә ите

— Күр син аны, үзен вегетарианец саный, үзе ит ашап утыра.

— Куян ите ич бу. Ә куян кәбестә ашап үсә.

Уйнарга өйрәнгәч

— Син хатыныңны карта уйнарга өйрәткәнсең имеш. Дөресме бу?

— Әйе, өйрәнде. Инде аның белән карта уйнап мин үткән айгы хезмәт хакымның яртысын оттым.

Сәбәбе бер генә

— Минем өемә кичә бер карлыгач очып керде, моны, бабакай, нәрсә дип һәм ничек юрарга икән?

Яшь ханымга авылның үтә зирәк көлкече карты үзенчә итеп җавап бирә:

— Сезнең я ишегегез, я тәрәзәләрегез ачык булган ул чакта.

Беренче очрак

— Рәхмәт сүзе яза торган кенәгәгезне бирсәгез икән миңа? — дип сорый берәү кибеттә сатучыдан.

— Безгә шуны язачаксызмы?

— Ничек язмаска ди: бүген бит миңа беренче мәртәбә вак акча кайтарып бирделәр биредә.

Кирәген әйтмәгән

— Ник болай бик арып-талып һәм мескенләнеп кайттың әле, этисе?

— Бар да синең аркада: ата-аналар җыелышына бар дидең, ә малаебыз кайсы мәктәптә укыганын әйтмәгәнсең.

Чучканың ни гаебе бар?

— Беләсеңме, кадерлем, чучкабызны суярга туры килә бит: тиздән безнең никахлашуга егерме биш ел тула.

— Чучканың монда ни гаебе бар?

Юләр түгел ич ул

— Беләсезме, күрше, сезнең этегез миңа өрми бит хәзер!

— Юләр түгел ич ул... Бәйләнеп кара сиңа...

Һәркемнең үз яртысы

Ике күрше, бергә симертеп үстергәч суярга һәм итенмаен тигез бүлешергә дип, чучка баласы сатып алалар. Күпмедер вакыт үткәч шуларның берсе әйтә икән:

— Син, Микола, үзеңә тиеш өлешне теләсәң симерт, теләсәң көтүдә йөрт, ә мин үз яртымны суярга булдым.

Ничек эшли?

— Яхшы эшлиме яңа алган сатучыбыз?

— Болай ярыйсы, ләкин кыяфәте гел йокылы күренә.

— Алайса аны пижамалар һәм төнге күлмәкләр бүлегенә күчерергә кирәк.

Начарларның яхшысы

— Иптәш редактор, минем роман чыннан да кулга тотарлык түгелмени?

— Юк, киресенчә: без кире каккан әсәрләр арасында ул иң яхшы дип саналырлык иде.

Кем бәя бирә бит...

— Нинди язучы иң атаклы дип саналганын беләсеңме син?

— Юк.

— Әгәр аңа бер әсәрен дә укымаган кешеләр югары бәя бирә башласа — шул әдип күренекле була.

Ник күралмыйлар?

— Минем ул кешене күрәсем дә килми.

— Мин дә шулай.

— Синең аңа күпме бирәсең бар соң?

Больницада шаяру

— Бүген безнең больницада гадәттән тыш бер вакыйга булды.

— Кемне дә булса дәвалый алдыгызмы әллә?

Үзе дә белми...

— Телевизион конкурста мин өч бүләк алдым.

— Нәрсә өчен?

— Беренчесен хәтерем яхшы булганга бирделәр, калган икесе ни өчен икәнен оныттым инде.

Өзеп әйтү

— Кадерлем, бер генә сүзеңне өзеп әйт — һәм мин гомерлеккә синеке булачакмын!

— Ишәк син!

Шунда да мактана

— Кичә күпме балык тоттың?

— Бер дә эләкмәде. Ә син?

— Мин дә шулай. Әмма минем балык зуррак булырдыр...

Күрмәмешкә салышу

— Күрмисезме әллә юл билгесен: бер генә юнәлештә йөрергә диелгән ич?!

— Әллә мин ике юнәлештә бараммы? — ди шофер.

Киресенчә эшләгәннәр

— Юарга биргән керләрем арасындагы күлмәкләргә бүтән төймәләр такканнар.

— Бу әле түзәрлек! Ә миңа бүтән күлмәкләр тегелгән төймәләр бирелде.

Югалмас өчен эзләү

— Ниемә дип шулай бик тырышып талантлар эзлисез?

— Чөнки талантсызлар безне үзләре бик тиз таба.

Алдан ук елап кую

— Ничек син шулай сәхнәдә кеше ышанырлык итеп оста елый аласың?

— Ул минутта мин бу роль өчен алган акчамның бер тиенен дә хатын миңа бирмәячәк бит дип уйлыйм.

Сеңеленең сеңелесе

— Кызыкай, синең бик матур сеңелең бар дип әйтәләр, дөресме?
— Бар, ләкин минеке түгел, минем сеңелемнеке.

Корыч ихтыярлы ханым

— Минем ирем тәмәке тартуын ташлады.
— Моның өчен бит корыч ихтыяр кирәк!
— Әлбәттә. Миндә нәкъ шундые бар да инде.

Яхшыдан баш тарту

— Сезнең өчен иң яхшысы шул: эчүне һәм тартуны бөтенләй ташларга кирәк.
— Доктор, мин үземне иң яхшысына лаек түгел дип саныйм. Бераз начаррак режим юкмы?

Иң яхшы бүләк

— Туган көнеңә нәрсә бүләк итим икән, картым?
— Берара вакыт дәшми торырсың.

Түшәктә... балык

— Квартирагыз бик юеш дип чынлап зарланасыңмы?
— Анттыр әгәр! Кичә түшәгебездән бик бәләкәй бер балык таптык.

Әгәр тагын лыгырдаса...

— Күршеңә чынлап та суктыңмы син?
— Ялган бу! Әгәр шундый юләр сүз лыгырдаса, мин аның ипи шүрлегенә тагын бер менеп төшәчәкмен!

Запаслы исәп

— Вокзалга ни өчен шулай ике-өч сәгать алдан килдесең син?
— Өйдә онытып калдырган берәр нәрсәмне кайтып алырга вакыт кирәк булса дип.

Серен ачты

Бер ханым үз ахирәтенә әйтә:
— Кече сеңелемнеке белән минем яшьне бергә куш-

сак безгә нәкъ алтмыш була.

— И ходаем, шундый бәләкәчне үзен генә өйдә калдырырга ничек курыкмадың?

Шигъри сүзләр ярату

— Җан кисәккәем, минем күзләр нәкъ күк йөзедәй зәңгәрме?

— Әйе.

— Ә иреннәрем ал чәчәктәйме?

— Һе-һе...

— Рәхмәт, и яратам да соң миңа шундый шигъри сүзләр әйткәнеңне...

Кисәтү

— Ирең буласы егет ни диде соң сиңа, кызым?

— Тыныч гаилә тормышы турында хыялланам, диде.

— Кызым, сак бул син аның белән! Өйләнгән кеше була ич инде ул алайса.

Каян белгән?

— Директор мине эш вакытында футбол караган өчен премиядән мәхрүм итте.

— Каян белгән ул синең футбол караганыңны?

— Стадионда үзе янәшәмдә утырды.

Теләге нинди икән?

— Хатыным минем белән аерылышырга тели ахрысы.

— Ник алай дисең?

— Кичә дус кызын өебезгә алып килде.

— Ә моның нәрсәсе бар?

— Нәрсәсе шул: ул кыз чибәрнең дә чибәре!

Яратмау

— Юк, аны яратмыйм һәм ярата да алмам ахрысы.

— Ник?

— Зур колаклары һәм кечкенә эш хакы миңа ошамый.

Эше күңелле

— Син кайда эшлисең?
— Почтада! Хатларга штамп сугам.
— Бик күңелсез хезмәттер ул?
— Юк! Чөнки һәр көн яңа дата бит.

Тик йоклый белү

— Бигрәк экрен кыймылдыйсыз эштә! Ичмаса бер генә нәрсәне тиз башкарсагыз икән.
— Мин бик тиз йоклап китә алам.

Икесе дә ялгышкан

— Бу телефон номерен дөрес җыйдым дип уйлыйсызмы?
— Әлбәттә дөрес! Ә менә сез телефон трубкасын ялгыш алгансыз!

Оныклар калачак

— Әгәр ата белән ана бөтен булганнарын балаларына бирсә, балалар үскәч аларга нәрсә калыр?
— Ничек нәрсә? Оныклар.

«Үзе куып керде...»

— Музейга эт ияртеп керергә ярамый ич!
— Беләм. Ләкин бит ул мине үзе монда куып керде.

Өенә кайта

— Салмышсыз ич. Бу килеш кая барасыз?
— Өемә кайтам, сержант иптәш. Яңа ел каршылаган төштән.
— Хәзер бит март ае инде.
— Шуңа ашыгам да шул. Анда хатыным борчылып көтәдер!

Буталыш

— Дөресен әйткәндә, мин бит кыз бала булып туганмын.
— Сөйләмә юкны!
— Чынлаптыр менә! Бала табу йортында бутаганнар...

Әдәпле сүзләр генә язсам?

— Владивостокка телеграмм суккан өчен күпме түләргә кирәк?
— Күпме сүз һәм ничек язасың бит.
— Бөтен сүзләрем дә әдәпле булса?

Даруны ире ала

— Мин сезгә гел йокы даруы бирәм, ә сез һаман саен төнге кафеда күренәсез. Файдасы тимиме әллә?
— Мин аны, доктор, хатыным өчен алам бит.

Булмас, булмас!

— Кичә синең хатының бер майор белән култыклашып бара иде.
— Булмас, булмас! Минем хатын хәрби дәрәҗәләрне аера алыр микән?

Урынлы теләк

— Күптән түгел сезнең романны укыдым.
— Соңгысынмы?
— Шулай булуын теләр идем...

«Бүген... үзем ашадым!..»

— Беләм, җан кисәгем, син моңа бәлки ышанмассың да,— ди бер ир үз хатынына,— әмма син әзерләгән гуляшны бүген үзем ашадым.

Күршеләр ышанмый

— Ирең сиңа һаман шулай ук бик игътибарлымы әле?
— Әйе. Безнең ирле-хатынлы икәнлеккә хәтта күршеләр ышанмый да инде.

Тозын таманлау чарасы

— Кадерлем, бу ашны синең утыз литр чамасы пешерәсең калган.
— Әллә сиңа шулай бик ошадымы?
— Юк, шулпасын күбрәк пешергәндә тозы таман буласы икән.

«Нәкъ синең кебек ул...»

— Карале, дустым, Бари миннән бурычка акча сорый. Биримме икән?

— Мин аны, кордаш, нәкъ сине белгәнем кебек беләм: ышанып бер тиен дә бирмә.

Төнге өчтә

— Картым, картым, тор әле, тор, безнең баскычтан кемдер менә бугай.

— Ә вакыт күпме соң хәзер?

— Инде өченче ярты.

— Алайса мин өйгә кайтамдыр.

Ә нинди көй?

— Минем матәмемдә оркестр уйнатуыгызны үтенәм!

— Ярый, булыр. Ә нинди көй тыңларга теләр идегез?

Тынычлык та кирәк

— Бу ниткән тәртипсезлек тагын. Ник эштә йоклап утырасыз. Моның өчен өегездә вакыт бар ич.

— Әйе, вакыт — бар. Ә бит йоклар өчен тынычлык та кирәк.

Торт капмый калу

— Күпме бәйрәмнәр узды, кемнәрдә генә кунакта булмадым, ләкин беркайчан да торт кабып караганым юк әле.

— Ник?

— Чөнки аны мәҗлеснең азагында бирәләр, ә мин ул чакта инде өстәл астында булам.

Оптимист егет

— Беләсеңме, безнең Алик гаять оптимист кеше икән?

— Каян белдең?

— Соңгы акчасына кошелок сатып алды.

Тар булмадымы?

— Беләсеңме, картым, миңа бүген трамвайда беръюлы өч кеше урын бирде!

— Ничек соң, җиттеме берүзеңә?

Дәвадан соң

— Сарымсак ашап дәвалану нинди нәтиҗә бирде соң?

— Үлчәвем өч килога кимеде һәм бөтен дусларымны югалттым.

Ләззәттән ваз кичү

— Улым, мин эштән гел ләззәт таба торган идем, ә син аңардан һаман качарга тырышасың.

— Гафу ит, әтием, минем ләззәтләнеп кенә яшисем килми шул!

Ә калганнары?

— Барча ирләр дә, минемчә, донжуаннар.

— Барчасы да дисеңме?

— Әйе шул. Ә калганнарын ирләр дип кем санар икән?!

Числосын әйт ичмасам!

Ачуыннан җенләнгән ир театрга барырга чамасыз озак җыенган хатынына идәнгә аяк тибеп кычкыра:

— Кайчан чыгып китәбез соң инде? Числосын әйт ичмасам!

Утюг шнуры кыска булганга

— Кадерлем, нишләп син минем чалбарның балак очларын гына үтүкләдең?

— Әйттем бит мин сиңа утюг шнурын озынайт дип.

Тәки мактатты бит үзен

— Җан кисәгем, миңа синең бөтен нәрсәң ошый: килеш-килбәтең, мөлаемлыгың, акылың. Бу яктан сиңа һичкем тиң булалмый. Әйт әле дөресен генә, ә сиңа минем нинди сыйфатым бигрәк тә ошый?

— Зәвыгың.

Борчылу

— Һай яман да соң бүгенге көн! Яңгыр чиләкләп коя бит. Ә хатыным зонтигын алырга оныткан.

— Бәлаң зурдан түгел лә, хатының берәр кибеткә кергәндер әле.

— Нәкъ менә шул борчый да инде мине.

Кем ул иллюзионист?

— Иллюзионист кем була ул?

— Адәм ышанмаслык һәм аңламаслык могҗиза эшли торган кеше.

— Синең кебек, футболга дип китеп, айныткычтан да кайта аламы?!.

Күрмисезме әллә?

— Гражданин, автомат телефон трубкасын ярты сәгать тотып торасыз инде, әле авыз ачып бер сүз дә әйткәнегез юк!

— Комачауламагыз ла! Күрмисезме әллә, хатыным белән сөйләшәм ич?

«Белмим, эчмәдем...»

— Быел ялыгызны кайда уздырдыгыз?

— Балтик диңгезендә.

— Анда су салкын диләр бит.

— Белмим. Мин су эчмәдем.

Уртак теләклеләр

— Ник азапланасың шул тешең белән? Әгәр минеке булса, күптән суырткан булыр идем инде.

— Әгәр ул синеке булса, әлбәттә, мин дә шулай эшләр идем.

Ишетелми

Күршеләрегезгә ни булган? Өч көн инде кыйнашканнары ишетелми...

— Бәлки үпкәләшкәннәрдер.

Әгәр ул торса...

— Әнә теге ир кешене мин бик тә тәкәллефледер дип беләм.

— Ник?

— Чөнки әгәр ул торса, урынына өч ханым утыра алыр иде!

Нишләмәк кирәк

— Сез миңа биргән бу порция тавык бары тик сөяк белән тиредән генә тора бит?

— Нишләмәк кирәк? Хәзер мода шундый бит — бөтенебез ябыгырга тели.

Кем нәрсә ярата?

— Минем хәләл җефетем этләр һәм мәчеләрне бик ярата.

— Ә минеке, кызганычка каршы, затлы мехлы җан ияләрен теленнән төшерми.

Вак-төякләр турында

— Еш кына безне зур вакыйгалар түгел, вак-төяк нәрсәләр бимазалый.

— Нидән чыгып әйтәсең моны?

— Кичә, мәсәлән, мин үз өемне шактый тиз эзләп таптым, ә ачкычны йозак ярыгына кертәлмичә әллә күпме вакыт узды!

Урамда сөйләшү

Урамнан узып баручы бер ирне туктата да:

— Сез минем балалардан берсенең этисе димме әллә?

— Мин? Монысы инде бер капкага да сыймас яңалык.

— Зинһар, тынычлана күрегез. Мин укытучы бит...

Туйлар остасы

— Я, сөйләп бир инде, туй сәяхәтеңне ничек үткәрдең?

— Гадәттәгечә...

Ялгыш киелгән костюм

— Бу костюмны киеп начар иткәнмен бит әле мин!

— Юк, иркәм, бу костюмың белән син бик ыспай күренәсең!

— Анысы шулайдыр бәлки, әмма бүгенге спектакльгә билетлар теге кесәдә калган бит.

Озакка китә, кыйбатка төшә

— Сезнең бу никахны теркәгәнче моңарчы булган никахларыгыз турында белешмә тутырырга кирәк.

— Алай бик озакка китә һәм кыйбатка төшәчәк бит, чөнки бирегә без счетчигы акча санап торган такси яллап кына килдек.

Оста киңәше

— Сез ремонтлаган бу будильник һаман эшләми.

— Вак мәсьәлә ич бу: шалтырарына өч минут кала аны бик каты селкергә генә кирәк.

Ашларын ошатмагач

— Бу шницель ботинка олтаныннан да катырак ич!

— Күр син аны, үз гомереңдә нәрсә генә ашамады икән бу кеше!

«Симерүемне көтәләр...»

— Син уенга өйрәткән арсланнар ничек тимиләр үзеңә? Син бик кечкенә һәм ябыксың бит...

— Фокусның бөтен мәгънәсе дә шуңа кайтып кала инде: алар минем симергәнне көтәләр.

Авызыңны да ачма

— Сиңа күктән йолдыз чүпләп биримме, алтыным?

— Авызыңны да ачма йолдыз турында! Бүген сиңа бары тик өйдә утырырга кушылды бит.

Зәвыгы начар

— Ирина белән ник очрашмый башладың?

— Аның зәвыгы начар.

— Каян беләсең?

— Чөнки ул «син миңа ошамыйсың» диде.

Сөйли башла

— Синə җитди сүзем бар, картым, эшеңнән тизрәк кайт.
— Хәзер үк сөйли башласаң да ярый, мин тиздән кайтып җитәрмен.

Аш алдыннанмы?

— Доктор, бер ун-унбиш килога кимисем килә минем. Моның өчен нишлим икән?
— Көненә маргарин белән генә бер телем ипи, бозау итеннән бер котлет, ике алма гына аша.
— Аш алдыннанмы, әллә соңыннанмы?

Шуны күрсәтегез әле?

— Сезнең ашханәдә ипи кисәгенең ике ягына да май ягыламы?
— Юк, бер генә якка.
— Шул якны зинһар, күрсәтегез әле миңа!

Алайса буш шешәләр күптер...

Чүпрәк-чапрак җыючы берәү кемнеңдер өенә шалтырата.
— Сездә кирәксез кәгазь, нинди дә булса тимер-томыр яки бүтән төр сәләмә юкмы?
— Бүтән чакта рәхим итеп шалтыратыгыз. Аларның кайдалыгын белмим, хатыным ял йортында иде.
— Алайса сездә буш шешәләр күптер?!.

Мин кем булам?

— Ник елыйсың, балакай?
— Әнием этине «син бит фил» дип тиргәде. Ә эти аны тавык дип атады.
— Ә нәрсәсе бар соң моның?
— Алайса мин үзем кем булам соң?

Ике ягы да бер юлы туктала

— Кондуктор, бу вагонның кайсы ягыннан төшәргә кирәк — алданмы, арттанмы?
— Кайсыннан да ярый, апай. Чөнки ике ягы да берьюлы туктала.

Яңгырда юылып чистарган

— Ай алла, безнең теге уртак таныш бикәбезнең йөзе шул хәтле агарганын һичкайчан күргәнем юк иде. Ни булды икән аңа?

— Әйе, ул зонтигын алмыйча чыккан шул, бүген дә бик каты яңгыр астында калган.

Яңача дәвалану

— Мин хәзер ял итү белән дәваланам әле.

— Ә ничек була соң ул?

— Көн саен шифаханәгә барам да врач бүлмәсе каршында өч сәгать рәттән чират көтеп утырам.

Ничек табарга

— Коммуналь хуҗалык идарәсен ничек табарга биредә?

— Менә бу шыксыз тузан басылгач юлны күрсәтермен,— ди бирәү.

«Гафу итмәячәкмен»

Ире белән бик каты ачуланышып талаша да эти-әниләре өенә китеп бара бер ханым. Бераздан соң әйләнеп кайткач ялынып-ялварып иреннән гафу үтенә.

— Атаң-анаң йортына китүеңне кичерәм,— ди икән ул әфәнде,— ә менә биргә кире кайтуыңны һичкайчан гафу итмәячәкмен!

Иске йортны кем салсын ди

— Син яңа йорт саласың, имеш.

— Ә син кемнең дә булса иске йорт салганын кайчан ишеткәнең бар?

Әгәр бергә ашасак

Ресторан башлыгы официант белән сөйләшә:

— Нәрсә ашыйбыз?

— Әгәр бергә икән, әлбәттә тәмле ризык булачак.

Барабанчы зары

— Тормыш дигәнем бөтенләй җәһәннәмгә әйләнде минем.

— Нәрсә булды соң?

— Иртән балалар акырып уята. Аннары, тузан суырткычыбызның чамалы гына чыжылдаган тавышына кушылып, үзенең тавышлы өермәсен хатын өя башлый. Тәрәз төбендә генә дөбердәп һәм шак-шок килеп асфальт кимерәләр. Күршем магнитофоны бертуктаусыз акыра... Бары тик эштә генә азмы-күпме ял итәм кебек.

— Ә кем булып эшлисең үзең?

— Оркестрда барабанчы.

Сәбәпләре нигезлеме?

— Син хатының белән ник аерылыштың?

— Пылау пешерә белми.

— Бүтән төрле ашлар да бик күп бит!

— Ә бүтәннәрен ул пешереп тә карамады.

Өченчесе нигә?

— Бездә яңа өч бассейн ясадылар: берсе салкын, берсе җылы сулы, өченчесенең исә суы бөтенләй юк.

— Ә анысы нигә?

— Йөзә белмәүчеләр өчен.

Кем алыштырган?

— Кичә мин кунакта булдым, шунда бүрегемне алыштырганнар.

— Кит әле?! Синеке кебек таушалып һәм кыршылып беткән бүреккә кайсы кызыкты икән?

— Белмим шул. Чөнки мин иң алдан кайтып киткән идем.

Тынычландыру

Берәүнең юбилей кичәсендә берәү үз янәшәсендә утырган кунакка әйтә икән:

— Сиксән яшемдә мин дә бүгенге юбиляр шикелле күренүемне теләр идем.

Күршесе аны тынычландыра:

— Сез бит хәзер дә нәкъ аның кебек күренәсез!..

Кызыктыргыч язмыш

— Минем ирем археолог.

— Бик кызыгам мин синең язмышыңа. Син бит картая барган саен аңа кадерлерәк булачаксың.

Үзенә түгел, иптәшенә

— Миңа бер чәркә хәмер бирегезче?
— Бирә алмыйм, чөнки сез инде эчкәнсез.
— Үземә түгел, ә бер иптәшемә сорыйм бит.
— Кая ул иптәшегез?
— Ишек төбендә ята.

Уйлап табу

— Зонтигың ник тишек?
— Үзем уйлап тапкан яңалык: яңгыр туктавын карап белер өчен эшләдем.

Кырынудан тую

— Сакал үстерәм әле мин дә,— ди икән бер бабай.— Көн саен кырынудан тәмам туйдым.
— Шашма акылыңнан! Әллә сиңа унсигез яшьме?!

Бетховенны ал...

— Яңа пианином өстенә куярга нинди бюст килешәрәк төшәр икән: Брамсмы, Бетховенмы?
— Бетховенны ал: ул саңгырау булган...

Парижпан кайткач бирәм

— Миңа әҗәткә ике йөз сум биреп тора әле?
— Парижпан кайтмыйча бирәлмим.
— Кайчан барасың анда?
— Әле билгеле түгел. Француз телен өйрәнә башладым инде.

«Әкият түгел лә бу»

— Әни, миңа әкият сөйлә әле!
— Ярый, тыңла. Бер кечкенә кыз бала яшәгән. Ул һәрвакыт әти-әнисенең сүзен тыңлаган, өйдә булышкан, дәресләрен яхшы әзерләгән, гел чиста итеп юынган.
— Җитте! Әкият түгел лә бу. Син хыялый хикәя сөйлисең, әни.

Укырга оныткан

— Соңгы вакытта хәтерем бик чуала башлады әле.
— Нидән беләсең моны?

— Кичә иремә хат килде, мин шуны укырга онытканмын.

Кайгырта беләләр

— Сез беләсезме, хатын-кыз шоферлар аварияне азрак ясыйлар икән.

— Ә сәбәбе?

— Чөнки алар машина турында ирләрен кайгырткан кебек үк кайгырта, ә ирләр исә машинага үз хатынына караган кебек карый.

Чит илләрнең берсендә

— Кунак өендә кунган өчен күпме аласыз?

— Ике бәя бар: бериш бүлмәләр егерме, икенчеләре утыз франк тора.

— Аермалары нидән гыйбарәт соң?

— Утыз франклы бүлмәдә тычкан тота торган тәбе бар.

Эшләмәскә дә була

— Яңа директорыгыз ничегрәк? Бергә эшләп булырлык күренәме?

— Һи, аның белән бөтенләй эшләмәсәң дә була.

Сүздә тору

— Менә сүземдә тордым, энкәсе, туган көнеңә чәшке тунны тәки алдырдың бит!

— Ә вәгъдәң машина иде ләбаса...

— Гафу ит, җаным, ясалма материалдан эшләнгән машиналар юк бит әле.

Дөрес бит, әй!..

— Хатының сине ташлап үз эти-әнисе янына кайтып киткән дип сөйлиләр. Дөресме бу?

— Әйе. Син әзерләгән ризыкны ашый алмыйм шул мин диде дә табан ялтыратты.

Син аны өйдә үстер

— Ник эшкә кырынмыйча киләсең?

— Сакал үстермәк булдым бит әле.

— Ә син аны эштә түгел, өйдә үстер.

Озын түгел, сирәк

Безнең кукуруз сабаклары быел телеграф баганалары кебек булды.

— Шундый озынмы?

— Юк, шундый сирәк...

Әз генә көтегез

— Нәрсә тектерергә телисез?

— Күлмәк, ләкин иң соңгы мода булсын.

— Алайса ярты сәгать чамасы көтәргә кирәк булыр.

— Ник?

— Хәзер нәкъ модалар алмашкан вакыт.

Әйтерсең бүтәне ярамый

Эчүчелеккә каршы лекция тыңлап кайтышлый ике абзый үзара сөйләшә:

— Инде дә булса юләр кешеләр бар икән әле бу дөньяда: күрә торып зәһәр алкоголь эчәләр бит, әйтерсең аларга сыра яисә эче бал гына җитми...

Шакыдылар ахрысы...

— Сезнең артельгә төнге каравылчы кирәк дигән белдерү элдергән идең. Кем дә булса шакыдымы соң кадрлар бүлеге ишеген?

— Шакыгандыр ахрысы, чөнки кичә безнең складны таладылар!

Утырмыйм, егылып кына төштем...

Театрда билет тикшерүче апа, тәртип бозылган дип әлбәттә, алты яшендәге бер малай белән сөйләшә:

— Карале, бала! Синең билет балконныкы бит, ә ник партерда утырасың?

— Юк, гафу итегез, мин утырмыйм, бирегә бары егылып кына төштем.

Сәер хәл

— Карале, күршекәй: сезнең этегез минем туфлине алып киткән?!

— Бик сәер ич бу! Ә бит өйгә яланаяк кайтты...

Эшен төшендә күргән

— Эштә ник йоклап утырдың?
— Әйе, черем итеп алдым шул, башлыккаем. Ләкин бит мин ничек эшләвемне күрдем төшемдә.

Ике сәгать карап торгач

— Мин белгән ялкаулар арасында әнә теге озын агай иң хөрәсәне булыр.
— Каян белдең?
— Чөнки ике сәгать инде шуңа карап торам.

Бар иде чаклар...

— Ох, ох, ох,— дип үз алдына сөйләнә икән бер өлкән агай, үткән яшьлеген искә төшереп,— ул чакта чәчем минем шул хәтле куе, дулкынлы иде ки, башыма кунган һәр чебен шул минутта диңгез чире белән сырхаулап егылып төшә барды...

Тартмасызы кирәк

— Әйтегезче, фройляйн, әнә теге ташбака күпмегә сатыла?
— Тартмасы белән кырык марк.
— Миңа тартмасызы кирәк шул...

«Үзем керәсе түгел ич»

— Авызыңны ник бу хәтле киң итеп ачтың? — дип сорый теш докторы.
— Анда көзге һәм инструментлар кертәсе бар, дип үзегез әйттегез ич.
— Ә бит анда мин үзем керәсе түгел.

Көнгә түгел, елга дисең ич

— Бүген мин бер гәзиттә һәр кеше елына бер кило тоз ашарга тиеш дип язганны укыдым.
— Ләкин бит аны бер көнне пешерелгән ашка салып димәгән.

Микроблар әле билгесез чакта

— Сез, бабай, инде йөз илле яшьтә икән дип ишеттем. Менә шуның серен белергә дип Казаннан килдем.

— Сере анын шунда, оланым: галимнәр әле микроблар барын белгәнче мин туган идем.

Су ярдәмендә дәвалану

— Су процедураларынын нинди төрләрен беләсез?
— Юыну, сөртенү, коену!
— Тагын нинди бар?
— Суга чуму...

Хатыны тапсын өчен

— Халык арасына кереп хәләл җефетем ничектер юкка чыкты, эзләп табалмыйм шуны. Сез, чибәр ханым, минем белән бераз сөйләшеп торыгыз әле зинһар, ул хәзер килеп мине табачак.

«Безгә кереп эшләтегез...»

— Күршем, пылесосыгызны берничә минутка гына биреп торсагызчы!
— Ирем рөхсәт итми бит. Ә безгә кереп теләсәгез күпме эшләтә аласыз!

Тентеп карый аласыз

— Иптәш-гражданин, сез тапкан бумажник — минеке ул.
— Ничек исбатлый аласыз?
— Тентеп карагыз менә — бөтен кесәләрем дә буп-буш.

Ачыш

— Беләсеңме, өйгә очып кергән шөпшәне тагын ничек үтереп була?
— Ничек?
— Аны шкаф астына куып кертергә дә шкафның аякларын кисәргә кирәк.

Холыклары бер үк төрле

— Хәләл җефетем тыйнакның да тыйнагы дияр идем. Миннән бер нәрсә сорамый һәм таләп итми.
— Минеке дә гел әмер бирергә генә ярата.

Хәле яхшыру

— Әби, хәлең бүген җиңелрәкме?

— Кичә култык астыма теге нәни пыяла кепшәне куеп торгач бик яхшы булып китте бит әле.

Җитди булып кылану җиңелрәк

— Ни өчен күңелле һәм җор кешеләр җитди кешеләрдән азрак була?

— Чөнки җитди булып кылану җиңелрәк.

Ник кәефсез күренәсең?

— Дустым, нишләп болай бик кәефсез күренәсең әле?

— Эш, кадерлем, эш!

— Каян алынган, нинди эш соң ул?

— Төзелештә көннәр буе кирпеч ташу бит...

— Чынлап та, җиңелдән түгел бу. Күптән шунда эшлисеңме инде?

— Иртәгә башлыйм.

Күрше белән күрше

— Күрше, музыка уйнаткычыгызны беразга биреп тормассызмы икән?

— Хәзер, төн уртасындамы? Биергә теләвегезме әллә?

— Киресенчә, безнең йокыбыз бик килә...

Яртысыннан артыгы

— Сез ничек уйлыйсыз: бу зур оешмада күпме кеше эшли икән?

— Минемчә, яртысыннан аз гына артыгы эшлидер бәлки.

Әйтүе кыен

— Сез Шекспирны яратасызмы?

— Моны әйтүе кыен. Минемчә, без аның белән бик якын дуслар гына түгелме икән.

Каты сигнал

— Доктор, минем аягым сынды бугай?

— Кайчан, ничек?

— Уйнаганда.

— Футболдамы?
— Юк, домино уйнаганда.
— Домино?
— Әйе, пардашым уйнаганда өстәл астыннан аягы белән шундый каты бәрде...

Шикләнмә, кызым

— Әти, мин Людвигка иргә чыкмыйм. Ул дингә каршы кеше һәм җәһәннәмгә ышанмый.
— Андый нәтиҗә ясарга ашыкма. Бер дә шикләнмичә ярәш син аның белән. Әнкәң белән бергәләп сез аны бу ялгыш фикереннән бик тиз ваз кичәргә мәҗбүр итә алачаксыз.

Кем дә булса утырдымы әллә?

— Кичә сездә сатып алган урындык бүген әллә ничә өлешкә таркалды...
— Бәлки аңа кем дә булса утыргандыр?!

Башлык әйтте...

— Әгәр башлык үз сүзен кире алмаса, мин иртәгә биредә эшләмәячәкмен.
— Ә нәрсә диде соң ул?
— «Эш эзләгез» дигән иде...

Үтенсә, ул түгел

— Пан Ковальский, сезнең хатыныгыз телефон трубкасын алырга үтенә...
— Үтенә? Юк, ул минем хатын түгел!

Серен әйттерү

— Котлыйм сине, Алиса! Бик матур булып ябыккансың. Серен әйт әле шуның!
— Ак фасольдән ул, ахирәт.
— Фасоль бит ул симертә диләр?
— Әгәр ашасаң симертә. Ә мин көн саен бер кило фасольны идәнгә сибәм дә, иелеп, шуны берәмләп чүплим.

Тартудан биздеру өчен

— Сигаретың бармы?
— Мин тартырга берни дә сатып алмыйм.
— Ник?
— Синең ишеләрне тартудан биздерер өчен.

Санама сантиметрларын

— Салган сырагыз бокалның билге сызыгына бер сантиметр чамасы җитми ич...

— Әй, санама ла шул сантиметрларын. Хәзерге бокалларга ышансаң...

Бәхетле бәхетсезлек

— Өйләнешкәнебездән соң каенанам безнең өйгә бер генә тапкыр килде.

— Син бәхетле алайса!
— Әмма ул бит шул килүдән китмәде.

Көтә-көтә көт булу

— Сезнең билетыгыз?
— Менә.
— Бу даими билет мәктәп баласыныкы ич?!
— Менә шуннан аңлагыз инде, сезнең каһәр суккан автобусыгызны күпме көткәнемне...

Юанны ябык итеп була

— Синең ирең ай-һай юан да соң...
— Ярый инде... Юанны ябык итеп була ич.

Кулыңны тыя бел

— Кулыңны тыя бел. Әнә күршебезне хатыны белән шулай талашкан өчен ике елга утыртканнар.

— Кара син аны, нинди бәхеткә тарган икән! Ичмаса бераз тавыштан тынып торачак.

Тиздән бер яшь тула

— Сезнең балагыз бармы?
— Әйе, малай үстерәбез.
— Тәмәке тартмыймы соң?
— Юк!

— Бик шәп икән. Чөнки тәмәке — агу бит ул! Ә карта уйнамыйммы?

— Юк!

— Монысы инде тагы да яхшырак! Шундый бала үстерү — үзе зур бәхет. Хәзер андыйлар күп очрамый ич! Инде ничә яшь соң үзенә?

— Тиздән бер яшь тулачак...

Бал ае бетәсе чак

— Бал ае дигән нәрсә кайчан бетә?

— Ир кеше савыт-саба юарга хатынына булышмый, ә инде үзе генә юа башлагач.

Акылы алтын юлдаш

— Менә арсланның әле кичә генә узган эзенә төштек. Син шуның кая киткәнен бел!

— Ә син?

— Ә мин синең юнәлешнең нәкъ киресенә барып аның бирегә кайдан килеп чыкканын ачыклыйм.

Ярый, ярый.. уйнагыз

— Сез музыканы бик яратасыз икән дип әйттеләр миңа...

— Бу дөрес, ләкин ярый, ярый... Уйнагыз.

Мин дә гел шуны тукыйм

Ирегезнең нервлары какшаган. Аңа гел тынычлык кирәк.

— Әлбәттә! Мин дә аңа көненә йөз тапкыр нәкъ шуны тукыйм бит, доктор!

Бәлки табарлар

— Ник бу хәтле ах-ух итеп сулыйсыз? Әллә сездә астма бармы?

— Белмим шул. Хәзер кухнәдәгеләрдән барып сорыйм әле, бәлки, сезнең өчен табарлар.

Әллә машинаңны саттыңмы?

— Син бу дөньяда минем өчен барча нәрсәдән дә кадерлерәк, җаныкый!

— Әллә машинаңны саттыңмы?

Диваналар йортына юл

— Профессор әфәнде, әгәр шушы залдан торып җирне үтәли тишсәм, мин кая барып чыгармын икән?

— Туп-туры диваналар йортына.

Ник язмыйсың?

— Син, каләм остабыз, соңгы вакытта ник бернәрсә дә язмый башладың?

— Башым таш белән тутырылган кебек бик каткан чак әле.

— Ә син ташчылар турында яз.

Тормышны өйрәнү

— Нишләп утыруың бу?

— Менә өс киемем төймәләрен тегәрҗеп белән ныгытып тагам әле. Тормышны өйрәнер өчен халык арасында ишелергә кушалар. Ә сыра залларында бик кысан чаклар була бит, каян алып төймә җиткермәк кирәк.

Эшне ашыктырмыйк

— Институтка керү белән эшең барып чыкмаганга артык борчылма, кызым. Эшкә керерсең менә.

— Эшне, әни, ул хәтле ашыктырмыйк әле. Мин башта иргә чыгып карыйм.

Зур акчасы булмаган

Бер спектакльдә ялчы ролен башкарган артист белән күрешкәч бер тамашачы сорый икән.

— Фәкыйрь ялчының чәче ник шул хәтле озын иде?

— Чөнки ул чакта бит хәзер чәч алдыра торган иксән тиен дә бик зур акча саналган.

Алданрак китеп кара

— Нидән икәнен белмим, берәр юлга чыгарга җыенсам, һәрвакыт бер көн алдан чамасыз дулкынлана башлыйм...

— Ә син юлыңа бер көн алданрак китеп кара.

Төштә таныштым

Бер ханым төнлә ирен уята:
— Ни булды сиңа, ник шулай кычкырасың?
— Марусяның суга батканы төшемә керде.
— Кем соң ул Маруся?
— Син белмисең аны. Үзем дә төшемдә генә таныштым...

КӨЛДЕРЕП ДӘВАЛАУ

* * *

Парижда сырхауларны көлдереп һәм елмаю белән дәвалаучы бер врач була. Аның шул даны һәм танылуы артканнан-арта бара икән. Ул инде сырхауларны хәтта күрергә дә вакыт җиткерә алмый һәм аларга язулы кәгазьләр генә җибәрә башлый. Шул кәгазь битенең өстенә үз исемен куя да аннары үткен көлдергечләр тезеп китә. Врачның исем-фамилиясе Галли Матье була. Тел тарихы белгечләре русча «галиматье» сүзе шул исем-фамилиядән ясалган дип раслыйлар.

Мини * меню

Марк Твен сырхаулагач, врач аңа бик катгый диета язып тоттыра: сохари ашарга һәм тәүлеккә бер стакан сөт эчәргә. Ни бары шул.
— Нишләп шулай бик аз соң? — дип карышмакчы икән әдип.
— Артыгы ярамый. Сез диетада...

* Кечкенә дигән сүз. Биредә сүз күләме чикләнгән ашамлык турында бара.

— Һм-м,— дип куя шунда Твен.— Алайса миңа почта маркасы да тоттырыгыз инде. Мин төнгә каршы бераэр нәрсә укырга да телим бит.

Рецензия

Яшь чагында Бернард Шоу Лондонның бер газетасына музыка тәнкыйтьчесе буларак та язгалаган. Аның врачлар хоры концертына биргән бер бәясе бик кыска була:

«Кичә врачлар җырлады. Үзләренең табиблек бурычларын берсүзсез якларга кирәклеген аларның исләренә тагын бер кат төшерү урынлы булыр иде».

Икенең берсен сайлау хокукы

Франциянең атаклы бактериологы Луи Пасторга һич таныш булмаган берәү килә дә үзен, имештер, аны мыскыллаган бер Графның секунданты итеп таныта һәм шуның үтенечен канәгатьләндерүне таләп итә. Пастор аны тыныч кына тыңлый да үз фикерен әйтә:

— Әгәр мине дуэльгә чакыралар икән, димәк, корал сайларга да хакым бар. Менә ике колба, берсендә — кызамык чире вирусы, ә икенчесендә — чиста су. Сезне бирегә җибәргән адәм шулардан теләсә кайсын сайлап эчәргә килешсә, калган икенчесен үзем кабып йотам.

Дуэль булмый кала, әлбәттә.

Үзе түгел, хатыны чирле

— Доктор! Сез нигәдер минем йөрәгемне тыңлыйсыз һәм каккалыйсыз. Мин әйтергә онытканмын, мин түгел, ә хатыным чирле бит.

Үзе нормальный, ә үзе серле

— Сезнең кан басымы нигәдер миңа ошамый әле,— дип баш чайкый врач.

— Югарымы, әллә түбәнме?

— Ул нормальный шикелле. Ә безнең көннәр өчен бу шуңа күрә серле.

Тимердәй тазалык кирәк

— Нидән зарланасыз?

— Ашказаным киңәйгән, бөерләремдә таш бар, үтем

җилсенгән, ишиас, радикулит турында әйтәсем дә килми инде...

— Берьюлы шул хәтле чир белән яшәр өчен чыннан да тимердәй таза булырга кирәк бит!

Бер генә кечкә...

— Кадерле күршем, бер кечкә генә саксофоныгызны биреп тормассызмы икән?

— Әллә сез дә уйнарга өйрәнмәк булдыгызмы?

— Юк. Мин бүген вакытында ятып йокларга бик телим.

Адресны бутаган

— Ни булды сиңа, Петя?

— Тешем сызлый...

— Син стоматологта булдың ич!

— Әйе. Ләкин минем бит уң азау теш сызлый, ә ул сул як буенча гына белгеч икән.

Дәшмәс иттем

— Син искиткеч уңышка ирешкәнсең икән бит. Ничек дәваладың соң ул кешене?

— Дәшми торырга өйрәттем.

— Сырхаунымы?

— Юк, аның хатынын.

Үз имзасы

Врач бер сырхауның җан тәслим кылуы турында таныклык тутырганда «үлемнең сәбәбе» дигән графага үз фамилиясен куя.

Куян ник күзлек кими?

— Доктор, әгәр кишер күбрәк ашасам, минем күзләр чыннан да яхшырак күрә башлармы?

— Әлбәттә, сезнең күзлек кигән куянны кайчан күргәнегез бар?

Игезәкләр атасы

Бала табу йорты коридорында ике санитар сөйләшә:

— Кем ул анда шулай бик тавышлап елый? Бүген төнлә туган өч игезәк бергә түгелме?

— Юк, шуларның атасы үкереп утыра.

Гаепсезмен мин дип уйлап

— Сезнең сырхауның сәбәбе — алкоголь!

— Гаепне миңа аудармаган беренче врач менә сез булдыгыз! Рәхмәт.

Ашыгасызмы әллә

— Гаҗәп, гаҗәп,— ди врач.—Сезнең йөрәгегез бик акрын тибә бит.

— Ә сез кая да булса ашыгасызмы әллә, доктор?

Алга китешсез медицина

— Сезгә аракы эчәргә һич ярамаганын моннан ничә ел элек әйткән идем инде...

— Хәтерлим, доктор. Әмма шул еллар эчендә медицина күпме дә булса алга киткәндер дип уйладым бит мин.

Күпне кичергән баш

— Дөньяда мин кичермәгән бер генә чир дә калмагандыр дип уйлыйм инде.

— Алай димәгез! Чирләрнең кеше гомерен я өзә, я аны юләр итә торганнары да бар бит.

— Беләм, беләм... Алары да кичкән инде минем баштан...

Эчтән бикләнде

Күрше бүлмәгә сөйләшергә чыккан теш докторы:

— Тагын пациентлар бармы миңа? — дип сорый шәфкать туташыннан.

— Әйе, берәү бар әле. Ул сезнең кабинетта.

— Алайса ник инструментлар әзерләмисез?

— Ул анда кереп эчтән бикләнде.

Тиешлесен капмаган

Иртән сестра палаткага керә дә авыруларның хәле белән кызыксына.

— Я, Салихов, йоклап булдымы?

— Бер дә уянмыйча йокладым, сестра. Рәхмәт сезгә, бигрәк тә шифалы дару биргәнсез миңа кичтән.

— Ә даруыгыз ник тумбочка өстендә ята соң? Эчмәгәнсез ич...

— Эчмәгәнмен?.. Күлмәгемнән өзелгән сәдәфне йотканмын инде алайса...

«Яхшыра» башлау

— Я, хәтерегез яхшыра башлады ич менә!
— Яхшыра... Ә сез кем буласыз соң, бу мәсьәлә сезне ник кызыксындыра?

Чир уйлап табу чире

— Врачлар күпме булса, чир-сырхаулар да шул хәтле була диләр. Дөресме икән?
— Юк, дәваланырга йөрүчеләр күбрәк хәзер һәм шуларның һәркайсы үзенә бер чир уйлап таба.

Аңлату

— Хәзер сез миңа ясыйсы операция бик авыр буламы, доктор?
— Сырхау кешенең үзе өчен авыр түгел — чөнки без аны дару биреп йоклатабыз. Ә хирург өчен бик кыен ул.
— Ник?
— Чөнки хирург бик зур киеренкелек белән эш итәргә тиеш. Мондый операциянең бары тик йөздән бере генә уңышлы узуын белсәгез, моны үзегез дә бик яхшы аңлар идегез.

Хәтерсез сырхау

— Миндә бик көчле склероз, доктор.
— Кайчаннан бирле?
— Нәрсә кайчаннан бирле?

Киңәшмә барганда

Поликлиникага телефоннан шалтыраталар:
— Мөдир белән сөйләшергә мөмкинме?
— Бер-ике сәгатьтән шалтыратыгыз,— ди секретарь кыз,— чөнки хәзер бездә биш минутлык киңәшмә бара.

Карамыйча әйтә алмый

— Исәнмесез, доктор!
— Саумысыз!
— Сез билгеләгән дәваланудан соң хәлем яхшыра төште. Әмма кичә йөрәгемнең тагын я кысылып-кысылып алуы, я чәнчеп-чәнчеп авыртуы бик нык сизелде. Аннары тагын эчем дә авырта. Нишләргә икән?
— Салыгыз өстегезне, тыңлап карыйм.

— Тыңлап? Биредә, театрдамы?..
— Соң сез үтенеч белән мөрәҗәгать итәсез ич. Ә карамый торып бернәрсә дә әйтә алмыйм мин.

Бала белгән нәрсәләр

— Доктор, минә бу эт белән сөйләшегез әле,— ди бер бала.
— Мин җәнлек-җанварлар белән сөйләшә белмим шул.
— Ә ник белмисез, доктор Айболит сөйләшкән бит?

Сулымы, уңымы

— Сул аягым бик авырта минем.
Врач шуны карый да, аптыраганнан җилкәләрен җыерып, белдерә аңа:
— Бернинди зыян да тапмыйм мин монда.
— Алайса уңы авырта булса кирәк...

Ашап кына дәвалана

— Мин сезгә аштан соң гына бер сигарет тартырга рөхсәт иткән идемме? Һәм менә нәтиҗә: бик яхшы күренәсез, сырхавыгыз уза, димәк.
— Ничек начар күреним ди, доктор! Мин бит хәзер көненә ун мәртәбә ашыйм.

КӨНДЕЗ — НОМЕРСЫЗ, ТӨНЛӘ — УТЫ ЮК

Аңлаштылар

Пассажир:
— Сикертмәле урыннан үткәндә тормозга, зинһар, бик әкрен бассагыз иде.

Шофер:
— Юкка борчыласыз. Минем машинаның тормозы эшләми торган чак.

Ике сәбәп

Ике дус сөйләшә:
— Әйдә, ахири, мотоциклың белән район үзәгенә алып бар әле.
— Көндез барсак — номеры юк, төнлә барыр идем — фарасы янмый.

«Җил безнең яктан исә...»

Колхозга килгән бер вәкил председательдән сорый:
— Нигә басуда карны бик аз тоттыгыз?
Председатель:
— Барысын да без тотсак, күрше колхозга калмый бит, чөнки җил һәрвакыт безнең яктан исә...

Дөрес кермәгән

— Иптәш администратор,— дип кычкыра бераз «кызып»; алган берәү.— Кунакханәгезнең лифты ник эшләми? Ике сәгать көтәм инде, урыныннан кузгалганы юк.
— Ә сез телефон будкасында басып торасыз ич.

Кайчан кайта

— Ирең балыктан кайчан кайта?
— Сәгать җидедән дә калмастыр.
— Нигә алай дисең?
— Балык кибете җидедә ябыла бит.

Кайсы нәрсә өйрәтә?

Хатыны машина белән нәрсәдер тегә. Ире аңа киңәш әйтеп тора.
— Акрынрак әйләндер... Ә хәзер уңгарак ал... Җөең алай кырыйда булмасын!..
— Кулыңа инә тотып та караганың юк бит синең, мине тегәргә өйрәтергә...
— «Жигули»не ничек йөртергә кирәген миңа өйрәтәсең бит әле!

Әтисе әйткән сүзләр белән

Әтисе белән улы зоопаркта җәнлекләр карап йөриләр. Шунда малай маймылның төрле кыланышлар ясап сикергәләгәнен күрә дә:

— Әти, мөгаен, бу маймыл икесен бергә кушып эчкәндер,— ди.

— Ник алай дисең?

— Соң, бервакыт үзең: «Аракысы исертә, көмешкәсе кикертә, икесен бергә кушып эчсәң, маймыл кебек сикертә!» — дип җырлаган идең бит!..

Куллары озын булганга

Мастерскойга костюм тегәргә заказ биргән берәү тегүчене гаепли:

— Бу пинжәкне алмыйм мин, чөнки җиңнәре терсәктән генә ич.

— Алай димә, акыллы баш: ул синең кулларың озын булганга гына шулай күренә.

Чамасын белә имеш...

Бер абзый сыра залы мөдиренең килгәнен көтеп шактый озак таптана ишек төбендә. Ниһаять, мөдир дигәнебезнең ике чиләк су алып килгәне күренә.

— Егетем, залга бу чиләкләрне алып кергәнче сал әле миңа бер савыт сыра.

— Курыкма, агай, бу су иртәгәге көннеке. Чама дигән нәрсә барын әллә белмиләр дисеңме?

« Алай булгач юлны да бел...»

— Әй, Гаврило, әйт әле, Васильковага ничек барып була биредән?

— Ә син минем Гаврило икәнемне каян беләсең?

— Мин белгән нәрсә бик күп ул бу дөньяда!

— Соң, алай булгач Васильковага ничек барып булганын да белергә тиешсең.

Әйе, кичә әйттем шул...

Бер абзый, йөзен томалап укыган газетасыннан аерылып, ниһаять, хатыныннан сорый:

— Син нәрсәдер әйттең бугай миңа?

— Әйе, кичә идән юганда «аякларыңны күтәреп утыр әле» дигән идем.

Юкка ваткан

— Кара син аны, мин скрипка уйнаган арада күршебез тәрәзәбезне таш белән бәреп ваткан ич?!

— Юкка эшләгән ул аны. Хәзер син уйнаган тавыш тагын да көчлерәк ишетеләчәк бит аңа...

Сәер сөйләшү

Автобуста ике күптәнге дус очраша:

— Кая барышың?

— Еракка. Ә син?

— Мин аннан да арырак.

Гадәте шундый

— Евмен дәдәй, син бит инде җитмешеңне тутырдың, әле тагын унсигез яшьлеккә өйләнмәкче икәнсең?

— Нишләмәк кирәк, энем, гадәтем шундый. Мин өйләнгәндә Клеопатра әбиегез дә нәкъ унсигез яшьтә иде.

Тартуны ташлар өчен

— Әллә авариягә эләктеңме? Ике кулыңны да ник гипслаттың?

— Юк, авария түгел. Тәмәке тартуны ташлар өчен иң соңгысы итеп шул чараны кулланырга булдым.

Таный алмау

— Язуыгыз һич танырлык түгел, доктор.

— Язу түгел ул, ә кардиограмма дип атала.

— Аталса ни! Аны да адәм аңларлык итеп язу мөмкин түгелмени?

Тетмәсен теткән имеш

— Ну бирдем кирәген мөдиребезнең кичәге җыелышта! Теттем тетмәсен!

— Үз алдында укмы?

— Әлбәттә! Сез, Федор Иваныч, әйткәнне санга сукмыйсыз, мин әйтәм, булмый болай! Төшке ашны вакытында ашагыз, курортларга ешрак барыгыз! — дидем, күзенә туп-туры карап.

Буталыш

Ире төн уртасында уяныш китә дә хатынына:

— Ник елатасың баланы! Бугазы ярыла бит инде! — ди.

— Йокла рәхәтләнеп,— дип тынычландыра хатыны.— Күршеләр малае елый ул, безнең балабыз юк бит...

Кемгә күрсәтим...

— Ник теш куйдырырга теләмисең?

— Ә ниемә кирәк ул? Өйләнгәнемә егерме ел инде. Кемгә күрсәтим ди ул тешләремне?

Күбе түгелә

Врач бүлмәсенә куркудан калтырангандай берәү керә.

— Күп эчәсезме? — дип сорый аңардан табиб.

— Аз-маз гына. Чөнки күбрәге түгелә.

Цемент каптырмагыз

— Алло, ашыгыч ярдәмме бу? Тиз генә килегез әле, оныгым ком ашаган.

— Ә хәзер берәр нәрсә каптырмадыгызмы?

— Бераз су гына бирдем. Сез килгәнче нишләргә?

— Берни дә кирәкми. Карагыз аны, цемент каба күрмәсен.

Инде кабып та өлгергән

— Әйдә, кода, берәр чәркә кабыйк әле.

— Юк, булдыралмыйм.

— Ник?

— Өч төрле сәбәбем бар: бердән, хәмер саулыкка зыян, икенчедән, врач тыйды, чөнки сырхавыма ярамый. Өченчедән, бүген шактый каптым да инде.

Саклана белү чире

— Петроны бик сакчыл дип сөйлиләр. Дөресме?

— Әйе, ул хәтта нинди дә булса берәр нәрсәгә дә, сыңар күзен йомып икенчесе белән генә карый. Күзләрен саклый, имеш.

* * *

Борын заманда берәү, халыкны алдап, күрше авылларда күрәзәлек кылып йөри икән.

Беркөнне шул кеше берәүләрдә алдашып утырганда кемдер килә дә тәрәзәдән кычкыра:

— Әй, күрәзәче, йортың яна!

Күрәзәче каушавыннан бишмәтен дә кияргә оныта, авылына чыгып йөгерә. Кайтса, янгын да, чуртым да юк икән.

Шуннан бирле бу кешедән:

— Үз йортында ни барын, ни югын да белмәгәч, сиңа ничек ышанмак кирәк? — дип көлә башлаганнар.

* * *

— Нишләп йөрешең болай, ахири?
— Этем югалды. Шуны ничек тә булса табасы иде.
— Ә син гәзиткә игълан бир.
— Этем укый белми иде шул...

ФӘН КҮЗЛЕГЕННӘН КАРАП

Кем булып эшли

Күренекле бер профессор бер сырхауны карагач:

— Сезгә акыл хезмәте белән шөгыльләнмичә тору кирәк булыр. Кем булып эшлисез?

— Оперетта либреттолары язам.

— Ә моны туктатмаска да мөмкин.

Берьюлы икәү сөйләмичә аңлат әле

Берәү психиаторга күренә һәм зарын белдерә:

— Доктор, мин һәр нәрсәне ике итеп күрәм, ике итеп

тоям никтер. Тәмам җәфалады инде бу мине. Хәтта мин мин түгел, ә без һаман икәүбез кебек.

— Һич ни аңламыйм. Тагын кабатлагыз әле. Тик, зинһар, икегез дә берьюлы сөйләмәгез.

Кайсы нигә кирәк?

Профессор: Әйтегез әле, бавырның функциясе нинди?

Студент: Бавыр кан әйләнешен тәэмин итә.

Профессор: Алай булгач, йөрәк нишли?

Студент: Йөрәк нигездә мәхәббәт функцияләрен башкара, минемчә.

Читтән торып

— Ишеттеңме син, галим Н. үз уйларын ерак-ерак араларга читтән торып күчерә ала икән бит?

— Моның булуы мөмкин түгел!

— Нигә?

— Чөнки аның үз уй-фикере беркайчан да булганы юк бит.

Сан сыйфатка әйләнә диптер

— Синең шефың фәлсәфи темаларга бик күп чыгышлар бастыра, ләкин алар, минем уемча, йомшак булалар. Нигә шулай ашыга икән ул?

— Кайчан да булса сан сыйфатка күчәр әле дип өметләнәдер.

Исемлеккә эләгүдән курку

— Сине нинди проблема бигрәк тә борчый хәзер?

— Штаттан чыгарылырга тиешле кешеләр исемлегенә эләкмәү.

Шефың — автордаш булсын

— Сез минем хезмәтне укыдыгызмы?

— Әйе.

— Шуны матбугатта чыгарырга шеф рөхсәтен алу өчен нишләргә икән миңа хәзер?

— Аның үзен соавторлыкка алырга.

— Бер атналык бу прогулыңны ничек дип аңлатмакчы буласың инде, коллега?

— Көчлерәк градуслы нәрсәне бераз авыз итеп, минут эчендә бер «йомшаклык» эшләнелгән...

Аны эшли алмый ул

Петербург хәрби медицина академиясендә студентлардан берәү академик С. П. Боткинның бер генә соравына да җавап бирә алмый. Боткин аны, әлбәттә, борып чыгара.

Соңыннан профессор янына әлеге ялкауның ике дусты керә дә: «Йөрәгемә пычак кадыйм!» — дип куркыта ул анда безне, дип әйтәләр.

— Бер дә борчылмагыз,— дип тынычландыра боларны Боткин,— сезнең дустыгыз кеше гәүдәсенең төзелешен белми, димәк, йөрәгенә пычак кадый алмаячак.

Соң инде

Студенттан имтихан алганда профессор:

— Менә бу сырхауга күпме дару бирер идең? — дип сорый.

— Бер аш кашыгы.

— Рәхмәт, сезгә чыгарга мөмкин.

Ләкин нәрсәдер исенә төшергән студент бик тиз әйләнеп керә:

— Профессор, ялгышканмын мин, биш кенә тамчы бирергә кирәк.

— Соң инде, сезнең сырхавыгыз исән түгел...

Урынсыз ачулану

Пьесасын тәнкыйтьләп язганы өчен бер яшь драматург рецензия авторына ачулана икән:

— Сез бит әсәрнең яхшымы, начармы икәнен гомумән белә алмыйсыз. Чөнки спектакль барганда гел йоклап утырдыгыз...

— Кайчакта йокы үзе дә зур фикер ул,— ди рецензент.

Шуннан түбәне юк бит

— Профессор әфәнде, миңа әдәбият теориясеннән «начар» билге куюыгызны һич аңлый алмыйм.

— Нишлим соң, энем, аннан да түбән билге юк бит.

Бу нәрсә сезгә кагылмый

Башлап язучы бер кыз өлкән тәнкыйтьче белән сөйләшә:

— Гениаль булу үзе бер чир диләр, дөресме шул?

— Бу нәрсә сезне бер дә борчымасын, сез гаять таза күренәсез...

Йокы алдыннан укыгыз

Шагыйрь, докторга күренеп, үзенең зарын белдерә:

— Профессор, зинһар, дип үтенәм, миңа ярдәм итегез! Ярты төнгәчә утырып шигырь язганнан соң йоклый алмыйча иртә таңга чаклы азапланам.

— Ә сез, энекәш, үзегез язганнарны төнгә каршы укыгыз гына...

ШУЛ ДА БУЛДЫМЫ ӘХЛАК

(Капитал дөньясы күренешләреннән)

Операциядән соң

— Сезгә операция ясадыларммы инде? — дип сорый врач.

— Әйе.

— Я, ничек?

— Өч мең доллар!

— Мин сезнең чирегез нинди икәнен белмәк идем.

— Бары тик ике йөз илле долларлык кына.

— Сез мине тагын аңламадыгыз. Нәрсәдән зарланасыз?

— Чамасыз күп түләргә кирәклектән.

Күнегү

— Коллега, сезнең һәрвакыт тыныч булуыгыз сокландыра мине. Ничек шуңа ирешә аласыз?

— Бик беләсегез килсә әйтим инде: күнегүләрем чамасыз күплектән ул. Өемдә каенана, хатыным, дүрт балам, ике этем һәм инде эшкә яраксыз зажигалкам бар бит...

Өстә шофер юк...

Лондонга ерак провинциядән килгән бер пар ике катлы автобуска утыралар. Шуларның берәве икенче катка менә дә аннан бик тиз атылып төшә:

— Джим, өскә менәм дип аяк атлыйсы булма — анда шофер юк икән бит.

Беренче булып

— Минем уемча, җирдә беренче кеше булып Адам түгел, ә Ева яралгандыр.

— Ник шулай дисең?

— Чөнки библиядә: «Башта сүз ишетелә» диелгән бит.

Мең крон акча һәм чәшке тиресе

Судья банкротка чыккан бер фирманың эше буенча шаһит буларак чакырылган секретарь кыздан сорый икән:

— Ялган күрсәтмә биргән өчен нәрсә буласын беләсезме?

— Әйе. Шеф ике мең крон акча һәм бер чәшке тиресе алачаксың, дигән иде.

Аркылыга түгел, буйга

Бер фокусчы цирк директорына:

— Мин яңа номер әзерләдем,— дип белдерә.— Бер ханымны урталай кисәм!

— Нәрсәсе яңа моның. Күпләр эшли ала торган гадәти чыгыш.

— Мин бит аркылыга түгел, буйга кисәм!

Көйсез күренде

— Мин сезне пианино көйләргә чакырдым, ә сез минем кызны үбәргә маташасыз!
— Чөнки ул бик көйсез булып күренде күземә...

Нәтиҗә

«Бүген үк үтә, иртәгәгә калдырма!» Зур бер фирма хуҗасы, хезмәткәрләре нәтиҗәлерәк эшләсен өчен, күренекле урыннарга шундый плакатлар язып эләргә куша. Берничә көн үткәч фирма хезмәткәрләренең бу өндәмәне ничек башкаруларын белергә тели бер танышы.
— Мин уйлаганча булып чыкмады шул. Кассир йөз мең крон урлап шул ук көнне качты, управляющий минем хәләл җефетем белән каядыр китеп югалдылар, ә алты хезмәткәр эш хакын күтәрүне дәгъвалап керде...

Срогыннан элек кисәтү

— Оят түгелме сиңа мәктәптә шул хәтле тәртипсезләнергә,— дип тирги тәртипсез баласын бер ханым.— Атаңнан үрнәк аласы иде сиңа.
— Соң, эти бит төрмәдә утыра.
— Хатларында ул үз-үземне яхшы тоткан өчен мине срогыннан элек азат итәчәкләр дип яза ич.

Су һәм... галстук

Хансен чүлдә эчәргә су табалмыйча газаплана. Шул чакны аңа берәү очрый һәм:
— Су! Су! — дип көчкә телен әйләндереп әйтә икән.
— Кызганыч, сэр, әмма мин бит галстуклар гына сатам.
Бәхетсез Хансен, юлын дәвам итеп, бер оазистагы ресторанга шуышып керә икән һәм пышылдап:
— Су... Су...— дип ялвара.
— Бик кызганыч, ләкин без галстуксыз кергәннәргә бернәрсә дә сатмыйбыз,— ди аңа официант.

Соңгарып йөрү

Моралес исемле ханым иреннән аерылырга судта эш кузгата.
— Сәбәбегез нинди була инде?
— 1967 елда бер савыт сыра эчеп керергә дип чыккан иде, 1983 елда гына өйгә кайтып керде.

Полициягә белдермәү

— Кичә миңа урамда бер бандит бәйләнде, әмма мин моны полициягә белдермәдем.

— Ни өчен?

— Чөнки ул минем кесәләремне актарды-актарды да, анда берни дә тапмагач, кулыма үз кесәсеннән чыгарып бер доллар тоттырып китте.

Шул хәтле йөгереп килгәч...

— Йожо атаклы спортчы! Мең ярым метр араны йөгереп узгач алты метр озынлыкка сикерде.

— Шул хәтле ерактан йөгереп килеп тә ничек инде 6 метрга да сикерә алмасын ди адәм баласы...

Бик ашыкмагыз әле...

Сырхауны операция бүлмәсеннән палатага кертеп салалар.

— Бөтенесе тәртиптә инде, ниһаять! — дип ходайга рәхмәт яудыра ул шулчакны.

— Алай бик ашыкмагыз әле,— дип кисәтә аны күрше караватта яткан берәү.— Миңа операция ясаганда хирург эчемдә бер уч мамыгын калдырып теккән иде яраны.

— Ә минем эчтә инструментлары калган булып чыкты,— ди икенче берәү.

Шул вакыт палатага хирург үзе кереп:

— Минем эшләпәмне күрүчегез булмадымы? — дип сорый икән.

Очрашу

Муеннарына «эш эзлим!» дип ат башы хәтле хәрефләр белән язылган белдерү таккан ике кеше бер бакчадагы эскәмиягә кич кунарга утырганнар.

— Синең белән, егеткәй, каядыр очрашкан идек бугай без?

— Сез бит, пан профессор, университетта безгә лекцияләр укыдыгыз.

«Бәлки, миндер...»

Беренче лекциясен башлар алдыннан профессор яңа студентлар белән таныша.

— Студент Грувениблонвербоксбург...

Студентлардан берәү тавыш бирә:

— Бәлки бу миндер. Ләкин, рәхим итер, инициалларын да әйтсәгез икән.

Үз улыбыз булса...

Кичке эңгер-меңгер чак. Ир белән хатын урам буйлап каядыр ашыга. Артларыннан битен-башын куе сакал-мыек һәм зур толым чәч каплаган бер зат килгәнен сизеп-күреп алгач алар бер карарга килә:

— Әгәр ул хулиган булса, безнең мең франк акчабыз бар дип, ә инде үз улыбыз булып чыкса, яныбызда сукыр бер тиен дә юк дип әйтербез.

Бүләк сорап тагын килү

— Сез миңа моннан өч ай элек иске пинжәк бүләк иткән кеше булам мин. Шуның кесәсеннән биш йөз франк акча таптым.

— Шул акчаны китердегезме әллә?

— Юк... сезнең тагын иске пинжәкләрегез булмасмы икән дип килгән идем.

Яшерен кесә

— Мсье, сез өйләнгәнме инде? — дип сорый костюм тектерүче берәүдән тегүче.

— Әйе.

— Алайса пинжәгегезгә яшерен бер кесә дә эшлим диясе идем.

Белдерү

Голландия газеталарының берсендә белдерү басыла: «Хатыным ташлап китүе сәбәпле, ул бәйли башлаган йон күлмәгемне бәйләп бетерердәй кәләш эзлим!»

Зур бәягә санап

— Ай аллам, карта уйнап пальтоңны оттырдыңмы?

— Һәм сәгатемне дә, аппагым.

— Ай аллам...

— Борчылма, җанкисәк, бу минем өчен бик отышлы оттырыш булды әле: пальто белән сәгать ике йөз маркадан артык тормый, ә алар аны ике йөз илле маркага исәпләделәр.

Бай кеше карт була алмый...

— Магданың бер карт кешегә кәләш булырга җыенганын ишеттеңме?
— Гафу ит, бай кеше карт була алмый.

Килми калмый ярамас

— Син минем туема килерсеңме?
— Кайчан?
— Җомга көнне!
— Кемгә өйләнәсең?
— Сиңа.
— Алайса килми калмый ярамас.

Чәчәк үстерергә дип

— Жаннет, шулай бик озакка сузып нәрсә саныйсың син анда? — дип сорый ир кеше.
— Сорама, җаным,— ди аңа хатыны.— Мин бүген чәчәк утыртыр туфрак өчен алты франк акча түләдем. Менә хәзер шуны бик беләсем килә: әгәр дә ки без чәчәк үстерергә дип бөтен җир шарын сатып алырга теләсәк, ул күпме торыр икән?

Өчләтә түләү алып

— Син чамасыз баеп алгансың дилэр, Пьетро! Ничек ирештең моңа?
— Мин утрауга туристлар ташыдым. Утрауга экскурсия биш йөз лир тора иде. Ә аннан кайтарганда — өчләтә түләү алырга туры килде.

Үзен җирләргә акча даулау

— Теләсәң нишлә, улым, мин сиңа хәзер беркайчан да акча бирмәячәкмен. Бу никахыңнан соң син минем өчен үле җан инде.
— Алайса мине җирләрлек акча бир.

Бөтенесе урланмаган

— Безнең малай минем янчыктагы зур сумма акчаны алган,— дип белдерә бер ир хатынына.
— Ә ни өчен мин алганмындыр дип уйламыйсың? — ди ханым.
— Чөнки вак-төяк бакыр-көмешләрнең бөтенесе бумажникта калган.

Аерылышуга таба беренче адым

— Кичә аерылышуга таба беренче адымны атладым мин.
— Әллә син өйләнгәнме?
— Бүген икенче көн инде.

Хатынының катнашы юк

— Нишләп иртүк ресторанда утырасың?
— Үземнең көмеш туемны билгеләргә кердем.
— Ә хатының кая?
— Аның бу эшкә катнашы юк. Чөнки ул минем өченчем инде.

Тагын бераз ябыгырга теләү

— Ирем бик юньсез булып чыкты: көн саен соң кайта, җитмәсә тагын кызмача була... Хезмәт хакын кайтармый. Шуның аркасында нәкъ ун килога ябыктым инде...
— И бичаракай! Ә ник аерылмыйсың соң?
— Беләсеңме... Әле тагын ике-өч килога ябыгырга телим.

Һич көтелмәгән нәтиҗә

— Бу шифаханәдә,— ди Карлсон,— кемнәрнең нишләгәннәрен белмәссең. Мине бирегә салганда бер врач аппендицит дигән иде, икенчесе үтеңә таш җыелган ди.
— Ә нинди нәтиҗәгә киленде соң инде?
— Һавага тәңкә чөеп шобага салдылар да тамагымдагы гландаларны кистеләр.

Мышьяк кыйммәтрәк

Бер клиент аптекадан дарулар алып чыгып барганда аңа кычкыра икән аптекарь:
— Туктагыз әле, тукта! Сода урынына мышьяк биргәнмен мин сезгә.
— Нинди аермалары бар соң аларның?
— Мышьякның бәясе ике франкка кыйммәтрәк.

Алдакчы икән

— Сез кызыгызны Джаванига бирәсез икән дип ишеттем,— ди бер ханым үз күршесенә.— Соң ул бит төрмәдә биш ел утырып әле генә чыкты.

— Алдакчы икән алайса! Ә миңа бер генә ел утырдым дип әйтте, юньсез.

Тагын оныткан

— Туйдан соңгы сәяхәткә китәм дисең, ә хатының кая соң?

— Шайтан алгыры, юлга чыкканда һәрвакыт шулай өйдә нәрсәмнедер оныта башладым!

Кайсын тартырга

Газетада чыккан белдерү:

«Әгәр күршегездән нәрсә өчен дә булса үч алырга теләсәгез «Кэмел» сигаретын тартыгыз. Төннәр буе буыла-буыла бик каты ютәлләтер ул, йоклап киткәч исә чамасыз тавышлы гырлатыр — күрше дигәнең бер генә минут та йоклый алмас. Әгәренки күршегез белән яхшы мөнәсәбәттә икәнсез, бары тик безнең компания сигаретларын гына алыгыз».

«Котлетың эт карынында!..»

Өенә бик соң кайткан ир холодильник капкачына эленгән язу укый:

— Синә дигән котлет этебез карынында инде!

Бәя артудан куркып

— Безгә счетны да аш-су белән бергә үк китерсәгез иде, чөнки без ашаган арада бәяләрнең тагын артуы ихтимал...— ди икән ресторанда бер ир белән хатын.

Начар фильм күрсәткән өчен

Фильм күрсәтелеп беткәч, кинотеатр кассасына гангстер килә дә, кассиршага пистолетын күрсәтеп:

— Мисс, искиткеч начар халтура күрсәттегез. Билетлар бәясен хәзер үк чыгарып миңа бирегез! — ди.

«Өс-башыңа ки дә йокларга ят»

Кызы дискотекадан бик соңгарып төнлә генә кайткач:

— И ходаем,— ди аңа әнисе,— танцыларга син шулай йөрисеңмени? Тизрәк өс-башыңа ки дә йокларга ят!

Сары чәчлеләрне ярата икән

— Карагыз әле, официант, минем шулпада кара чәч бөртеге йөзә ич!

— Күрүемчә, сэр сары чәчле дамаларны ярата төшә булса кирәк?

Туры килмәгән әле

— Карале, Джон, сиңа моңарчы кешеләргә атарга туры килдеме?

— Юк. Алабамада мине бары тик негрларга һәм буш консерв банкаларына гына төбәп аттырдылар.

Операцияне кичектерү

Хирург бер танышына шалтырата:

— Сезнең үтенеч буенча теге сырхауның эчтәге авыру урынын табар өчен сөяген бораулап тишәргә кирәк булачак бит. Ничек уйлыйсыз, моның өчен ул мең франк түли алырмы?

— Минемчә, хәзер үк түли алмас. Әмма мин аның яңа бер зур завод салачагын ишеттем.

— Ярый, алайса операцияне мин ярты елга кичектерәм...

Таш булмаган

Судья бер йолкыш сукбайны үгетли:

— Шул хәтле мәрхәмәтсез булырсың икән! Ул карчык сиңа ике булки биргән ич. Ә син таш ыргытып аның тәрәзәсен ватансың!

— Галиҗәнаб, таш түгел иде, үзе биргән булкаларның берсен аттым!

Исбатлау җавабы

— Ольдика, бүләгең өчен зур рәхмәт! Ул крем чыннан да биттәге җыерчыкларны бик тиз бетерәме?

— Тагын бер кат ант итеп башымны кисәргә бирәм:

минем Владек ванна бүлмәбездәге бөтен тишек-тошык урыннар һәм ярыкларны шуның белән сылады, бик шома булды.

Унбиш минуттан соң

Урам хәрәкәте кагыйдәләрен бозган берәүне полицейский туктата:

— Ник сәгатенә йөз чакрым тизлек белән чаптырасыз машинагызны?

— Нинди сәгать ди? — Руль тотып утыруыма унбиш минут кына ич әле?

Исемлек тәкъдим итә

— Үзегез генә эшләп алган акчага хатыныгызны асрый алмыйм дисез икән, менә мин сезгә никахтан баш тартучыларны яклаучы адвокатлар исемлеген бирәм.

Шифаханәдән хәбәр

Эштә имгәнгән берәүнең эш урынына шифаханәдән белдерәләр:

— Хезмәткәрегезне, без куйган гипсы кибү белән үк эшкә чыгара аласыз.

Катгый әмер

— Администрация һәм хезмәткәрләр һәр нәрсәне бердәм килешеп эшләргә тиешләр. Шуңа күрә сезгә минем приказларның барчасын төгәл үтәргә әмер бирәм.

Үзенчә хәл иткән

— Мин бүген завод капкасы артына чыгып китәргә үзләре теләмәүчеләрне эштән куу проблемасын хәл иттем,— дип мактана икән кулына автомат тоткан бер магнат.

Эш эзләп

Икесе бер вакытта килеп станциядә туктаган поездның кара-каршы вагонында торып ике абзый сөйләшә:

— Кызык бит әле бу, эш эзләп син көнчыгышка барасың, ә мин шул ук мәсьәлә белән көнбатышка юл тотам.



ЧИЛЕ-ПЕШЛЕЛӘР СЫРЛАГАН ЧЫШ-ПЫШ

(Пегас серләре сандыгыннан)

Төзәтү кирәк

— Сезгә пьесаны аның герое асылынып түгел, ә атылып үлә торган итеп төзәтү кирәк, минемчә.

— Ни өчен?

— Чөнки мылтык тавышы тамашачыларны да уятачак.

Сәбәбен әйттеләр

— Минем хикәянең азагы сезгә ошамаган диләр. Сәбәбен әйтмәссезме икән?

— Чөнки ул хикәянең башыннан бик еракта.

Тартуыңны ташла

Бер эдип каләмдәш дустына үзенең иҗат тәҗрибәсен сөйли икән:

— Мин тәмәке тартмасам яза алмыйм...

— Алай булгач сезгә тартуны ташларга кирәк.

Кире кайтмаган әле...

Яшь бер автор хат ташучы белән сөйләшә:

— Миңа нәрсә дә булса юкмы?

— Юк, сезгә редакцияләр бүген бернәрсә дә кире җибәрмәгәннәр әле.

Күптән укылган хикәя

— Минем хикәяне укыдыгызмы, иптәш редактор?

— Укыдым, хөрмәтлем, укыдым! Күптән инде, син тумас борын әле...

Басылу-басылмау турында

— Минем шигырь сезгә ошадымы?
— Аңардан начарраклары да була.
— Бәлки, икенчерәк фикер әйтерсез?!
— Әйтә алам әлбәттә: болардан начарраклары басылмый.

Кире кагылу

Кульязмасын карап чыккач, редактор автордан сорый:
— Нишләп романыгызны «Бумеранг?» дип атадыгыз?
— Беләсезме, ни өчен: кайсы гына редакциягә җибәрсәм дә, аны миңа кире кайтардылар...

Юморны яклый, имеш

— Бу юморның бернинди үткенлеге һәм көлкесе юк дип саныйм мин.
— Безнең заманда, кадерлем, күпләр никотинсыз тәмәке тарта, шикәрсез ширбәт һәм кофеинсыз кофе эчә бит әнә. Юморсыз гына шаяруларны яратучылар да табылыр әле.

* * *

— Күрәсең пьеса кызыклы булырга тиештер, әнә бит күпме халык килгән...
— Тамашачы түгел бит алар — һәммәсе драматургның я автордашлары, я дус-ишләре...

Бик көчле йомшак

Башлап язучы драматург күренекле һәм өлкән әдипкә үзенең пьесасын укырга бирә дә бер атна үткәч кызыксынып сорый:
— Я, ничек? Көчлеме, әллә йомшагракмы?
Җавап бик кыска була:
— Икесе дә бар: бик көчле йомшак.

Әдәби диагноз

Мөтәшагыйрь белән күренекле бер әдип очраша.
— Эшләр ничек, коллега?
— Коллега? — дип гаҗәпләнә күренеклесе.— Ә! Әйе! Оныта язганмын: сине дә ревматизм борчый бит әле.

Матурлыкның көче

— Премьераң ничек үтте?
— Шәп булды кебек. Пәрдә ачылгач та, ябылгач та көчле алкышлар булды.
— Кызык. Пәрдә бизәкләре шул хәтле матур идеме?

Мавыктыргыч китап

Берәү электричкада китап укып бара. Укый-укый да, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча, кинәт кычкырып куя:
— Менә бит ничек икән ул! Элек моны башыма да китерми идем... Ха-ха!..
Тагын бераз укып баргач хәтта сикереп үк тора.
— Булмас! Ышанмыйм!!
— Нәрсә укыйсыз? — дип сорый бер пассажир.
— Орфография сүзлеген,— ди укып баручы.

Кем икәнемне беләсезме?

Толстой Шекспирны яратмаган, мин дә Шекспирны укымыйм.
Чехов тәнкыйтьчеләрне өнәмәгән, мин дә тәнкыйтьне җенем сөйми.
Пушкин авылда яшәүне яраткан. Мин дә авылны үз күрәм.
Байрон чатанлабрак йөргән. Мин дә никтер чайкалыбрак атлыйм.
Уэллс тәбәнәк буйлы булган. Мин дә бик үк озыннардан түгел.
Бальзак кофе эчәргә яраткан, мин дә кофедан баш тартмыйм.
Айвазовский диңгезгә гашыйк булган. Мин дә ел саен диңгез буена бармыйча калмыйм.
Шаляпинның тавышы бик көчле булган. Минем тавышны да колак тондыргыч диләр.
Сименон трубка тарта. Мин дә бары тик трубка гына тартам.
Менә шушы тап килүләрдән соң мине бөек димәгән кешене җансыз дип саныйм.

Үзебез күбрәк

Спектакль башланыр алдыннан режиссер тамаша залына карады да артистларны дәртләндерер өчен:
— Борчылмагыз, артык дулкынлану кирәкми! Бүген без үзебез тамашачылардан күбрәкбез.